ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0869-5083

10'98

Шәүкәт БИКТИМЕРОВ: БЕЗНЕҢ ТАМАШАЧЫ – ИМАНЛЫ ХАЛЫК, ЧӨНКИ АНЫҢ МӘЧЕТЕ БАР, ТЕЛЕ БАР, ТЕАТРЫ БАР.

ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТКӘРЕ 12

ЯЗЫЛАСЫ РОМАН 22

МӨСЛИМ ҖИРЕ АЛТЫНЛЫ 28

АК ЯУЛЫГЫМ КЕБЕК АК КАЛДЫМ 54

КАЗАННЫҢ йөзек кашы,

Ял көннәрендәме, эштән соңмы,вакыт табып, ашыкмый-кабаланмый гына Казанның бродвее булган Бауман урамыннан үт әле. Соңгы елларда күзгә күренеп чибәрләнә барган башкалабыздагы үзгәреш-яңарышлар, бер тамчы суда кояш чагылган шикелле,нәкъ менә Бауман урамында калку гәүдәләнеш таба. Бу урамнан узганда, чал тарих белән хәзерге заманның бик тә гармонияле төстә бергә кушылып яшәвен күрерсең. Онытма: Казан кешеләренең иң яраткан урамы бу. Алар башкалабызга килгән кунакларын да иң элек шунда алып киләләр. Бауман урамы борын-борыннан шәһәрнең үзәк магистрале булып формалашкан. Казанда күпме генә яңа районнар, киң проспектлар пәйда булмасын, барыбер ул тарихи үзәкнең төп урамы данын саклый. Хикмәт анда гына да түгел. Иң мөһиме: ул кешеләргә күптин-күп ихтыяҗларын канәгатьләндерү мөмкинлекләрен тәкъдим итә ала. Аның сәүдә итү, көнкүреш хезмәте, мәдәни-агарту,тамашалар күрсәтү вазыйфалары - күп гасырлардан килә торган традиция. Аның буеннан-буена дистәләгән махсус кибетләр, рестораннар, кафелар, ашханәләр, ательелар, кунакханәләр, кинотеатрлар, драма театры, административ учреждениеләр һ. б. тезелеп киткән.

Башкаланың үзәк урамы

Урам тарихы Казан тарихы белән аерылгысыз бәйләнгән. Аның бик күп бианлары узганнарның йөзен саклый. Дөрес, борынгылары сакланмаган. Башта Казан агачтан төзелгән булган. Әледән-әле булып торган янгыннар агач биналарны ялап алган. Сакланып калганнары XVII гасырга карый.

Урам Кремльдән башлана. XV-XVI гасырларда аның озынлыгы бүгенгедән ике тапкыр кимрәк булган. Бары XVII гасырда гына аны Яңа бистәгә кадәр (хәзерге Богоявленский чиркәве) суза алганнар. Урамның хәзерге чикләрдә формалашып бетүе XVIII гасырга карый. Өч ярым гасыр дәвамында ул Зур Проломный исемен йөрткән. 1930 елда аңа Казанда туып-үскән һәм актив революцион эшен җәелдереп җибәргән Н. Э. Бауман исеме бирелгән.

Хәзер үзәк урам икенче яшьлеген кичерә. Күптән түгел аның түшәмәсе алыштырылды: таш җәелде. Ике яклап бер караганда борынгы, икенче караганда заманча баганаларга затлы фонарьлар эленде. Түбәсе ябылган гаҗәеп ял урыннары, тирмәләр пәйда булды. Биналарның күпчелеге ремонтланды, яңартылды. Инде исемен үзгәртәсе генә калды. Безгә калса, Тукай мәйданына килеп терәлгән бу урамга Тукай исемен бирү бик тә муафыйкъ буласы. Бу гамәл Казаныбызга бер милли төсмер өстәр иде.

ТАТАРСТАН

TATARSTAN №10 1998

Баш мөхәррир
Рифат ФӘТТАХОВ

Редколлегия:
Флорид ӘГЪЗАМОВ,
Казан дәүләт университетының журналистика факультеты деканы,
Ислам ӘХМӘТҖАНОВ,
Татарстан Республикасының матбугат һәм мәгълүмат министры,
Разил ВӘЛИЕВ,
Татарстан Республикасының Милли китапханә директоры, Татарстан халык депутаты,
Тәлгат ГАЛИУЛЛИН,
академик,
Марат ГАЛИЕВ,
Татарстан Дәүләт Советының икътисадый үсеш һәм реформа мәсьәләләре даими комиссиясе рәисе,
Ришат ГЫЙНИЯТУЛЛИН,
җаваплы сәркәтип,
Әнәс ИСХАКОВ,
Азнакай районы хакимияте башлыгы, район һәм шәһәр берләштерелгән Советы рәисе,
Гүзәлия МИНКИНА,
Мәскәү районы хакимияте башлыгы, район Советы рәисе,
Роберт МИҢНУЛЛИН,
Татарстан Дәүләт Советының мәдәният һәм милли мәсьәләләр даими комиссиясе рәисе,
Ринат МӨХӘММӘДИЕВ,
Татарстан Язучылар берлеге рәисе,
Сәйфихан НАФИЕВ,
Татарстан Республикасы прокуроры,
Марсель ТАИШЕВ,
Татарстан Республикасы мәдәният министры,
Индус ТАҺИРОВ,
академик, Татарстан халык депутаты, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе,
Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ,
баш мөхәррирнең беренче урынбасары,
Фарис ХАРИСОВ,
Татарстан Республикасының мәгариф министры,
Рафаэль ХӘКИМОВ,
Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт киңәшчесе,
Илгиз ХӘЙРУЛЛИН,
Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары,
Әнәс ХӘСӘНОВ,
Президент Аппаратының матбугат үзәге җитәкчесе,
Тәлгат ШИҺАБИЕВ,
"Востокстройтрансгаз" акционерлык җәмгыяте генераль директоры,
Рүзәл ЮСУПОВ,
Казан дәүләт педагогика университеты ректоры, академик.

Бүлек мөхәррирләре: Госман Гомәров, Резидә Низамиева, Нурсәя Шәйдуллина.
Бу санның дизайнын Розалина Мусабирова, компьютер версткасын Татьяна Шмарина һәм Елена Тарасова башкарды.
Гамәли хезмәткәрләр: Лариса Әхмәтова, Лүзия Әюпова, Клара Миңнуллина, Фирадия Хәйруллина.

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Телефоннар:
баш мөхәррир - 43-55-62,
баш мөхәррир урынбасары - 49-36-68,
җаваплы сәркәтип - 49-36-27,
баш бухгалтер - 43-54-33.
бүлекләр:
сәясәт, фән; әдәбият-сәнгать; хатлар һәм социаль мәсьәләләр - 49-36-25,
икътисадый үсеш һәм реформалар; реклама, коммерция - 49-36-23.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
Килгән хатлар, кулъязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми, авторга кире кайтарылмый.
Производствога бирелде 28.09.1998.
Басарга кул куелды 26.10.1998.
Кәгазь форматы 60/84 1/8.
Күләме 8 басма табак.
Заказ Я - 537. Тиражы 5000
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәү таныклыгы N 95.
Татарстан газета-журнал нәшрияты типографиясе.

Тышлыкның беренче битендә - С. Исхаков фотосы.

Фотоочеркта Э. Хәкимов, С. Исхаков һәм А. Титов фотолары файдаланылды.

ЭЧТӘЛЕК

6 **Республика сулышы**

8 **Мөлкәтле дәүләт - бай дәүләт**

Н. Булатов.
10 **Үз кешебез**

Г. Гомәр.
11 **Җир улы**

Ә. Фәйзрахманов.
12 **Дәүләт хезмәткәре**

Н. Әкбәров.
16 **Яшь җинаятьчеләрнең төбәге бармы?**

И. Саттар.
19 **Алладан куркумы, әллә максатмы берләштерә?**

Т. Миннуллин.
22 **Языласы роман**

27 **Республикабыз - матбугат дәрьясында**

Р. Фәттахов, Г. Гомәр.
28 **Мөслим җире алтынлы**

32 **Бер горурлык хисе... юк ул бездә**

Фәния Исхакова:
34 **"Мин кияүгә шәһәр башлыгына чыкмадым..."**



Иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни журнал
Оештыручылары: Татарстан Республикасы хөкүмәте һәм редакциянең хезмәт коллективы.

1920 елның декабрь аеннан башлап чыга.



Хиссияте миллия *40*

Телләр сагында - дәүләт *41*

Р. Мөхәммәтдинов.
Без каян килеп чыкканбыз? *44*

Татар дөньясында *47*

Р. Юсупов:
"Тәрбия буенча дәүләт программасы кирәк" *48*

С. Жаксыбаев.
"Казахстан" - Татарстанда *51*

Н. Айтуган.
Егетләр солтаны *52*

В. Минкина.
Ак яулыгым кебек ак калдым *54*

Галиҗанап шигырь! *56*

Мәдәни манзара *58*

Ф. Шиһапова.
Кеше гомере - гасыр ярым *60*

Көлке капчыгы *62*

АЛГА КАРАП

Журналыбызның яңартылган варианты чыга башлауга да берничә ай үтте инде. Берничә сан гына тулы картинаны тудыра алмаса да, инде журналның бүгенгесе һәм киләчәге турында сөйләшергә нигез бар.

Журналның яңа варианты чыга башлагач, без, билгеле, күп төрле фикерләр, күп төрле тәкъдимнәр ишеттек. Күптән түгел үткән редколлегия утырышында да сүз нәкъ менә шул хакта, журналыбызның бүгенгесе һәм үсеш перспективалары турында барды.

Әйтик, матбугат һәм мәгълүмат министры И. Әхмәтҗанов, чыккан саннарыбызга тирән анализ ясап, "Форма, дизайн, полиграфик бизәлеш ягыннан "Татарстан" журналы дөнья стандартларына җавап бирсә дә, эчтәлеген яңарту, баету буенча эшлисе дә эшлисе әле", - дип ассызыклады.

Мәдәният министры М. Таишевның да журналыбызда тирән эчтәлекле, сәнгать проблемаларын белеп язылган профессиональ язмаларны ешрак күрәсе килә. Дәүләт Советының мәдәният һәм милли мәсьәләләр даими комиссиясе рәисе Р. Миннуллин исә журналны укучыларга тагын да якынрак итү мәсьәләсен күтәрде: "Нинди генә катлаулы проблема күтәрелмәсен, журнал укылырга тиеш". Татарстан халык депутаты Р. Вәлиев журналның укучылар санын арттыру проблемасына аеруча игътибар итәргә киңәш бирде. Журналистикабыз тарихын яхшы белгән галим Ф. Әгъзамов: "Бу журнал - яңа тип басма, безнең тарихта мондый журналның булганы юк иде", - диде. Күренекле тарихчы, академик И. Таһировның: ""Татарстан" журналы элек тә халыкка хезмәт итте, бүген дә ул халыкныкы", - дигән сүзләре белән килешмичә мөмкин түгел. Чыннан да, журналыбыз иң элек киң катлам укучыга адресланган. Шуңа күрә дә ""Татарстан" журналы элитар басмамы, әллә гади укучыныкымы?" дигән сорауның куелышы ук урынсыз.

Әйе, "Татарстан", иҗтимагый-сәяси басма буларак, республикабызда барган зур процессларга игътибар итә, сәясәт, икътисад дөньясының иң актуаль проблемаларын күтәрергә тырыша. Әмма бу мәсьәләләр гади халыкны борчымыймыни?

Без республикабыз хакимият органнарының, дәүләт җитәкчеләребезнең эшгамәлләрен киң яктыртып та дөрес эшлибездер. Чөнки болар хакында хәбәрдар булу иң элек гади халыкка кирәк.

Журналыбыз хәзер затлы кәгазьдә, югары полиграфик башкарылышта нәшер ителә. Нәрсә, гади халык өчен чыга торган басмалар затсыз, сыйфатсыз булырга тиешмени?

Шуңа күрә дә "Татарстан" журналы кемнеке?" дигән сорауга без: "Халыкныкы !" дип җаваплыйбыз. Бүген журнал тирәсендә кайбер бәхәсләр бара икән, бу - табигый күренеш. Яңалык беркайчан да җиңел генә юл ярмый. Иң мөһиме - алар барысы да журналга битараф калмауны күрсәтә, аның кирәклеген дәлилли.

Без алга карап эш итәбез. "Татарстан" журналының киләчәге өметле буласына шигебез юк!

Бергә булыйк!

ПРЕЗИДЕНТ

Мәскәүдә очрашулар

2 сентябрьдә АКШның Мәскәүдәге илчелеге резиденциясендә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев Россия сәясәтчеләре төркеме составында АКШ Президенты Б. Клинтон белән очрашты. АКШ Президенты белән әңгәмә барышында ул ике ил компанияләре арасындагы икътисадый һәм сәүдә бәйләнешләренең урнашып килүе, шул исәптән республика икътисадына инвестиция бирү өлкәсендәге хезмәттәшлек турында сөйләде.

Б. Клинтон Россиядә һәм аның төбәкләрендәге социаль-сәяси хәл, финанс һәм икътисадый кризисның нәтиҗәләре турында М. Шәймиев фикере белән кызыксынды. Әңгәмә барышында төбәкләрнең АКШ сәүдә-икътисадый партнерлары белән турыдан-туры хезмәттәшлек итүенең әһәмияте күрсәтелеп үтелде.

* * *

3 сентябрьдә М. Ш. Шәймиев Мәскәүдә республика өчен күп кенә мөһим очрашулар үткәрде. Аерым алганда Мәскәү мэры Юрий Лужков белән очрашты. Аның белән әңгәмәдә Мәскәү заводында Татарстан нефтен эшкәртү һәм башкала базарында нефть продуктларын сату күләмен арттыру чаралары билгеләнде.

Аннары Татарстан Президенты Россия Федерациясе Ягулык һәм энергетика министрлыгы, Россиянең "ЛУКойл" нефть компаниясе җитәкчеләре белән очрашты. Татарстанның Россия Федерациясендәге вәкаләтле вәкиллегендә Минтимер Шәймиев "Дженерал Моторс" автомобиль төзү компаниясе делегациясе әгъзалары белән әңгәмә үткәрде.

Кул куелды

11 сентябрьдә Президент Минтимер Шәймиев Татарстан Республикасында банкротлык һәм финанс хәлен яхшырту эшләре буенча дәүләт органы турындагы Указга кул куйды.

Финанс хәле катлауланып, банкротлык янаган предприятиеләрне яклау, аларның финанс хәлен яхшырту һәм санация үткәрү буенча дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, шулай ук аларны үзгәртеп кору, ябу процедураларын бөлгенлек турындагы законга яраклаштырып башкару шартларын булдыру максатында Татарстан Республикасының бөлгенлек һәм финансны яхшырту эшләре комитеты булдырылды.

Юбилярны котлау

М. Ш. Шәймиев Кремльдә танылган галим, Россия Фәннәр академиясе академигы, Астронавтика халыкара академиясенең хакыйкый әгъзасы, техник фәннәр докторы, үзенең 75 яшен билгеләп үтүче Вячеслав Алемасовны кабул итте.

В. Алемасов ракета двигательләрендә югары температуралы сиземле мохитләр һәм процессларның составын, үзенчәлекләрен хисаплау, тикшеренүләрдә яна фәнни юнәлеш эшләп, илнең фәнни-техник потенциалын ныгытуга бәя биреп бетергесез өлеш кертте.

ХӨКҮМӘТ

Ыгы-зыгыны ничек бетерергә?

Сумның бәясе төшүгә бәйле сатып алу ыгы-зыгысы Татарстан хөкүмәтен республика базарын, беренче чиратта азык-төлек базарын тотрыкландыру белән якыннан торып шөгыльләнергә мәҗбүр итте. Ыгы-зыгыны бетерүнең иң яхшы ысулы - халык өчен беренче чиратта кирәкле азык-төлек китерүне өзлексез оештыру. Бу проблема 5 сентябрьдә Татарстан Премьер-министры Рөстәм Миннеханов уздырган киңәшмәдә тикшерелде. Анда республикада булган азык-төлекнең төп төрләре барлап чыгылды. Бу шартларда хөкүмәт эшкуарларга азык-төлек кайтаруны оештыруда ярдәм күрсәтәчәк, бартер өчен Татарстан предприятиеләренең сатылачак продукциясеннән товар кредиты биреләчәк.

Карар чыкты, нәтиҗәсен көтик

11 сентябрьдә Министрлар Кабинетының 511 номерлы карарына кул куелды. Шул карар нигезендә физик затлар белән республиканың кыска вакытлы облигацияләре буенча исәп-хисапны алып бару өчен "Ак Барс" банкы хөкүмәтнең вәкаләтле агенты итеп билгеләнде. Кыйммәтле кәгазьләргә инвестицияләнгән акчаны түләү тәртибе турындагы нигезләмә расланды. Шуна нигезләнеп "Ак Барс" банкы гражданнарның кыска вакытлы республика облигацияләрен каплаганнан соң акча түли.

Түләүләр 1998 елның 18 августына кадәр сатып алынган облигацияләр буенча гына башкарыла, чөнки физик затларның кыйммәтле кәгазьләре белән икенчел сәүдә итү 19 августтан аерым күрсәтмә белән туктатылды.

ПАРЛАМЕНТ

Тагын бер закон

23 сентябрьдә, җәйге каникулдан соң, парламентның көзге сессиясе башланды. Депутатлар беренче утырышта "Элемтә турында" закон кабул иттеләр.

Әлеге закон республикада элемтә өлкәсендәге эшчәнлекнең хокукый нигезләрен урнаштыра, дәүләт хакимияте органнарының шушы эшчәнлекне җайга салу буенча вәкаләтләрен, элемтә хезмәте күрсәтүдә катнашучы юридик һәм физик затларның хокукларын, бурычларын билгели.

Киңәшле эш таркалмый

Дәүләт Советы каршындагы вәкаләтле хакимият органнары хезмәткәрләрен укыту һәм белемен күтәрү курслары кысаларында республика, шәһәр һәм район газеталары редакцияләре, радио, телевидение җитәкчеләре, журналистлары өчен семинар үткәрелде. Анда катнашучылар алдында Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин чыгыш ясады. Ул республикадагы сәяси һәм икътисадый хәлне анализлады, кризистан чыгу буенча күрелә торган чараларга киң тукталды, хәзерге кыен шартларда массакүләм мәгълүмат чараларының хәлен җиңеләйтү юнәлешендә нәрсәләр эшләнүен бәян итте.

ИКЪТИСАД

Татарстанны данладың, Ромашкино

Лениногорск шәһәрендә Ромашкино нефть ятмасының 50 еллыгы уңаеннан зур тантаналар узды. Анда илнең төрле почмакларыннан мәртәбәле кунаклар җыелды. Юбилей белән нефтьчеләрне Президент Минтимер Шәймиев котлады.

"Тарихи кыска вакыт эчендә Татарстан Республикасы илебездә һәм чит илләрдә зур нефть төбәге буларак танылды. Татарстанның нефть индустриясе республикада куәтле энергетика базасы, нефть химиясе һәм химия индустриясе булдыру, зур шәһәрләр һәм авыллар салу өчен шартлар тудырды. Бүген, республиканың нефть потенциалына иң югары бәя биреп, без беренче чиратта хезмәт кешеләренә - геологларга, эшкәртүчеләргә, бораулаучыларга, нефть чыгаручыларга, тәзүчеләргә - нефть эшенә фидакарь хезмәтләрен багышлаган барлык кешеләргә ихтирам хисе белдерәбез," - диелә котлауда.

Французлар канәгать

Татарстанның "Бөгелмә фарфоры" акционерлык җәмгыяте үз продукциясен Франциягә җибәрә башлады. Бөгелмәдән түбән температурадагы төсле фарфордан эшләнгән 1 миллион 200 мең савыт-саба китерү турындагы килешүгә кул куелды.

"ТУ-324" халыкара мәйданга чыга

Лондонда Казан авиация берләшмәсендә "ТУ-324" самолеты булдыруга кагылышлы килешүгә кул куелды. Сүз Казан авиация берләшмәсенең булачак самолеты өчен көч җайланмасын эшләү һәм Казанга тапшыру турында бара. Документка Татарстан Премьер-министры киңәшчесе Назир Киреев, Туполев исемендәге АНТК генераль директоры Василий Александров, икенче яктан "Вибро Мэтр" җитәкчесе Ричард Гривс кул куйды.

Горбунов исемендәге авиация берләшмәсенә чит ил компанияләре белән тагын 11 контракт төзергә кирәк булачак. Проектта Көнбатыш Европа һәм АКШның барлык самолетларын җиһазлауда катнашучы фирманың булуы яхшы фал буларак бәяләнә.

Кунакка ешрак барыгыз

Ульяновск һәм Чаллы халкы хәзер бер-берсенә кунакка ешрак йөрер инде. Чаллы - Зәй - Нурлат - Кошки - Ульяновск автобус маршруты ачылды.

Һималайдан эшкуарлар килде

Татарстан Республикасы сәүдә-сәнәгать палатасында Непал корольлегеннән килгән эшкуарлар белән очрашу үткәрелде. Һималай кунаклары визитының максаты республика базары белән танышу иде. Непаллылар бездән ашлама, полиэтилен, битум, металл сатып алырга әзер. Ә үзләре татарстанлыларга кием-салым, ювелир әйберләре, кулдан эшләнгән келәмнәр тәкъдим итәләр.

БӘХЕТ ЕЛМАЙДЫ

Ватан алдындагы хезмәтләре өчен

Дәүләт алдындагы хезмәтләре, күп еллар буе намуслы эшләгәне өчен "Алга" укыту-производство предприятиесе акционерлык җәмгыяте директоры Әнвәр Шакир улы Иванов II дәрәҗә "Ватан алдындагы хезмәтләре өчен" ордены белән бүләкләнде.

Радиода яңа җитәкче

Татарстан Министрлар Кабинеты карары белән Миләүшә Ләбиб кызы Айтуганова "Татарстан" дәүләт телерадиокомпаниясе рәисе урынбасары итеп билгеләнде. Ул республика радиосына җитәкчелек итәчәк.

Миләүшә - тәҗрибәле радиожурналист, күп еллар буена шушы компаниянең яшьләр редакциясендә эшләде. Тарих фәннәре кандидаты.

"Заман"да яңа мөхәррир

Туфан Хәсән улы Доган "Заман - Татарстан" газетасының яңа мөхәррире итеп билгеләнде. Ул Кара дингез буендагы Трабзон шәһәрендә туган, Измирдагы Эгей университетының авыл хуҗалыгын механикалаштыру факультетын тәмамлаган. Ак Сарай шәһәрендә ике ел "Заман" газетасы мөхәррире булып эшләгән. Аннары шул ук вазыйфаны Казагыстанда да, Истанбулда да башкарган.

Туфан Доганга 34 яшь.

Гасыр кешесе

Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, филология фәннәре докторы, профессор Фуат Ганиевка Кембридж халыкара биографик үзәгеннән сертификат килде. Анда, филология фәненә зур өлеш кертүен искә алып, Ф. Ганиевка "XX гасырның атаклы кешесе" дигән исем бирелде, диелгән.

Пленум карар итте ...

Татарстан Республика партиясенең киңәйтелгән пленумында партиянең яңа җитәкчесе итеп күренекле сәясәтче, Татарстанның беренче Премьер-министры, Дәүләт Советы президиумы әгъзасы Мөхәммәт Сабиров сайланды.

КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР, УТЫРЫШЛАР

Европа вәкилләре Румыниягә җыелды

23 сентябрьдә Румыниянең Яссы шәһәрендә Европа төбәкләре ассамблеясе оештырган халыкара конференция үткәрелде. Анда Европаның 20 иленнән делегатлар, шулай ук Европа Берлеге, Европа Советы, ОБСЕ һәм башка оешмалар вәкилләре катнашты. Татарстан конференциягә Президент аппараты җитәкчесе Ә. Гобәйдуллин җитәкчелегендәге делегацияне җибәрде.

Еллык нәтиҗәләр куанычлы

Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитетының еллык утырышы булды. Анда икенче Бөтендөнья татар конгрессыннан соң үткән берьеллык эшчәнлеккә йомгак ясалды. Конгресс идеяләре һәм карарлары милли хәрәкәтне үстерүдә, татарларның милли аңын уятуда, татар җәмгатьчелеген берләштерүдә гаять зур роль уйнады.

Бүген Җир шарының төрле почмакларында 130 дан артык татар иҗтимагый оешмасы бар. Шуларның 41е Бөтендөнья татар конгрессына керә.

Тупламада редакция хезмәткәрләре һәм "Татар-Информ" хәбәрләре файдаланылды.



МӨЛКӘТЛЕ ДӘҮЛӘТ – БАЙ ДӘҮЛӘТ

Базар мөнәсәбәтләре безнең яшәешебезгә җитди үзгәрешләр алып килде. Гасырлар буе тупланган байлыгыбыз дәүләт һәм җәмгыяви структураларга бүленде. Бу уңайдан безнең хәбәрчебез Татарстан Республикасының Дәүләт мөлкәте белән идарә итү дәүләт комитеты рәисе урынбасары Илдар Сәйфулла улы ХӘЙРУЛЛОВКА берничә сорау белән мөрәҗәгать итте.

- Илдар әфәнде, дәүләт милкенең бер өлешен хосусыйлаштыруга да инде шактый вакыт узды. Бүген бу комитетның вазыйфасы нәрсәдән гыйбарәт?

- Дәүләт комитетының бурычлары шактый киң: ул мөлкәтне хосусыйлаштырудан тыш, дәүләт акцияләре пакетлары, күчемсез милек белән идарә итә, фонд базары үсешенә, дәүләт карамагындагы предприятиеләр җитәкчеләренең эшчәнлегенә контроль урнаштыра, аларны билгеләп куя.

- Татарстанның мөлкәтне хосусыйлаштыру программасы Россиянекеннән яки күрше төбәкләрнекеннән кайсы ягы белән аерылып тора?

- Беренчедән, Татарстан Республикасының милекне хосусыйлаштыру турындагы законы кешеләргә льготалы хосусыйлаштыру хокукын бирә. Россия Федерациясеннән аермалы буларак, бездә "алтын акцияләр" белән эш итү хокукы бермә-бер киңәйтелде. Дәүләт өлеше 25 проценттан да ким булмаган акционерлык җәмгыятьләре өстәмә акцияләр чыгара алалар. Шул ук вакытта предприятиеләр акциясе әйләнешенә чикләүләр мөмкинлеге дә калдырыла. Моның җөмһүриятебез икътисадына тәэсире гаять көчле. Хосусыйлаштыруда Татарстан Республикасының Дәүләт мөлкәте белән идарә итү дәүләт комитеты вазыйфаларының бер өлешен аерым министрлыкларга, ведомстволарга тапшыру мөмкинлеге дә күздә тотыла. Бу инде хосусыйлаштыру вакытында тармакның үзенчәлекләрен һәрьяклап исәпкә алу дигән сүз. Мондый гамәлләр Элемтә, Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыклары белән тормышка ашырыла башлады да инде.

Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы арасында хакимият вәкаләтләре чикләрен билгеләү һәм үзара вәкаләтләр бүлешү турындагы Шартнамәгә, шулай ук мөлкәт турындагы Килешүгә таянып, без, Россиянекеннән аермалы буларак, хосусыйлаштыруның беренче этабын уңышлы уздырдык. Аермалыкның төп билгеләре түбәндәгечә:

- мөлкәтнең бәясен билгеләүдәге үз методикабыз (базар бәяләренең үзгәрүенә карап мөлкәтне хосусыйлаштыру бәясен дә арттыру ягына таба берничә тапкыр карарга туры килде), ә ул башлангыч чорда Россиянекенә караганда - 20, алга таба 60 тапкырга һәм аннан да күбрәккә артты;

- хосусыйлаштыруны хезмәт коллективлары аша, льготалы шартларда үткәрүдә Россия Федерациясенең хосусыйлаштыру чеклары (ИПВ) һәм Татарстан Республикасының исемле вкладлары, гади акция пакетлары (уртача 40 процент чамасы) файдаланылды;

- Татарстан Республикасы Президенты Указына туры китереп, җөмһүриятебез гражданнары өчен, алар кулындагы чекларга (ИПВ), номиналь бәя белән, яхшы исәптә йөрүче предприятиеләрнең акцияләренә ирешү мөмкинлеге тудырылды;

- льготалы шартларда алынган акцияләрне сатуны яки башка юллар белән

урнаштыруны өч ел дәвамында чикләп тору каралды;

- республикабыз район һәм шәһәрләрендә күчемсез милекне, транспорт җайланмаларын, башка мөлкәтне сатуның күптөрле аукционнарын үткәрү каралды. Юридик һәм физик затлардан алынган чекларга (ИПВ) аукционда номиналь бәядән 9,7 мәртәбә югарырак түләү кулланылды.

Болар исә республиканың 1,5 миллион гражданына хосусыйлаштырылган предприятиеләрнең акционерлары булу мөмкинлеген тудырды. Шул ук вакытта күләгәдәге структураларның үтеп керүенә юл ябылды. Чөнки хосусыйлаштырыла торган мөлкәтнең бәясе алар өчен көч җитмәслек нәрсәгә әйләнде. Бу инде җөмһүриятебездә сәяси һәм икътисадый тотрыклылыкны ныгытуда мөһим фактор.

Үзгәртеп коруларның башлангыч этабында үткәрелгән хосусыйлаштыру республика икътисадында күренекле урынны алып тора, ул, нигездә, дәүләтнеке булмаган секторларга һәм мөлкәтнең акционерлык формасына карый. Россия кануннары буенча, дәүләт мөлкәте буларак, тиешле карарлар белән ныгытылмаган акцияләр пакетын, аукционнарда хосусыйлаштыру планнары раслаганнан соң бер ай үткәч кенә тормышка ашырыла. Хосусыйлаштыру турындагы элеккеге законнарда андый норма каралмаган иде. Фонд базарының тиешенчә үсмәвен һәм камиллектән ерак торуын искә алып, хезмәт коллективлары тарафыннан сатып алынмаган акцияләр ашыгычлык белән урнаштыруны без кирәкле эш дип санамыйбыз. Бу исә безгә акцияләр урнаштыруны, кирәк чакта, инвесторларга яки төрдәш предприятиеләргә аукционда яисә инвестиция һәм коммерция конкурсларында, икътисадның торышына карап, бераз кичектерергә мөмкинлек бирә.

- Торакны бушлай хосусыйлаштыру вакыты тагын бер елга озынайтылды. Моның сәбәбе нәрсәдә?

- Җөмһүриятебездә торакны хосусыйлаштыру башланганнан бирле 430 меңнән артык гаилә үзләренең фатирларын хосусыйлаштырдылар. Бу - барлык дәүләт торак фондының 60 процентын тәшкил итә. Белгечләр исәпләвенчә, хосусыйлаштырылган фатирларның дәүләт һәм муниципаль торак фондына нисбәте 60-65 процент булырга тиеш. Димәк, ел дәвамында республиканың кайбер шәһәрләрендә һәм Казан каласында бу биеклеккә ирешеләчәк.

- Татарстанда хосусыйлаштыруның яңа программасы кабул ителде. Аның яңалыгы нәрсәдә соң?

- Программада каралганча, хосусыйлаштыру инициативасы белән теләсә нинди юридик һәм физик затлар чыга ала. Бу исә инвестицияләр агымын шактый арттырачак.

Тагын шунысы бар: әлеге эшне башлап йөрүче "инициатив төркемнәр"гә мәгълүм дәрәҗәдә льготалар да каралган. Килешү шартларына туры китереп, аларга акцияләрнең 30 процентын сатып алырга хокук (опцион) бирелә һәм номиналь бәянең 30 проценты күләмендә ташлама ясала. "Инициатив төркем" хосусыйлаштыру планын үтәү һәм предприятиене икътисадый кризистан чыгару турында үз өстенә йөкләмә дә ала.

Дәүләт комитеты хосусыйлаштырылырга тиешле предприятиеләр исемлеген шактый киңәйтте. Программада каралганча, сәүдә, туклану һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү предприятиеләре, нинди ведомствода булуларына карамастан, барлык төр биналары белән хосусыйлаштырыла яки 10 елдан да ким булмаган срокка арендага бирелә, берүк вакытта аны сатып алу хокукы да калдырыла. Дәүләт карамагындагы специальләштерелгән икмәк һәм сөт кибетләре икмәк һәм сөт заводларына сатып алу хокукы белән озак сроклы (10 елга чаклы) арендага бирелә. Бу исә хезмәт коллективына мая туплап, алга таба предприятиене түләем сатып алырга мөмкинлек тудыра.

Хәзерге вакытта без, сынау тәртибендә, социаль-мәдәни һәм медицина объектларының аерым өлешләрен хосусыйлаштыруны гамәлгә куйдык. Әлбәттә инде, тиешле министрлык һәм ведомстволар белән килешеп. Тупланган тәҗрибә киләчәктә, әйтик, 2000 нче елдан соң, бу төр оешмаларны хосусыйлаштыру концепциясен эшләүдә кулланылачак.

- Имеш-мимешләргә караганда, кайбер мафиоз структуралар, хосусыйлаштыру битлеге астында, төрле ярдәмендә, шактый дәрәҗәдә дәүләт мөлкәтен эләктереп калдылар. Мондый сөйләшүләр нигезлеме?

- Җөмһүриятебездә башланып киткән хосусыйлаштыру хәрәкәте баштан ук социаль характерда иде. Моның өчен, Россия чекларыннан тыш, Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, исемле хосусыйлаштыру кертемнәре (вкладлары) кулланыла башлады. Аның белән ярыйсы гына исәптә йөргән предприятиеләрнең акцияләрен алырга мөмкинлек тудырылды. Бигрәк тә пенсионерлар һәм бюджет оешмаларында эшләүчеләр номиналь бәяләрдән файдаландылар. Имеш-мимешкә килгәндә, контрольсез, шулай ук льгота белән сатып алынган акцияләрне чикләү һәм читләштерү бернинди алдау-хәйләгә дә юл калдырмый. Хосусыйлаштыру барышы массакүләм информация чараларында киң яктыртыла. Шуңлыктан дәүләт мөлкәтенең мафиоз структуралар кулына күчүе турындагы гайбәтләр дөреслеккә туры килми.

"Алтын акцияләр" бары тик республика икътисадын күтәрүгә, социаль җитмәүчелекне тулыландыруга, милли куркынычсызлыкны тәэмин итүгә юнәлдерелгән. Әмма без "алтын акцияләр"дән бик сирәк очракта, предприятиене юкка чыгару чарасына килеп терәлгәч кенә файдаланабыз.

- Шулай да хосусыйлаштыру программасы гади халыкка нәрсә бирә?

- Югарыда әйтелгәнчә, бүгенге көнгә республиканың 1,5 миллион гражданы хосусыйлаштырылган предприятиеләрнең акционерлары булдылар. Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә, җөмһүриятебезнең барлык гражданнары өчен дә үзләрендәге чекларны (ИПВ) танылган предприятиеләрнең акцияләренә алыштыру мөмкинлеге бирелде. Билгеле булганча, "Оргсинтез", Казан вертолет заводы, "Татнефть" һәм башка акционерлык җәмгыятьләре акцияләренә фонд базарында сорау аеруча зур. Күп кенә гражданнар, акцияләрен файдаланып, күчемсез милеккә, автотранспортка һәм көнкүреш техникасына ия булды.

- Бүген инде шактый гына керем бирүче элегрәк хосусыйлаштырылган предприятиеләрне яңадан дәүләт карамагына алу турында сүз бара. Сез моңа ничек карыйсыз?

- Бу мәсьәләдә бик сак эш итәргә кирәк. Ник дигәндә, акционерлык җәмгыятьләре структурасы инде ныклы бер юлга салынды, ул шәхсилекне гәүдәләндерә. Аны таркату дәүләткә ышанмаучылыкны тудырыр иде. Чыннан да без кайбер акционерлык җәмгыятьләрендә дәүләт өлешен үстерә барабыз. Шуна күрә аларның акцияләре дә тотрыклылана. Бу бигрәк тә бюджетны тулыландыру, хезмәт хакын һәм пенсияләрне түләү өчен кирәк.

Хәзер бурычка баткан предприятиеләрне реструктуризацияләү турында күп сүз бара. Әйтик, җир мәйданнарының уставта каралган бәясен билгеләгәндә дәүләт өлеше шактый арта. Дәүләт мөлкәтен кире кайтару хакында сөйләгәндә без бары тик "эшләре барып чыкмаган" акционерлык җәмгыятьләрен, әгәр акцияне сатып алу процессын 2-3 ел буе башкара алмаганда гына мәсьәләне кабыргасы белән куябыз.

- Дәүләт кулындагы милек һаман кими бара. Киләчәктә сезнең комитетның кирәге калырмы?

- Татарстан Республикасының Дәүләт мөлкәте белән идарә итү дәүләт комитетының тагын бер төп бурычы бар, ул дәүләт мөлкәте белән файдалы юнәлештә идарә итүдән гыйбарәт. Боларга акция пакетлары, аларны урнаштыру, мөлкәтне арендага, залогка бирү кебек төшенчәләр керә.

Шуна да без бүген Татарстан Республикасы мөлкәте белән идарә итү концепциясен эшлибез. Дәүләтебез мәнфәгатьләрен күздә тоткан хәлдә, базар мөнәсәбәтләре шартларында яңа программаларны тормышка ашырырга җыенабыз.

- Мөлкәтле кеше - бай шәхес. Сез баймы соң?

- Мин шулай уйлыйм: теләсә кемнең төп байлыгы - аны чолгап алган кешеләр, аңа карата күрсәтелгән хөрмәт, гаиләсе, балалары, инсанның эчке дөньясы, үз эшеннән канәгатьлек алуы, узган тормыш юлының матурлыгы...

- Матур сүзләрегез өчен рәхмәт!

Әңгәмәдәш - Госман ГОМӘР.

Солтан ИСХАКОВ фотосы.



Нургали БУЛАТОВ,
журналист.

Рим Шагали улы МОСТАЕВ - Татарстан Республикасы хәрби комиссары.

ҮЗ КЕШЕБЕЗ

Ул ничектер беренче карашка ук синең ихтирамыңны яулап ала. Мөгаен, моңа эчкерсез итеп елмая, өлкәннәрчә ике куллап күрешә, кешене бик игътибар белән тыңлый белүе сәбәпчедер. Аның һәр соравына татарча җавап бирергә тырышуы да күңелгә бик якын тоела.

Ә бит Татарстан Республикасының яңа хәрби комиссары генерал-майор Рим Шагали улы Мостаев туган якларында (ул 1949 елда Апаста туган) утыз еллап булмаган. Орджоникидзеда Югары командалык гомумгаскәр хәрби училищесын тәмамлагач, яшь офицер төрле төбәкләрдә хезмәт итә. Төньяк төркеме гаскәре составында Польшада, Урта Азия хәрби округында, Әфганстанда була...

Менә шулай татар егете хәрби баскычлардан һаман югары үрмәли. Ул башта М. В. Фрунзе исемендәге Хәрби академиядә белемен арттыра, аннары Генеральный штаб академиясен алтын медальгә тәмамлый. Туган төбәгенә хәрби комиссар булып кайтыр алдыннан генерал Р. Мостаев Ленинград хәрби округындагы 6 нчы армия командующиеның беренче урынбасары була. 50 яше дә тулмаган генерал ике Сугышчан Кызыл Байрак, ике Кызыл Йолдыз һәм III дәрәҗә "Ватанга хезмәт иткән өчен" орденнары, күп медальләр белән бүләкләнергә өлгергән инде.

- Туган төбәкләргә кайту күптәнге хыялым иде. Кораллы Көчләрдә реформа үткәрәбез дип, 6 нчы армияне бөтенләй таратып бетергәч, һич көтмәгәндә җай да чыкты. Миңа Татарстан Республикасы хәрби комиссары урынын тәкъдим иттеләр, - ди Рим Шагали улы.

Генерал-майор Р. Мостаевның Татарстан Республикасы тарихындагы икенче татар комиссары булуын да әйтергә кирәк. Аның беренчесе Мамадыш районының Албай авылында туып-үскән керәшен егете, гражданнар сугышы герое, өч Кызыл Байрак ордены кавалеры Степан Домолазов иде. Яңа хәрби комиссарның әтисе Шагали Мәрдән улы Оренбург өлкәсендәге Красный Ключ бистәсендә, әнисе Нурия Сәлах кызы Казанда туып-үскәннәр. Шагали Мостаевны Татарстанның Әгерҗе, Аксубай, Апас, Тәтеш районнарында өлкән буын кешеләре әле хәтерлидер. Ул бу төбәкләрдә хәрби комиссар була.

- Минем хәрби профессияне сайлавым очраклы гына булмады, билгеле. Балачактан ук өйдә алтын йөгертелгән погоннар, хәрби китель һәм шинельләр, хром итекләр күреп үс тә башка һөнәр сайла инде! Ул мөмкин түгелдер. Бертуганым Риф та офицер булды. Полковник дәрәҗәсендә запаска чыкты инде, - дип искә ала генерал.

Рим Шагали улы үзенең бурычын егетләребезне Россия Кораллы Көчләренә җыеп җибәрүдә генә күрми. "Туган илне ярату хисен тәрбияләүне беренче итеп куярга кирәк", - ди ул. Моның өчен Мәгариф министрлыгы, Балалар һәм яшьләр эше буенча дәүләт комитеты белән бергәләп, мәктәпләрдә һәм башка төр махсус уку йортларында хәрби-патриотик тәрбия бирүне, физкультура һәм спортны нык көчәйтергә кирәк, дип саный. Шулай ук егетләребезгә ОСТО курсларында тыныч тормыш өчен дә файдалы һөнәрләр бирүне киңәйтү турында янып йөри.

- Хәзер Россия армиясенә хәрби хезмәткә барудан баш тартучылар бик ешайды. Сез моңа ничек карыйсыз? - дип сорыйм генералдан.

- Һәр егет кеше хәрби хезмәт срогын узарга, туган ил сакчысы булырга әзерләнергә тиеш. Бу - минем чын күңелдән ышанып әйтүем һәм үзебезнең татар егетләренә аталарча киңәшем, - ди Рим Шагали улы.

Теләсә нинди дәүләткә аның амбарындагы ашлыгына һәм армиясенең куәтенә карап бәя бирәләр. Бу яктан Россиянең хәле бик мөшкел. Ул ашлыкны чит илдән сатып ала, Кораллы Көчләре инде таркалып беткән. Менә шундый хәлдәге армия һәм флотның абруен күтәрәсе иде. Төньяк Атлантика блогы илләре Россия белән түбәнсетеп сөйләшерлек булмасын. Аны бөтен яктан диярлек "киләшчә"гә алган бер заманда безнең Кораллы Көчләр ил дошманнарын бик тиз айнытa алсын.

...Татарстан Республикасы хәрби комиссары генерал-майор Рим Шагали улы Мостаев әнә шундый матур-матур планнар белән янып йөри. Ул Кораллы Көчләр һәм сугыш ветераннары белән еш очраша, районнарга барып чыга...

Госман ГОМӘР,
икътисад бүлеге
мөхәррире.

Җәүдәт Аппау улы ГАФУРОВ - Чүпрәле районы хакимияте башлыгы.

Җир улы

Юк. Ялгышасың, барсы да
Дошман түгел,
Бар синең дустың, бар ул,
Ул гали, ул ак күңел...

(Һади Такташ.
"Җир уллары трагедиясе"ннән).

Җәүдәт Гафуров та үзен җир улларыннан берсе дип исәпли, ак күңел, саф күңел белән яши. Яшь хаким өчен дошман да, хаин-катил дә юк дөньяда, ул һәркемне тигез күрә, әйләнә-тирәдәгеләргә зур ышаныч белән карый. Бу сыйфатлары аны халкы итә, башкалардан бер башка үстереп җибәрә.

Шул ук Такташтагыча, "Җырланасы җырлар" турында, алдагы тормыш хакында шагыйрь сүзләрен кабатлыйм ул:

Туасы таңнарның кояшына
Мактау җырлап елны башлыйбыз,
Без елларга табан атлыйбыз!
Ел артыннан туган елга табан
Күчәр безнең көчле нәселләр.

Әйе, хәзерге буын яшьләре көчле нәселлеләр токымыннан. Мин монда гарип җанлы, мафия битлегеннән йөрүче кайбер җилкуарларны күздә тотмыйм, алга олы максатлар куеп, илаһи биеклеккә омтылучы күпчелек яшьләребез турында әйтәм. Җәүдәт Гафуровны нәкъ менә соңгылары исәбенә кертергә кирәктер.

Чүпрәле районының Иске Ишле авылы. Алдынгы колхозчы Гафуровлар гаиләсе. Аппау абзый белән Мөзәйзинә апаның 11 баласы тупырдап үсә. Шулар арасында җитезлеге, уңганлыгы, киң күңеллелеге белән Җәүдәт беркадәр аерылып тора шикелле. Укырга хирыслыгы көчле була малайның. Үз авылларында сигезьеллыкны тәмамлагач, Кәкерле урта мәктәбенә йөреп укый башлый. Мәктәп еллары да артта кала. Өлгергәнлек таныклыгында гел әйбәт билгеләре булгангамы, әллә мөгаллимлек сәләте ташып торгангамы, район мәгариф бүлеге аны укытучы итеп билгели. Балаларны авызына никадәр генә каратмасын, Җәүдәтнең бәгырен "җир улы" дигән корт кимерүдән туктамый. Һәм ул карар кыла: укытуны ташлап, Казан авыл хуҗалыгы институтының (хәзер академия инде) агрохимия факультетына барып керә.

Югары уку йортында тормыш башкачарак, әлбәттә. Лекцияләр, практик дәресләр, фән яңалыклары, кичләрен спорт күнекмәләре. Таза авыл егете герен дә, штангасын да күтәрә, татарча көрәш белән дә шөгыльләнә. Авылга ул галим-агроном дигән диплом алып кайта. Үзләренең "Алга" колхозында агроном булып эшли башлый. Нибары 4-5 ай эшләп кала - аны хәрби хезмәткә алып китәләр. Армиядән кайткач, беркадәр вакыт һөнәре буенча Ульяновск өлкәсендә эшләп ала. Аннары Чүпрәле үзәгендәге "Россия" колхозының баш агрономы була. Биредә ул 5 ел хезмәт куя. Ары таба тормышта сигезәр еллык сәхифәләр язылa. Туган колхозы "Алга"да рәислек, район авыл хуҗалыгы идарәсендә җитәкче. Сигезәр ел дип әйтергә генә ансат бит ул. "Алга" колхозы иң эре хуҗалыклар иде ул чакта. Хуҗалыкның икътисадын күтәрүгә аз көч куймады Җәүдәт. Игенчелектә югары күрсәткечләр яуланды. Шикәр чөгендере үстерү буенча да уңышлар куанырлык иде. Мөгезле эре терлекләр саны 2000, савым сыерлар - 500, дуңгызлар - 3500, сарыклар 2000 баштан артып китте. Колхоз кассасына акча әнә шулардан керде. Нәтиҗәдә төзелеш эшләрен киң җәелдерергә мөмкин булды. Хәзер инде бу эре хуҗалык "Маяк", "Алга", "Таң" колхозларына бүленде. Һәрберсе үз маркасын сакларга тырыша.

Район авыл хуҗалыгы идарәсенә җитәкчелек итү үзе бер тарих. Монда инде бер хуҗалыкка гына түгел, бөтен район өчен җаваплы син. Уйлап кына карагыз, "Чүпрәле җиренә тәртә кадап китсәң, тарантас үсеп чыга" дигән әйтемгә ышанып, озак еллар буе туфракка минераль ашламалар кертүгә игътибар бирелмәде. Җирнең җегәре елдан-ел кимеде. Менә шуны истә тотып, идарә җитәкчесе туфракны ашлауга аерача игътибар итә.

Быелгы көйдерүне генә искә төшерик. Ашламасын да кулланмасаң - харап иде бит эшләр. Агротехника таләпләрен төгәл үтәгән "Цильна" колхозы, мәсәлән, бөртекле-кузаклы культураларның һәр гектарыннан уртача 25 центнер уңыш җыеп алды. Сүз уңаеннан әйтик, бу хуҗалыкка тәҗрибәле игенче Җәүдәт әфәнденең бертуган абыйсы Борис Гафуров җитәкчелек итә.

Районга яңа хаким билгеләү мәсьәләсе килеп тугач та, беренче итеп Җәүдәт Аппау улы Гафуров исеме телгә алына. Бу тәкъдимне җирле Совет депутатлары да хуп күрәләр. Яңа хезмәттә да сынатмый яшь хаким. Районны тоташтан газлаштыру эшен җәелдереп җибәрде. Соңгы берничә айда гына да 100 километрга газ торбалары сузылды. Яңа елга кадәр тагын 1000 йортка газ кертеләчәк. Авыллар арасында 30 километрга асфальт юл салынды. Бу якларда күрелмәгән зур шифаханә комплексы төзелеп бетеп килә. Тагын ике мәктәп сафка басарга тора. Район үзәге барлык уңайлыклары булган күпкатлы йортлар, уңайлы коттедж-өйләр белән бизәлә. Барысы да җир улларының хезмәте, көчле нәселлеләргә күчәчәк мирас.

Уңышлар сиңа, Җәүдәт әфәнде!

Эдвард ХӘКИМОВ фотолары.

Әгъзам ФӘЙЗРАХМАНОВ,
баш мөхәррирнең беренче урынбасары.

ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТКӘРЕ

Татарстан Республикасы Конституциясенең өченче маддәсендә шундый сүзләр бар: "Татарстан Республикасы сәяси, икътисадый, социаль һәм мәдәни тормышының барлык тармакларында гражданнарның тигез хокуклылыгын гарантияли".

Бер көнне шулай оныгымнан бакчада нәрсәләр ашаулары хакында сорашып утырдым. Ул тезеп китте:

- Ботка, токмач, бәрәңге, чәй...
- Сөт бирәләрме соң? - дим.
- Биргәлиләр, - ди бу.
- Ә ит, каймак?
- Кайсы көннәрдә бирәләр.
- Күп бирәләрме соң?
- Ничек күп бирсеннәр инде, бабай? Күп бирсәң, барысына ук җитми бит ул.

Хикмәт менә шунда шул. Бирәү умырып алгач, башкасына җитми. Кәмнәрдер "яхшыртылган планировкалы" йортларда яшәгәч, кайберәүләргә подвалда торырга туры килә. Барысына акча ничек җиткерәсең ди?!

Мин чиновниклар начар яшәсен дигән карашта тормыйм. Рәхәтләнеп бай яшәсеннәр. Әмма гомере буе тирләп-пешеп продукция җитештергән, табышының күпчелек өлешен шушы чиновникны асрау өчен салым рәвешендә биргән эшченең дә бай яшәвен тәэмин итәргә кирәк. Бу турыда инде хөкүмәт исәбенә хатыны, бала-чагалары белән чит илләрдә ял иткәндә дә, коттедж төзеткәндә дә, шактый надан кызын университетка төрткәндә дә чиновник уйланырга тиеш. Үзенең ни дәрәҗәдә гадел булуын намус бизмәненә салса иде ул.

Кайбер законнар да гаделсезлеккә этәрә. Дөресрәге, алар гаделсезлекне законлаштыра. "Дәүләт хезмәте турында"гы Закон моның ачык мисалы. Әлеге закон чиновниклар хезмәтен гади халыкныкыннан берничә тапкырга югарырак бәяли. Әйтерсең лә, алар тәүлегенә 25 әр сәгать эшлиләр.

Грамматик кагыйдәләргә нигезләнеп караганда дәүләт хезмәткәре дәүләткә хезмәт итүче буларак аңлашыла. Бактың исә күпме генә тырышып дәүләткә хезмәт итсәң дә, сине дәүләт хезмәткәре дип санамыйлар икән. Гомере буе дәүләткә, халкына хезмәт иткән журналист дәүләт хезмәткәре түгел. Журналның баш мөхәррире дә дәүләт хезмәткәре түгел. Хәтта абруе бөтен дөньяга танылган Казан дәүләт(!) университеты профессоры да дәүләт хезмәткәре түгел. Халыкка аң-белем бирүче укытучы да, сине үлем тырнагыннан йолып калучы табиб та, икмәк үстерүче дә, күренекле артист та дәүләт хезмәткәре түгел. Нигә түгел?!

Бүгенге көндә 39 депутат парламентта даими эшләсә дә, бик мөһим, беренче дәрәҗәдә әһәмиятле законнарыбыз әлегә кабул ителмәгән. Татарстанның суверенлык Декларациясе кабул

ителүгә сигез елдан артык вакыт үткәннән соң да, без үзебезнең кем гражданы булуыбызны билгели алмыйбыз. Законнарыбыз юк. Суд системасы, прокуратура, Дәүләт куркынычсызлыгы комитеты турындагы законнар эшләнмәгән. Ә менә "Дәүләт хезмәте турында"гы Законны Конституция кабул ителеп бер ел да өч ай һәм ике көн үтүгә эшләп бетереп, гамәлгә кертеп тә куйдылар. Нык тырыштылар! Җитәкчеләр һәм аларга турыдан-туры хезмәт күрсәтүчеләр өчен бөтен уңайлыкларны тудыра ул закон.

Университетта бергә укыган сабакташым диплом алгач авылга балалар укытырга китәргә теләмәде. Таныш-белешләре ярдәмендә комсомолның Казан шәһәр комитетына инструктор булып урнашты. Югыйсә уку чорында активлыгы да, оештыру сәләте дә сизелми иде. Комсомолдан яше чыга башлагач, политик мәгариф йортына референт итеп күчерделәр үзен. Анда бераз тамырларын җибәргәч, партия өлкә комитетына инструктор итеп күтәрделәр. Әмма кайда гына утырса да, әллә ни эш күрсәтә алмады. Хәер, үзе өчен аз тырышмады. Безнең кебек мәхлуклар әле тулай торакларда яшәгәндә шәһәр үзәгеннән өч бүлмәле фатир алды. Малае бераз үсә төшкәч, фатирын аңа калдырып икенчесенә күчте. Кызы кияүгә чыккач, бу фатиры да тараеп калгандай тоелды. Кызы белән киявенә анысын туй бүләге буларак калдырды да, хатыны белән дүрт бүлмәлегә күчеп китте. Җае чыкканда хәтта балконыбыз да икәү дип мактанырга ярата ул. Ашау-эчү байдан ук булмаса да, аның шактый өлеше арзан бәягә өлкә комитеты ашханәсеннән иде. Командировкалардан да буш кайтмады. Җәйге ялын Кырымда һәм чит илләрдә үткәрергә күнекте.

Партия таркатылгач та эшсез калмады. Өлкә комитетында кайчандыр бергә эшләгән хезмәттәшләре хөкүмәт структурасына урнаштырдылар үзен. Пенсия яше җиткәнче шунда буталып йөрде. Хәзер ике мең сумга якын пенсия ала. Чөнки ул закон нигезендә дәүләт хезмәткәре исәпләнә.

Шулай да дәүләт хезмәте дип нәрсә атала? Кем соң ул дәүләт хезмәткәре? Законның беренче маддәсендә болай диелә: "Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасында гамәлдә булган башка закон актлары нигезендә дәүләт органнары вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча профессиональ эшчәнлектән гыйбарәт.

Дәүләт хезмәте закон чыгару, башкарма һәм суд хакимияте органнары аппаратларында, шулай ук дәүләт исеменнән аның вазыйфаларын үтәүче һәм Татарстан Республикасы законнары белән дәүләт хезмәтенә кертелгән башка дәүләт органнарында башкарыла". Димәк, совет органнарында, Президент аппаратында, район һәм шәһәр хакимиятләрендә, министрлыкларда, дәүләт комитетларында, алар составына кергән төрле идарәләрдә, бүлекләрдә, судларда эшләүчеләрне дәүләт хезмәткәре дип анларга кирәк. Бу учреждениеләрдә бүлмәдән бүлмәгә кәгазь ташып йөрүчеләр дә, чәй эчүдән бушаганда әз-мәз кәгазь кыштырдатучылар да, төп вазыйфасы үзенең начальнигын елмаеп каршылаудан гыйбарәт булган секретарьшалар да - дәүләт хезмәткәрләре.

Балыклар арасында акулалар да, ташбашлар да булган кебек, дәүләт чиновниклары да эреле-ваклы була икән. Законда алар зурлыкларына карап А, Б, В категорияләре белән билгеләнәләр. Иң зурлары - Конституция, Татарстан законнары нигезендә дәүләт органнары вәкаләтләрен турыдан-туры башкару өчен билгеләнүчеләр. Президент, Премьер-министр, Дәүләт Советы Рәисе, Дәүләт Советында даими эшләүче депутатлар, министрлар, дәүләт комитетлары рәисләре, судьялар...

Икенчеләре - А категорияле урыннарда утыручы затларның вәкаләтләрен үтәүне турыдан-туры тәэмин итү өчен законда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә куелган хезмәткәрләр. Урынбасарлар, идарә, бүлек башлыклары, аппарат җитәкчеләре...

Өченчеләре - дәүләт органнарының вәкаләтләрне үтәвен тәэмин итүчеләр. Референтлар, консультантлар, бүлек



хезмәткәрләре, инструкторлар...

Агымдагы елның беренче яртысында "Дәүләт хезмәте турында"гы Законга иллегә якын төзәтмәләр һәм өстәмәләр кертелде. Аларның күпчелеге дәүләт хезмәткәрләренә төрле ташламалар ясауга юнәлдерелгән иде. Әйтик, 11 нче маддәнең өченче өлеше хәзер шундый: "Отставкага чыккан чакта, тиешле бюджет акчасыннан, эшләгән еллары өчен өстәмә түләүне исәпкә алып, отставкага чыккан көндәге эш урыны буенча вазыйфаи 10 эш хакы күләмендә салым алынмый торган акчалата бүләк бирелә". Законга бары "Эшләгән еллары өчен өстәмә түләүне исәпкә алып" дигән сүзләр генә өстәлгән. Беренче карашка, бу сүзләр игътибарны җәлеп тә итмәскә мөмкин. Әмма өстәмәләрнең күләмен компьютерга салып исәпли башласаң, алар төп хезмәт хакыннан берничә тапкырга артып та китәләр. Моңа инде айлык, еллык премияләр, җәйге ялга киткәндәге өстәмәләр, төрле даталар уңаеннан бүләкләүләр, дәүләт хезмәтенең махсус шартлары, класслы дәрәҗә өчен, озак еллар эшләгән өчен (выслуги лет) түләүләрнең барысы да керә. Гади кеше хыял-

лана да алмый торган сумма килеп чыга. Шуны инде, законда каралганча, 10 га тапкырлап та җибәрсән! Бу акчаны тутырып кайту өчен капчык алып барырга туры килмәгә.

Ә нигә соң мондый тәртип - салым түләүче исәбенә капчыклап акча бирү тәртибе дәүләт хезмәткәре булып исәпләнмәгән кешеләрне пенсиягә озатканда кулланылмый? Гадәттә пенсия яшенә җитүгә кадрлар бүлеге хезмәткәрләре кешеләрне этептөртеп "лаеклы ялга" озату чарасын күрәләр. Көндез чыра яндырып эзләсәләр дә 10 эш хакы күләмендә салым алынмый торган акчаны таба алмый инде алар. Чиновникка салым түләүче исәбенә шулкадәр акчаның түләнүен аңлап та, аңлатып та булмый, билгеле. Әгәр шушы акчаны бирәүгә дә бирмичә, шушы ук күләмдә салымнарны киметкәндә гаделрәк булыр кебек. Әнә дә бүләк, дөя дә бүләк, дигәндәй, яхшы эшләгән чиновникка отставкага киткәндә хезмәттәшләрен хәтердә озак сакласын өчен, бәлки, Мактау грамотасы бирсәң дә җитеп торыр.

8 нче маддәгә өстәлгән 11 нче пунктка игътибар итегез! Дәүләт хезмәткәренең хокукларын санаганда шундый җөмләне өстәп куйдылар: "Тиешле бюджет акчалары исәбенә яңа һөнәргә өйрәнергә (башка белгечлек үзләштерергә) һәм белгечлеген күтәрергә". Дәүләт хезмәткәрен салым түләүче укытырга да тиеш икән бит әле. Ә нигә ул башкалар кебек үз исәбенә укый алмый? Бәлки, ул бюджет исәбенә гомере буе укып йөрергә теләр. Дисталәрчә һөнәр үзләштерү һич тә начар түгел бит. Бу инде студентларның яртысына якыны үзләре түләп белем алган заманда.

Дәүләт хезмәткәренә нинди гамәлләр кылырга рөхсәт ителми соң? Законда алар унау саналган:

- укытучылык, фәнни һәм башка иҗат эшчәнлегеннән гайре, бүтән түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә;
- Татарстан Республикасының закон чыгару органы һәм җирле үзидарә органнары депутаты булырга;
- шәхси яки ышанычлы кешеләр аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, законнарда билгеләнгән очраклардан гайре, коммерция оешмалары органы әгъзасы булырга;
- үзе хезмәттә торган яки турыдан-туры аңа буйсынган, яисә аның тикшерүендә булган дәүләт органында яки җирле үзидарә органында өченче затлар эшләре буенча вәкил яисә ышанычлы кеше булырга;
- дәүләт мөлкәтен, шул исәптән матди-техник, финанс һәм мәгълүмат тәэминаты чараларын хезмәттән тыш максатларда файдаланырга;
- кызыксынган органнар яки затлардан хезмәт вазыйфаларын үтәүгә яки үтәмәүгә бәйле акчалата бүләк, башкача законсыз файда алырга;
- эш ташлауларда катнашырга;
- дәүләт хезмәткәренең эш урынындагы вәкаләтләрен дини берләшмәләр, сәяси партияләр һәм иҗтимагый оешмалар мәнфәгатьләрендә аларга булган мөнәсәбәтләрне пропагандалау өчен файдаланырга;
- эш урынындагы эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәртибендәге чыгышлар һәм басмалар өчен гонорарлар алырга;
- халыкара шартнамәләр яки Татарстан Республикасының дәүләт органнары белән чит дәүләт органнары һәм аларның административ-территориаль берлекләре арасындагы үзара килешүләр нигезендә гамәлгә ашырыла торган хезмәт урыныннан оештырылганнарыннан гайре, юридик һәм физик затлар хисабына чит илгә командировкага чыгарга.

Бу чаралар дәүләт хезмәткәрләрен билгеле дәрәҗәдә закон кысаларында тотса да, алар гарантияләр белән чагыштырганда ат белән черкине янәшә куеп, кайсысы зуррак икән дип тикшерүне хәтерләтә. 13 нче маддәдәге гарантияләр исемлеге 14 пункттан тора. Менә аларның кайберләре: дәүләт хезмәткәренә һәм аның гаилә әгъзаларына, дәваланган өчен сарыф ителгән акчаны тиешле бюджеттан каплап, отставкага киткәннән соң да саклана торган медицина хезмәте күрсәтү; белгечлеген исәпкә алып һәм соңгы эш урынындагы вазыйфадан эш хакын (окладын) саклаган хәлдә, башка дәүләт эш урынына күчерү яки, әлеге вакыт эчендә соңгы эш урынындагы эш хакын саклаган килеш, алты айга кадәр кабат әзерләү (яңа белгечлек бирү), дәүләт органы бетерелгән яки аның штаты кыскартылган очракларда, законнар нигезендә эш белән тәэмин итү; дәүләт хезмәткәре вафат булган очракта аның гаиләсенә тиешле бюджет хисабыннан еллык эш хакы күләмендә берьюлы бирелә торган пособие түләү; хезмәт командировкаларына, дәүләт хезмәтенә кабул итүгә, башка дәүләт органына эшкә күчүгә бәйле рәвештә чыгымнар һәм башка компенсацияләр түләнә, шулай ук болар белән бәйле транспорт һәм торак өчен түләү чыгымнары кире кайтарыла.

Законның 15 нче маддәсе янәдән эшләнде. Әйтергә кирәк, ул чиновниклар өчен гаҗәп мөһим. Элек дәүләт хезмәтендә кимендә 25 ел эшләгән ир-егет, 20 ел эшләгән хатын-кыз пенсиягә вакытыннан алда китәргә, өстәмә түләүләргә хокуклы иде. Хәзер мондый хокукларга ия булу өчен бу стажның яртысы да җитә. Димәк, ирләргә кимендә дәүләт хезмәтендә 12,5, хатын-кызга 10 ел эшләү кирәк. Әмма мондый очракларда дәүләт хезмәткәре отставкага картлык буенча пенсиягә чыгу өчен гомуми билгеләнгән чордан ике елдан да иртәрәк китә алмый. Дәүләт хезмәткәренә картлык буенча дәүләт пенсиясенә өстәмә билгеләнә, бу чакта пенсия (өстәмәләрне, компенсация түләвен исәпкә алып) һәр айлык өстәмә суммасы дәүләт хезмәткәренең эшеннән киткән көнендә яисә пенсия алу өчен гомуми билгеләнгән яшькә җиткән көнендә эш урыны буенча алган акчаларының 55 процентын тәшкил итәргә тиеш. Өстәмә күләме дәүләт хезмәткәренең билгеләнгән минимумыннан тыш дәүләт хезмәтендәге һәр эшләгән тулы елы өчен алган акчаларының 3 проценты күләмендә билгеләнә. Әмма пенсиянең һәм аңа өстәмә түләүнең гомуми суммасы дәүләт хезмәткәре алган акчаларның 80 процентыннан артмаска тиеш. Дәүләт пенсиясенә айлык өстәмәне билгеләү һәм түләү дәүләт хезмәтеннән киткән очракта гына башкарыла.

Дәүләт хезмәткәренә ел саен 30 көнлек түләүле ял бирелә. Дәүләт хезмәтенең аерым төрләренә ял озайтылырга да мөмкин. Дәүләт хезмәтендә 5 елдан 10 елга кадәр эшләгән өчен - 5 көн, 10 елдан алып 15 елга кадәр хезмәт өчен - 10 көн, 15 елдан артыграк хезмәт өчен 15 көн өстәмә ял бирелә.



Квалификация имтиханы яисә аттестация дәүләт хезмәткәренең үзе биләгән эш урынына туры килүен ачыклау, ана класслы дәрәҗә бирүне хәл итү өчен үткәрелә. Дәүләт квалификация имтиханы хезмәткәр таләбе буенча ана чираттагы класслы дәрәҗәне бирү өчен дә кулланыла.

65 яшькә җиткәч дәүләт хезмәтендә калу рөхсәт ителми. Шушы яшькә җиткән кеше эшен вакытлыча дәвам итәргә теләсә, килешү төзи.

Элек дәүләт хезмәте белән идарә итү республика Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаментына йөкләнгән иде. Бу департамент Дәүләт хезмәте мәсьәләләре советына әйләндерелде. Закон нигезендә Совет Президентның, Дәүләт Советының, хөкүмәтнең, суд хакимияте югары органнарының бертигез сандагы вәкилләреннән тора. Совет дәүләт хезмәтенең нәтиҗәлелеген анализлый, норматив актлар проектларын әзерли, аттестацияләр, квалификация имтиханнары уздыруда ярдәм күрсәтә, хезмәткәрләрнең профессиональ әзерлегенә, аларны яңа һөнәргә өйрәтүгә, квалификацияләрен күтәрүгә җитәкчелек итә, югары эш урыннарына күтәрү резервын формалаштыра.

Депутат Ольга Ермакова тәкъдиме белән законга А категорияле дәүләт эш урынын биләүче затларны матди тәэмин итүне җайга салу тәртибе турында махсус маддә өстәлде. Бу адәми затлар вәкаләтләр срогы бетү сәбәпле эштән азат ителгәндә, башка эшкә күчерелгәндә, отставкага чыкканда, дәүләт хезмәтендәге стажының күпме булуына карамастан, картлык буенча дәүләт тарафыннан гомуми нигезләрдә билгеләнгән һәр ай бирелә торган өстәмә түләүне алырга хокуклы. Икенче төрле әйткәндә, мондый ташламаларга ия булу өчен хөкүмәтнең бер составында әгъза булып тору да җитә. Мондый чакта барлык өстәмәләрне кертеп пенсия суммасы ул биләгән дәүләт эш урыныннан киткән көндәге яисә гомуми билгеләнгән пенсия яшенә җиткән көндәге хезмәт хакының 80 процентын тәшкил итәргә тиеш.

Законга өстәмәләр кертүкәндә ризасызлык белдерүче депутатлар шактый булды. Күп кенә сораулар куелды. Әмма аларның барысы да диярлек җавапсыз калды. Әйтик, архивларда һәм китапханәләрдә нигездә бер үк уку йортларын тәмамлаучылар эшли. Эшләренең авырлыгы һәм җаваплылыгы да бер дәрәҗәдә диярлек. Әмма архивчылар дәүләт хезмәткәрләре, ә китапханәчеләр - юк. Татарстанның "баш китапханәчесе" Разил Вәлиевкә моның сәбәбен бирү дә анлата алмады.

Андрей Александров министрлыкта эшләүче бухгалтерның хезмәт шартлары заводта эшләүче бухгалтерныкыннан ни дәрәҗәдә авыр булуын төпчеңде. Бер үк эшне башкарсалар да, хезмәтләренә түләү җир белән күк арасы бит. Шушы булдымы хезмәткә бәя, гаделлек? Шәһәр Советында кәгазь кыштырдатып утырган чиновникка ни өчен пенсия танылган хирургка караганда 4-5 тапкыр артык түләнә?

Фәндәс Сафиуллин үзенә хас кайнарлык белән партия оешмаларында эшләү чорын дәүләт хезмәтенә кертмәскә өндәде. Фикерен бүген партияләрнең күп булуы белән дәлилләде. Пенсияне кешенең кылган гамәлләреннән чыгып түләүнең гадел булачагын, пенсия белән тәэмин итү буенча бердәм система булдыру зарурлыгын белдерде.

Депутатлар арасында фикер уртаклыгы юк иде. Моны таләп тә итеп булмый, билгеле. Чөнки һәр депутат, читләтеп булса да, үз мәнфәгатен дә кайгыртырга тырышты.

Ф. Сафиуллиннан соң ук чыгыш ясаучы даими комиссия рәисе Гелий Кобелев партия оешмаларын җитәкләүнең төрмәдә утыру түгеллеген искәртүне кирәк тапты. Аның әйтүенә караганда, республикада 8 мең 400 дәүләт хезмәткәре бар икән. Бу - республикада эшләүче халыкның 0,61 проценты. Әмма хезмәт хакы фондының 9,8 проценты дәүләт хезмәткәрләренә түләнә икән. Республикада уртача пенсия 328 сум, ә дәүләт хезмәткәрләренең уртача пенсиясе 948 сум. Республика матбугатында эшләүче күпчелек журналистларның айлык хезмәт хакы 500 сум чамасы булуын истә тотсак, уйланырлык саннар бу.

Сессиядә утырганда миңа олы-олы агайлар һәм апалар кемгәдер зарланышып файдасызга вакыт уздыралар кебек тоелды. Кемнедер гаепләделәр, фикерләрен куәтләү өчен үз тормышларыннан мисаллар китерделәр. Парламентның иң өлкән яшьтәге депутаты Герман Мелкумянц 30 ел совхозны, аннары авыл хуҗалыгы идарәсен, соңыннан районны җитәкләгән. Бүген янәшәсендә авыл Советы рәисе булып эшләүчеләрдән 3-4 тапкыр кимрәк, 370 сум пенсия ала икән.

Фикер алышу барышында лозунглар ыргыткалаучылар да булды. Сергей Осколок, мәсәлән: "Намуслы хезмәт - дәүләт учреждениесе хезмәткәренә бердәнбер ташлама, ничек идарә итәсең - шулай түләнсен", - диде.

Индус Таһиров:

- Без барыбыз да дәүләткә хезмәт итәбез, димәк, дәүләт хезмәткәрләре, - дип раслады. - Уртача хезмәт хакы 350 сум булганда, пенсия ничек инде 3 мең 500 сум була алсын?!

Туфан Миңнуллин гадәтенчә образлы сөйләде:

- Премияне сыерга түгел, сыер савучыга бирәләр. Савучыга бирелгәч, савылучыга эләкми. Тигезсезлек каршылык китереп чыгара. Бу нәкъ менә тигезсезлекне, гаделсезлекне яклый торган закон. Чиновниклар арасында да эленке-салынкы йөрүчеләр бар. Кешенең кайда эшләвенә карамастан, түләү гадел булсын. Элек персональ пенсияләр бар иде. Хәзер дә закон яки Президент Указы нигезендә дәүләт алдындагы хезмәтләре өчен махсус пенсияләр бирергә, ташламалар ясарга була.

Законның гаделсез булуын күпчелек депутатлар яхшы аңласалар да, аны гамәлдән чыгаруны тәкъдим итүче табылмады. Чиновниклар санын кыскарту хакында да тәкъдим кертелмәде. Бүгенге авыр заманда күпсанлы чиновниклар армиясен асрау халык җилкәсенә авыр йөк булып төшә. Аларның күпчелеге халыкның тормыш хәлен яхшыртуга сәләтсез булуларын расладылар да бит инде. Һәр җитәкче үзенә бер кәтү ярдәмче туплый.

"Дәүләт хезмәте турында"гы Законга карата Президент та карашын белдерде. Аның фикеренчә, закон дәвамлылыкны тәэмин итәргә, хезмәт эшчәнлегеннән соң кешегә нормаль тормыш шартлары тудырырга тиеш. "Дәүләт хезмәте турында" Закон кирәк. Идарәдә сыйфатлы кадрлар булырга тиеш. Кичәге белән бүгенге төшенчәләр бер үк нәрсә түгел.

Президент дәүләт хезмәтенә киләчәктә кешеләрне ялларга, килешүләр төзергә кирәк булачак дип саный. Базар шартларында кадрларны сайлап алу мөмкинлеге бар. Президент дәүләт хезмәткәрләренең пенсиясен һәм хезмәт хакын зур дип санамый. Башкаларга андый шартларны тудырып булмавын да инкарь итми.

- Элек партия, совет органнарында эшләүчеләрне дәүләт хезмәткәрләре дип танырга мәҗбүрбез, - диде Минтимер Шәймиев, - аларны да тәэмин итми булмый. Алар арасында зур хөрмәткә лаек кешеләр бар. Гадәттә, начарларны сайламадылар. Безгә кешенең хезмәт вазыйфасын, бүләкләрен исәпкә алып ташламалар бирү кагыйдәләрен эшләргә кирәк.

Хокукый дәүләт өчен законнарның төрлесе кирәк. "Дәүләт хезмәте турында"гы Законның да, мөгаен, яшәргә хокукы бардыр. Һәр профессия вәкиленең хокукларын да, вазыйфаларын да билгеләргә кирәк, билгеле. Әмма һәркемнең хезмәте эш нәтиҗәләреннән чыгып бәяләнергә тиеш. Бу - аксиома. Ә чиновник хезмәтенә халыкның тормыш дәрәҗәсеннән чыгып бәя бирелә. Кризис көзге ачы җил кебек колак төбендә сызгырып торганда, халык тормыш авырлыгыннан сыкраганда күпме генә теләсән дә, Татарстан чиновниклары хезмәтеннән канәгатьләнү, аны югары бәяләү авыр. Шуңлыктан алар бу кадәр ташламаларга да һич кенә дә лаек түгел шул. Ышанмасагыз - мәсьәләне бөтенхалык тикшерүенә, референдумга чыгарып карагыз. Гаделлек шунда табылыр.

Андрей ТИТОВ коллажы.

Яшь җинаятьчеләрнең ТӨБӘГЕ БАРМЫ?

Хәзерге җәмгыять үсешендә төп проблемаларның берсе - җинаятьчелеккә каршы көрәш. Закон бозулар социаль институтларның, сыйныфларның, катлау, төркем һәм аерым кешеләрнең байтак өлешен колачлап алды. Бу күренеш массакүләм характер ала бара һәм еш кына гадәти гамәл дип кабул ителә. Россиядәге криминаль хәл-халәт шактый катлаулы булып кала бирә. Җинаятьчелек эш-хәрәкәт колачын бик тиз киңәйтә, яңадан-яңа көчләрне җәлеп итә, дәүләт структураларына реаль көндәш буларак җинаятьчел инфраструктура булдыра.

Нургаян ӘКБӘРОВ,
Казан шәһәре Эчке эшләр идарәсе башлыгы, милиция полковнигы.

Сүз дә юк, Россиядәге катлаулы криминаль хәл-халәт дәүләт күләмендә бердәм хокук саклау чараларын гамәлгә ашыруны таләп итә. Шул ук вакытта хәзерге Россиядә җинаятьчелеккә каршы көрәшнең төбәк үзенчәлекләре һаман саен күбрәк әһәмияткә ия була бара. Бу, бер яктан, төбәкләрнең мөстәкыйльлек алу процессының көчәюе, икенче яктан, аларның үсешендәге тигезсезлек, шулай ук икътисадый, сәяси, демографик, милли-мәдәни һәм башка үзенчәлекләр аркасында иҗтимагый тормышның криминальләшүе аерым төбәкләрдә үзенчә чагыла, аның үзенә генә хас тенденцияләре, үзлекләре, төсмерләре бар. Алар тулаем Россиядәге криминоген хәл-халәткә житди йогынты ясыйлар. Аңлашыла ки, җинаятьчелеккә каршы көрәштә теге яки бу төбәкнең үзенчәлекләрен исәпкә алучы, тирәнтен уйланган төбәк сәясәтеннән башка федераль көрәш программасын уңышлы төстә тормышка ашырып булмый.

Яшүсмерләр мохитендә законга каршы эш-гамәлләрнең киң таралуы иң мөһим проблемаларның берсе була бара. Ясалган җинаятьләрнең 13% ы (ачылган җинаятьләр турындагы мәгълүматлар буенча) Россия халкының 8% ын тәшкил итүче 14 тән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаганнар өлешенә төшә. Тулаем ил буенча алганда, һәр унынчы, ә кайбер төбәкләрдә һәр дүртенче җинаять үсмерләр һәм яшьләр тарафыннан эшләнә.

Социаль-криминоген хәл-халәт Татарстанда да катлаулы булып кала бирә. Республика Эчке эшләр министрлыгы мәгълүматларына караганда, яшүсмерләр җинаятьчелеге күп яклардан гомуми җинаятьчелек торышын кабатлый. Ул һаман саен социаль яктан куркыныч саналган җинаятьләр ягына авыша бара.

Яшүсмерләр арасында төркем җинаятьчелеге аеруча борчылу тудыра. Алар Татарстанда балигъ булмаганнар җинаятьчелеге динамикасына һәм структурасына турыдан-туры җитди йогынты ясыйлар, төп тенденцияләренә сәбәп булып торалар. Нәкъ менә үсмерләр төркемнәре аша балигъ булмаганнарның байтагы җинаять юлына баса. Республикада шул төркемнәр яшүсмерләр җинаятьчелеген гомум җинаятьчелек белән бәйлиләр.

Ышаныч белән расларга була: кыек юлга баскан үсмерләр төркемнәре күренеше үтә күпкырлы. XVIII-XIX гасырларның тарихи мәгълүматлары һәм документлары шәһәрләрдә үсмерләрнең төркемнәре булганлыгын дәлилиләр. Шулар балигъ булмаганнарның җинаятьчел төркемен формалаштыруга шактый зур йогынты ясаганнар. Мәсәлән, 1912 елда ук Д. Н. Радонежский, балалар җинаятьчелеген сыйфатлап, ялгызак җинаятьчеләрнең аз булуын раслаган. "Калганнары, - дип язган ул, - башкалар белән берлектә эш башлаганнар һәм аны дәвам иттергәннәр".

Яшүсмерләр төркемнәре нигездә стихияле төстә җәмгыятьнең читкә кагылган һәм тормыш төбендәге катлаулары вәкилләреннән оешканнар. Яшәешнең теге яки бу шартлары тарафыннан социальләшүнең гадәти һәм рәсми институтларыннан кысрыклап чыгарылган үсмерләр, территория һәм яшькә карап, рәсми булмаган альтернатив төркемнәргә берләшкәннәр. Аларның барлыкка килүе закончалыклы күренеш булып, яшь буынның яшәп килүче шартларга һәм социаль якланмауга каршы хисси ризасызлык чагылышы иде.

Төбәгебездәге иҗтимагый катлауланууны анализлау республикада балигъ булмаганнар арасында төркем җинаятьчелегенең чыганакларын һәм төп этапларын абайларга мөмкинлек бирә.

Индустрияләшү һәм шәһәрләшүнең бик тә көчәюе (70 нче елларда КамАЗ, АлАЗ, Түбән Кама химия комплексын, ә әлегрәк Казанның үзендә байтак кына эре объектлар төзү) авыл халкының күпләп шәһәргә күчеп килүен һәм иҗтимагый тормышта маргинальләшүне китереп чыгарды. Авылдан шәһәргә күчеп килгән гаиләләрдә яшәү рәвешенең гадәти нигезләре югалды. Авыл үсмерләренең шәһәр шартларына әзер булмавы һәм аларның тәртибенә социаль күзәтчелекнең йомшаруы социальләшүдә

тискәре чагылды. Индустриаль яктан үсә торган төбәкләрдә "бөек төзелешләр"гә җәлеп ителгән җинаятьчел элементларның (рецидивистлар, хөкем ителгән затлар һ. б.) йогынтысы да яшьләр һәм үсмерләр мохитенең криминальләшүенә житди сәбәп булды. Кыска гына арада илнең төрле почмакларыннан мәнфәгатьләре, кыйммәти юнәлешләре һәм әхлак кагыйдәләре төрле булган кешеләрнең уптым илаһи күчеп килүе республиканың индустриаль яктан үсеп барган үзәкләрендә тиешле иҗтимагый-психологик һәм әхлакый хәл-халәт тудырды. Аңа кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрдә югары социаль-психологик киеренкелек хас иде. Игелекле шәһәр мәдәниятенен үсмәгән булуы, әлеге шәһәр кешеләрендә "мәдәни катлау"ның сайлыгы җинаятьчел мохитнең барлыкка килүен җиңеләйтте.

Микрорайоннарның бик тиз төзелүе, аларда яшьләрнең җәһәт артуы яшүсмерләр җинаятьчелегенең торышына житди йогынты ясаган социаль сәбәпләрнең берсе булды. Әлеге яшьләр арасында табигый төстә төрле бергәлекләр барлыкка килде.

Бу хәлләр социальләшмәгән яшүсмерләр субкультурасының бик тиз формалашуына һәм үсмерләр җинаятьчелегенең үсүенә китерде. Әлеге төр җинаятьчелекнең бер аерымлык билгесе аның төркемнәргә һәм территорияләргә бүленешеннән гыйбарәт иде.

Үсмерләр һәм яшьләр төркемнәре 70 нче елларның икенче яртысыннан республиканың барлык индустриаль үзәкләрендә тупланды. Казан белән Чаллы Татарстанда балигъ булмаганнар җинаятьчелегенә бәйле социаль-криминоген хәл-халәтне билгеләде. 80 нче еллар ахырына кадәр төркемнәрнең үсүе һәм тупланууы күмәкләп сугышу һәм аларның "авторитетын күтәрү" белән бергә барды. Казанда гына да 90 га якын һәртөрле яшьләр һәм үсмерләр төркеме бар иде. Алар республикадагы криминоген хәл-халәткә шактый ук зур йогынты ясадылар. Бу чорда оешканлык һәм җәмәгатьчелеккә каршы юнәлеш дәрәҗәсе җәһәтеннән төрледән-төрле төркемнәр барлыкка килде.





Шәһәр микрорайоннарында, башка кварталлар төркемнәренен хулиганлыгыннан һәм һөҗүменнән саклану максатында, нигездә 14-15 яшьлек үсмерләрне берләштергән аз санлы һәм тотрыксыз төркемнәр (компания тибындагы) оеша. Шайка тибындагы төркемнәр дә пәйда була. Аларында "житәкче үзәк" оеша һәм җәмгыятькә каршы "кыйммәтләр" хакимлек итә. Алар шәһәрнең мәгълүм бер территориясендә йогынты сферасы өчен көндәшлек көрәше башлыйлар, моның өчен, көч күрсәтү максатында, башка төркемнәр белән сугышлар оештыралар.

Мондый төр төркемнәр территориаль буенча оешкан банда тибындагы өерләргә әверелә лар. Аларның аерымлык билгеләре түбәндәгеләр: төркем эчендәге элементләр оешканлык җәһәтеннән югары дәрәҗәдә була, әгъзалар арасында эш бүлешенә, төркемнәрдә барлык әгъзалары өчен мәҗбүри булган һәм "төрмә" субкультурасына тәнгәлләшкән кагыйдәләр һәм "кыйммәтләр" хөкем сөрә.

Шуны искәртик: яшүсмерләр төркемнәре бердәй түгел, алар бер-берсен инкарь итмиләр, бер-берсен тулыландыралар. Яшүсмерләр бандаларының саны компания һәм шайка тибындагы төркемнәр исәбенә арта.

Россиядә яшүсмерләр төркемнәре җинаятьчелеге проблемасы 80 нче еллар ахырыннан һәм 90 нчы еллар башыннан аеруча кискенләште. Кискен икътисадый реформалар уздырырга тырышу - аларның үзеген хосусыйлаштыру һәм базар нигезләрен салу тәшкил итә - социаль структураны җимерде: халыкның байтак өлеше маргинальләште, хосусый эшкуарларның һәм буржуазиянең тар катлавы барлыкка килде. Бу процесс җәмгыятьтәге социаль институтларның үзгәрүе белән бергә барды. Социальләшүнең гадәти институтлары тамырдан үзгәрде, үз эченә бикләнде. Бу күренешләр үсмер һәм яшьләрнең унай социальләшү процессын таркатуга китерде. Шуның нәтиҗәсендә барлыкка килгән социомәдәни бушлык ялган кыйммәтләр белән тула барды. "Югары" катлаулар яшәешенең кызыктыргыч булуы халыкның шактый катлауларының матди хәлен җинаятьчел юллар белән яхшыртуга юнәлдерде. Мондый шартларда балигъ булмаганнарның һәм яшьләрнең җинаятьчел тәртибен формалаштыруда социаль-криминоген факторлар система рәвешен алды.

Шуның нәтиҗәсе буларак, җинаятьчелекнең, шул җөмләдән балигъ булмаганнар җинаятенең, юнәлеше үзгәрде. Үсмерләрне ачыктан-ачык һәм яшертен эшкуарлыкка бик иртә тарту көч кулланып файда алу тенденциясенең өстенлек алуына, хулиганлык активлыгының йомшаруына китерде. Хәзерге хәл-халәттә яшүсмерләр җинаятьчелегенең мөлкәткә юнәлеше, күрәсен, көчәя барыр, куркытып алу, урлау, талау һәм башка юллар белән файда табу кебек җинаятьләргә этәргеч бирер.

Яшүсмерләр җинаятьчелеге структураларындагы һәм торышындагы житди үзгәрешләр аның яна үсеш дәрәҗәсенә чыга башлавын раслый. Әгәр 80 нче еллар ахырында республикада аның эчтәлеге һәм структурасы яшүсмерләр төркемнәре җинаятьчелегенә бәйле булса, хәзерге вакытта аның үсүе оешкан җинаятьчелеккә бәйле дип әйтергә нигез бар.



Республикада оешкан җинаятьчелектә үсмерләр һәм яшьләр шактый зур роль уйный. Аларны җентекләп сайлап алалар, өйрәтәләр һәм коралландыралар. Мәсәлән, Казанның "39 нчы квартал" төркеменең үсмер әгъзалары биргән анлатма язулары шул хакта сөйли. Алар безнең янга белдекле кеше килде, ул безне "конторага алып китте", дип күрсәтәләр.

Бу уңайдан шуны әйтим: әгәр элегрәк үсмерләрне аерым-аерым сөйләшеп-сынап, аларның криминаль мохиткә эләккәнен, криминаль мәгълүматын, күнекмәләрен исәпкә алып җәлеп итсәләр, хәзер күмәкләп тарталар. Яшүсмерләр төркемнәре әгъзаларының яшь ягыннан диапазоны киңәя бара. Алар составына 10-12 яшьтәге 4-5 нче сыйныф укучыларын, хәтта 7-10 яшьтәге балаларны да тартып кертәләр. Төркемнәрдә кызлар саны да арта бара. Актив эш итүче төп өлешне 16-17 яшьлек үсмерләр тәшкил итә. Аларны криминаль мохит тирәсендә, шулай ук хокук саклау органнарының игътибарын һәм көчләрен оешкан җинаятьчел төркемнәрнең эшчәнлегеннән читкә юнәлтү өчен файдаланалар.

Шулай итеп, яшүсмер төркемнәре җинаятьчелеге мафиоз структуралар һәм рецидивистлар йогынтысы нәтиҗәсендә оешкан төс ала, күзгә бәрелеп тормый.

1990 елның башыннан Татарстанда җинаятьләрдә катнашучылар арасында ПТУ һәм мәктәп укучылары өлешендә үзгәрешләр шактый зур. Әгәр 1993 елда ПТУ укучылары 17,6%, ә мәктәп балалары 17,2% тәшкил итсә, 1997 елда 13,6 - 15,6% булды. Бу - соңгы елларда балигъ булмаганнарның законга каршы гамәлләрендә мәктәп балалары өстенлек итә дигән сүз. Үсмерләр җинаятьчелеге яшәрә, 14 яшькә кадәрге балигъ булмаганнар тарафыннан ясалган җинаятьләр арта.

"Мәктәп рәкеты" дип аталган күренеш киң таралган. Узган ел безнең республикада үсмерләр мохитендә 65 янап акча алу очрагы ачыкланды. 56 очракта катнашучыларга җинаять эше кузгатыр өчен яше җитмәү сәбәпле хәтта тикшерү дә алып барылмады. Үсмерләр төркеменә керүче 13 яшьлек кызның янап акча алуы билгеле. Ул тугызынчы сыйныфта укучы кызларның котын алып торган: алар акча түләргә әзер булганнар. Кагыйдә буларак, өлкәнрәк үсмерләр кечкенәләрдән куркытып акча алалар. Мәсәлән, Казанның бер мәктәбендә алтынчы сыйныф укучысы өченче сыйныф укучыларын дер селкетеп торган, тегеләр әбәткә дигән акчаларын берсүзсез биреп барганнар.

Шуны да искәртим: мәктәп рәкетына хәтта 1-3 сыйныфларда укучы 10 яшькә кадәрге балаларны да өйрәтәләр.

Кыскасы, Татарстандагы яшүсмерләр җинаятьчелегенең хәзерге төп тенденцияләре түбәндәгеләргә кайтып кала:

яшьләрне һәм үсмерләрне, криминаль бизнес мохитендә катнаштырып, оешкан җинаятьчел төркемнәргә күпләп тарту;

җинаятьләр төркемен оештыру һәм

яшертенлек эш итү дәрәҗәсе арта бара; баю нияте белән көч кулланып ясала торган җинаятьләр ишәя, үсмерләр тарафыннан аеруча рәхимсезлек белән ясалганнары арта;

үсмер кызларның җенси әхлаксызлыгы һәм криминаль активлыгы үсә;

җинаять өчен җаваплылык яшенә җитмәгәннәр тарафыннан кылынган иҗтимагый куркыныч гамәлләр саны арта.

Кызганыч ки, балигъ булмаганнар һәм яшьләр арасында закон бозуларны кисәтү буенча дәүләти чаралар төбәктәге социаль-криминоген хәл-халәтнең тиз үзгәрүе артыннан җитешә алмый. Бу - күпмедер дәрәҗәдә дәүләти хокук саклау институтларын баштан ук административ контроль вазыйфаларын үтәүгә юнәлдерүгә һәм алар арасында федераль дәрәҗәдә дә, төбәк дәрәҗәсендә дә тиешле бәйләнеш булмауга бәйле.

Аннары килеп балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны кисәтү эшендә төп игътибар балалар һәм үсмерләрнең психик һәм социаль үсешендәге тайпылышларга сәбәп булган тискәре психологик, педагогик һәм социаль-психологик факторларны ачыклауга бирелә. Бу очракта балигъ булмаган хокук бозучылар белән шәхси эшләү алымнарына өстенлек бирелә.

Бу уңайдан, яшүсмерләр җинаятьчелеген кисәтүдә психологик-педагогик чаралар комплексының кирәклеген инкарь итмәстән, ассызыклап әйтергә кирәк: гомумән, илдә һәм аерым алганда Татарстанда килеп туган социаль-криминоген хәл-халәткә яшүсмерләр төркемнәренең киң таралуы һәм балигъ булмаганнарны җинаятькә күпләп тарту хас. Бу - яшүсмерләр җинаятьчелеген кисәтүгә системалы якын килүне таләп итә. Аңа каршы көрәш хокук саклау чараларына гына кайтып кала алмый, ә киң колачлы социаль сәясәт кысаларында каралырга тиеш.

Мәсьәләгә шулай якын килгәндә, бу эшчәнлек хокукый яктан закон бозуның барлык формаларын кисәтүгә юнәлдерелә, ә социологик ноктадан караганда, сүз законга буйсыну тәртибе һәм балигъ булмаганнарның җинаятьчел тәртибен формалаштыруга социаль-криминоген факторларның йогынтысын киметүгә этәргеч бирүче иҗтимагый мөнәсәбәтләр системасын һәм иҗтимагый аңны формалаштыру максатын куйган эшчәнлек турында бара. Хәзерге вакытта бу эшчәнлекнең төп бурычы үсмерләрне уңай социальләштерүне һәм бүгенге Россия җәмгыятенең төбәкләрдәге тиз үзгәрүчән шартларга яраклашуын җиңеләйтүдән һәм тизләтүдән гыйбарәт.

Балигъ булмаганнар җинаятьчелеген кисәтү институты яшь буынга эшкә урнашуда, һөнәри әзерләүдә, торак белән тәэмин итүдә, дәвалануда булышырга, ә кирәк очракларда акча белән нәтиҗәле ярдәм күрсәтергә тиеш. Шул ук вакытта закон чыгару күзлегеннән караганда, һәр үсмернең шундый ярдәмгә хокукы булу зарур.

Сүз дә юк, хәзерге иҗтимагый хәлхаләттә иң нәтиҗәле кисәтү чарасы - матди-икътисадый этәргечләр. Шунысы да бик мөһим: үсмерләргә, яшьләргә уңай хезмәт һәм көнкүреш шартлары тудыру белән бергә, аларның законга ихтирамлы тәртибен әхлакый-хокукый яклау һәм стимуллаштыру системасын булдыру сорала. Аерым алганда, җинаятьчел тәртип хас булмаган яшьләргә, мәсәлән, югары һәм башка уку йортларына кергәндә өстенлек бирү шундый тәртипне стимуллаштырыр иде. Яклау һәм стимуллаштыру системасы даими рәвештә җинаять ясаучыларны чикләү чараларын да күздә тотарга тиеш.

Йомгаклап шуны ассызыклыйсы килә: хәзерге вакытта яшүсмерләр җинаятен кисәтүгә теләсә кайсы рөхсәт ителгән чаралар, хәтта алар вакытлыча уңыш китерсәләр дә, киң колачлы социаль реформалар стратегиясе белән бәйләнмәгән очракта тактик характерда гына булачак.

Василий МАРТИНКОВ һәм Солтан ИСХАКОВ фотолары.

Алладан куркумы, әллә максатмы берләштерә?



Ил САТТАР,
фәлсәфә фәннәре кандидаты, доцент.

Татар халкы тарихында мөселман дине рухи көч булганлыгына беркемнең дә шиге юк. Мин дә моңа шикләнмим. Кешенең табигате - рухи. Әлбәттә, милләт өчен рухи бердәмлек кирәк. Әмма гарәп телендә булган дин, урта гасырлардан килгән идеологик көч бүген безгә нинди рухи нигез була ала һәм нинди бердәмлеккә китерә?

Бүген без бар көчебезне дин нигезләрен ныгытугамы, әллә күпкырлы бай мәдәният үсешенә бирикме, дип мин “Татарстан” журналында мәкалә бастырган идем. Рашат Әмирхан шул ук журналда “Милли яшәеш һәм ислам” дигән мәкаләсе белән минем фикерләремә каршы чыкты. Фәнни бәхәсләр кирәк, әлбәттә. Бу да бит милли мәдәниятнең бер күренеше. Тик алар гадел булсын иде.

Алдан ук әйтеп куйыйм: мин дин белән көрәшмим. Ул бар, халыкның кайсыдыр өлешенең аңына сеңгән. Кешенең күңел халәте белән сугышу ул үзе җинаять. Дин - заманасында бөек, даһи кешеләр уйлап тапкан искиткеч көчле рухи чара. Кешелекнең дә, шәхеснең дә күңелен биләп ала торган анлап бетергесез зур көч. Шунысын да әйтергә кирәк: дин халык яшәешенең дәрәҗәсе, эчтәлеге белән тыгыз бәйләнештә торган. Көчле идеология буларак, халыкның бүгенге яшәешенә дә, киләчәгенә дә аның тәэсире искиткеч зур. Шуларны истә тотып, дин турында, гомумән, идеология турында сүз йөрткәндә халык алдында булган җаваплылыгыбызны онытмаска кирәктер.

Рашат Әмирхан минем фикерләрем белән килешми. Тик бу очракта ул аларны анлап язганмы? Бөтенләй үк анлап бетмәгән шикелле. Минем әйтергә теләгән фикерем шул: бүген безнең түрәләребез халыкны яңадан дингә кайтарырга кирәк диләр бугай. Минем бу фикерем уйдырма түгел икәнлеген исбатлап торасы юк. Байлык хакимият кулында. Шулкадәр мәчетне халыктан җыелган акчага төзеп булмавы көн кебек ачык. Колшәриф мәчете дә әллә ничә миллиард сум акча таләп итә. Димәк, бәхәсләшеп тормыйк, хакимият рухи юнәлешебезне дин ягына борып җибәрергә ниятли.

Мәкаләмдә мин мәдәниятне үстерүдә безнең алда бүген ике юл ачылды дип белдердем. Берсе халыкны дин калыбына тарту, икенчесе - дөнья халыклары рухи мәдәниятләренең иң бөек казанышларын үзләштерү. Шушы соңгы юнәлештә торып милли мәдәниятебезне булдыру. Рус халкы соңгы сиксән ел эчендә үз теленә әдәби әсәрләрнең иң югары дәрәҗәдәгеләрен тәрҗемә итте. Шуна өстәп фәлсәфә, психология, социология, сәнгать, гуманитар фәннәр буенча иң күренекле хезмәт, фән җәүһәрләре дә тәрҗемә ителде. Бу рус халкының мәдәни дөньясын искиткеч баетты. Татар халкының исә бу эшкә әле керешкәне дә юк. Бу очракта сүз фикер байлыгы турында түгел, ә акыл турында бара. Безнең фикерләү сәләтебез сай һәм көчсез. Бу бит наданлыктан. Фикер байлыгы, фикер тирәнлеге халыклар аралашуыннан килә. Рус теле искиткеч бай, аның тасвирлау алымнары да бай, рухи ашказаны бик сәламәт, барысын да үзләштерә бара.

Минем шул фикеремә Рашат Әмирхан тиешенчә игътибар итмәгән. Ул: “...һәрбер иҗтимагый тәгълимат үз эчтәлегендә теге яки бу идеологияне чагылдыра”, дип яза һәм идеология түгел, тәгълимат кирәк дигән фикеремә бәйләнебрәк мине марксизмга ябышып ятуда гаепли. Марксистик фәлсәфәне без тирәнтен анлап үзләштергән булсак, бик тә ярар иде әле. Мин моңа өмет итмим. Аңа ирешер өчен көчле зиһен дә, зур тырышлык та кирәк. Марксистик тәгълимат катлаулы, аннары ул ятлап ала торган таблица да түгел. Аны үзләштерер өчен барлык калыплардан китү сорала. Без исә күрсәткән юл белән генә атларга өйрәнгән. Бүген безгә “Дин!” дип әйткәч, без шунда ук динне якларга керештек.

Шунысын да әйтү кирәктер, идеология - ул теге яки бу сыйныфның мәнфәгатьләрен яклый торган һәм шул мәнфәгатьләргә ирешү юлларын билгеле торган карашлар системасы. Капитализм да идеологиясез була алмый. Димәк, бүген безнең илдә идеология хөкем сөрә. Газеталарны, журналларны укыгыз, радио тыңлагыз, телевидение карагыз. Менә шул була инде идеология. Идеологияне теоретик формада гына яши дип уйлаган кешеләр бик ялгыша. Кулында хакимият һәм акча булган сыйныф үзенең идеологиясен халыкка көчләп тага. Син буржуаз идеологиядән беркая да кача алмыйсың. Ул көн-төн синең белән аерылгысыз. Мин әнә шул бүгенге сәясәтне күз алдында тотып, безгә тәгълимат кирәк, дим. Марксистикмы ул, әллә юкмы - монысы әллә ни әһәмиятле түгел. Халык мәнфәгатьләрен яклый торган тәгълимат кирәк. Мин батраклар, алпавытлар барлыкка килүенә каршы. Мин кешене кеше изми торган җәмгыять ягында. Безгә тулаем халык мәнфәгатьләрен күз алдында тоткан тәгълимат кына кирәк. Бу тәгълимат идеология ролен башкара алмый.

Эшчеләр сыйныфының мәнфәгатьләрен яклый торган тәгълимат идеологияме, әллә түгелме? Рашат Әмирхан: “Шул ук И. Саттар искә алган “фәнни тәгълимат” сыйнфый идеологиянең гәүдәләнеше булып барлыкка килде”, - дип яза. Капиталист күзлегеннән чыгып караганда - идеология. Кешелек тарихы күзлегеннән чыгып караганда - фәнни тәгълимат. Бу

тәгълимат сыйныфсыз җәмгыятькә ирешү юлларын ачыклый. Капиталист, әлбәттә, бу утопия, ди. Эшчеләр һәм крестьяннар сыйныфы, батрак булып яшиселәре килмәсә, бу тәгълиматка җитди карарга мәҗбүр. Һәм шунысын да әйтик, сыйныфларга бүленүдән котылу - җәмгыять өчен мәҗбүри. Шундый җәмгыять була калса, кешелек сугышлардан, явызлыктан, гаделсезлектән котылыр. Бу максат бер дә әкият түгел. Бүгенге җитештерү көчләренең үсеше шундый җәмгыятьне булдыру мөмкинчелеген әллә кайчан тудырган инде. Эш нидә соң? Кешелекнең үз алдына бу максатны куюыннан. Бу максатка ирешү өчен ихтыяр көче дә булырга тиеш. Гомумкешелек идеологиясе идеология ролен югалта.

Рашат Әмирхан XX йөз башын татар мәдәнияте өчен үсеш еллары иде, ди. Бик тә дөрес фикер. Анда җәдитчеләр кадимчеләр белән көрәшкән, анда Вахитовлар, Ямашевлар булган, анда Тукайның күпкырлы таланты канатларын җәйгән, анда Габдулла Кариев, русларга ияреп, татар театры тарихын башлап җибәргән, анда татар халкы дин белән генә чикләнмичә, дөнья мәдәниятенә тартыла башлаган. Бу гасыр башында татарның рухи тормышында секуляризация (мәдәнияттә һәм тулаем тормышта дин тәэсиреннән котылу) дигән юнәлеш барлыкка килә. Бу юнәлеш Европада берничә йөз ел хөкем сөрә. Шул казанда кайнап, без татар булып үсәбез дә. Урта мәктәп, югары уку йортлары, газеталар, журналлар, нәшриятлар, татар телендәге күпкырлы рухи тормыш милләтебезгә сакланып калырга гына түгел, гел үсештә булырга ярдәм итә. Рашат Әмирхан исә исламны татарны татар итеп саклап кала торган бердәнбер көч итеп күзаллый, ахрысы.

Аңлашыла ки, Рашат Әмирхан буржуаз караштa тора. Ул Россиядә 1917 ел вакыйгалары Февраль революциясе белән чикләнсә, оҗмах булыр иде, дигән фикерне әйтә. Нинди оҗмахка әләгер идек икән? Тарихны кире кайтарып булмый. Аңлашыла ки, без губерна булып калыр идек. Татарларга дәүләтне Ленин кайтарды. Кызганыч ки, тарих ул такыр юл түгел. Ленинның фикере тулысынча тормышка ашмады. Ул күз алдында мөстәкыйль хөкүмәтләр берлеген тотса, вафатыннан соң, бу фикер автономияләштерүгә кайтып калды. Февраль революциясе дә бит халык кузгалышы башы гына иде. Шул чордагы капиталистлар һәм алпавытлар халык мәнфәгатьләрен канәгатьләндерү турында уйласа, Октябрь түгел, Февраль түнтәреше дә кирәкмәс иде. Ник соң алар сугышны бетереп, солдатларны өйләренә кайтарып, крестьяннарга җир, эшчеләргә фабрикаларны бирмәгән? Алар бүген дә үз кулларындагыны бирәүгә дә бирмәячәкләр. Шуңа күрә бүген дә безгә яңа революция яный.

Рашат Әмирхан аңлы һәм белемле галим. Тик нигә соң ул интернационализмны милли мәдәнияткә каршы куя: "...авыл җирлегендә интернационализмга авыр бирелә торган милли моңнар, авыз иҗаты, гореф-гадәтләр..." дип яза? Интернационализм - ул төрле милләтләрнең үзара тыныч һәм дуслыкта яшәү кагыйдәләре. Бу төшенчә Рашат Әмирхан тезеп киткәннәргә кагылмый! Нәрсә соң ул интернационализм? Син урыс, мин татар. Мин сине татар итәргә җыенмыйм, син мине урыс итәргә тырышмыйсың. Ә инде кирәк чакта уртак дошманга каршы без бердәм булып күтәрелербез. Рашат Әмирхан әйткәннәр интернационализм кагыйдәләреннән килми бит. Руслашу дигән нәрсә татар халкына гына кагылмый. Бүгенге дөньяда татар мәдәнияте генә рус кебек зур халыкның теле һәм мәдәнияте басымы астында яшәми. Француз, испан һәм башка күп халыклар АКШ мәдәнияте йогынтысына каршы көрәш алып бара. Руслашу ул икътисад мөнәсәбәтләреннән дә килә. Әйе, кызганыч, без бүген телебезне, мәдәниятебезне саклап калу турында уйларга мәҗбүр. Тик бит моның чын сәбәпләрен дөрес билгеләмәсәң, уйдырма сәбәпләргә сылтап ялгыш диагноз куйсаң, ялгыш дару билгеләсәң, нәтиҗә нинди булыр икән? Үз телебездә бай һәм күпкырлы мәдәният булдырмасак, татарлар, телиме-юкмы, рус телендәге күпкырлы дөньякүләм мәдәни мирасга коенып яшәр.

Рашат Әмирхан ислам дине ул безнең бердәнбер рухи таяныч һәм татар милләтен саклап калырлык бердәнбер чара дип чыга. Мине исламның кешелек дөньясында искиткеч зур урын алып торуын танымый дип гаепли. Кешелекнең аны, дини чорлардан китеп, әллә нинди биеклекләргә күтәрелде. Алладан куркып һәм Алла көченә генә ышанып яши торган чорлар артта калып бара. Кеше үзенә ышанырга тиеш, үз көченә ышануның күнелен биләп алган чакта гына кеше чын-чыннан азат шәхес була ала.

Сүзебезне Рашат Сафинның "Милли хәрәкәт һәм дин" дигән мәкаләсенә бәйләп дәвам итик ("Татарстан", 1997,

N 4). ТИҮ рәистәше дә татар өчен диннән башка бернәрсә дә юк, дигән караштә тора. Ни өчен соң татарга диннән башка берни дә ярамый?

Рәшат Сафин Р. Әмирхан әйтеп бетермәгәннәрне әйтеп сала.

1) "Совет чорында без динне фәлсәфә белән аралаштырмакчы булдык, ләкин бу юл белән рухи тәрбиядә уңышка ирешә алмадык". Бик тә кызык фикер. Мескен халкыбыз! Рухи тәрбиясез сиксән ел яшәп караңгылыкка, гаделсезлеккә тәмам төштен! Кем булдың соң рухи тәрбиясез? Рухи тәрбияне Рәшат Сафин ни дип белә икән? Күз алдына ничек итеп китерә икән? Әллә инде дин булмаса, рухи тәрбия дә юкмы?

Гафу итегез! Мин халкым турында андый фикердә тормыйм. Рухи тәрбиясез халык шулай тырыш була алмый, санап бетергесез галимнәрне җәмгыятькә бирми, иген чәчми. Аннары ата-аналар, санап бетергесез мәктәпләребез, укытучыларыбыз, пионервожатыйларыбыз бу сиксән ел ни эшләде соң?! Халыкны наданлыкка, караңгылыкка бәлә торып алып бардымы?

Аннары... динне фәлсәфә белән алыштырыйк, дип әйткән кешене автор атап әйтә алыр микән? Совет власте дин түгел, мәдәният бирү ягында торды. Татарның язучы, композитор, артист, журналист, сурәтче берләшмәләре Совет власте чорында барлыкка килде. Бөек композиторларыбыз Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов, Җәүдәт Фәйзи, бөек сурәтче Бакый Урманче, бөек артистларыбыз Шәүкәт Биктимеров, Илһам Шакировлар кайсы чорда тәрбияләнеп, белем алып, күтәрелеп китте? Язучыларны әйтеп тә тормыйм, алар бик күп. Без һаман җиденче гасырда Мөхәммәт исемле гарәп иҗат иткән рухи байлык белән генә яшәп торырга тиешме?

2) Халыкны ничек тәрбияләргә кирәк? "Дөньяга караш тәрбияләүдә дин философиядән нәрсә белән аерыла? Дин хискә таяна, Аллаһының кодрәтенә ийламыйча ышануга нигезләнә. Фәлсәфә табигать законнарына, акылга таянып, уйфикер аркылы килүне хуп күрә. Димәк, аларның беренчесе балалар, яшьләр, гади халык тәрбиясе өчен, икенчесе зыялылар өчен кирәк. Беренчеләре фәлсәфи гомумиләштерүне үзе "чәйнәп йота" алмый, тәгълиматны аларга ийламыйча гына кабул итәрлек итеп бирергә кирәк... Нәтиҗә шул: ...халык никадәр "карарак булса, аңа әлеге законнар турындагы мәгълүматны серлерәк итеп бирү (әйтик, гарәп телендә) отышлырак".

Бу бит шаккатырлык программа!

3) "Диннең әһәмияте тагын менә нәрсәдә - ул омтылыш бирә: үзенне киләчәккә (теге дөньяга - мәңгелеккә) әзерләргә... өйрәтә". Менә сина мә! Соң бу дөнья белән нишлибез инде?! Бу дөньяны кемгә тапшырабыз?! Бу дөньяга киләчәк тә кирәкмимени? Теге дөнья безнең киләчәгебез икән! Белмәгән, күрмәгән теге дөнья турында хыялланып яшәп, мин бу дөньяның рәхәтен бүгенге халык милкен урлап ике-өч катлы коттеджлар төзеп яшәгән байларга бирим, үзем, хәерчелегем белән килешеп, уфтана-уфтана бу дөньяда бераз яшәп алыйм. Бәлки, бу дөньяның киләчәге турында халкыбызны уйларга өйрәтсәк яхшырак булыр? Бу дөньядагы киләчәкне дә булдыру кирәк бит. Рәшатның фикере ачык: түз, халык, башыңа ни төшсә дә, түз! Теге дөньяда рәхәт күрерсен. Бүгенге түрәләр бар байлыгыңны тартып алса да, хәерчелеккә төшсән дә, түз. Менә шуңа күрә К. Маркс дин турында: җәберләнгән хайванның авыр сулышы, миһербансыз дөньяның йөрәге, дип язган да инде.

4) "...киләчәккә өмет калдырмый торган марксистик-ленинчыл философиядән һәм атеизмнан аның өстенлеге шунда".

Дин турында язган кешеләр динне дә, марксистик-ленинчыл философияне дә белми. Марксистик философия бар философик юнәлешләрдән шунысы белән аерыла да - ул тарихи оптимистик философия. Мәсәлән, Зигмунд Фрейд фикере буенча, кешене никадәр тәрбияләмә, ул барыбер ерткыч хайван табигатеннән ерак китә алмый. Фрейд кеше табигатенә биологик караштә тора. Кешегә ерткычлык нәселдән бирелә, ди, Маркс, мәгърифәтчелек чоры фикерен уртаклашып, кеше җәмгыять тудырган шартларда тәрбияләнә, ди. Ләкин бу очракта ул өстәп куя: тәрбиячене дә тәрбияләргә кирәк. Димәк, аның фикере буенча, кеше максат куеп, кешелекле яшәеш шартлары булдыра ала. Җәмгыятьнең объектив законнарын танып-белеп һәм шул законнарга таянып, үз көче, үз көрәше нигезендә кешелекле киләчәкне булдыра ала. Марксистик тәгълиматның асылы шунда да. Киләчәккә өмет бар. Бу дөньядагы киләчәккә. Гафу итсеннәр мине Рәшатлар.

5) "Кешенең табигате шулай яратылган ки, ул кемнән дә, нәрсәдән булса да куркырга тиеш". Сафин, кеше Алладан яки Сталин кебек шәхестән куркып яшәргә тиеш, ди.

Шунысын аңлап бетереп булмый, бүгенге каләм ияләре бер дә шикләнмәстән үзләрен төрле фәннәрдә белгеч итеп саныйлар. Менә Рәшат Сафин да үзенең карашлары, һичшиксез, дөрес дип, кешенең табигате турында: "Шулай яратылган... куркырга тиеш", дип яза. Кеше табигате турында гомерем буе эзләнеп укыйм. Мондый фикерне беркемдә дә очратканым юк. Татар халкын куркак итеп тәрбияләсәк, ни булыр соң? Кайларга барып җитәрбез һәм ниләргә ирешербез?

Аңлыйм, бу очракта Сафин кеше Алладан курыкса, намуслы булыр, дигән фикердә тора. Тик бит монысын да исбатлап булмый.

Мин үз күңелем һәм үз ихтыярым белән генә гадел һәм намуслы. Мин гаделсез, намуссыз булуымнан курыккан чакта гына чын-чыннан гадел һәм намуслы. Шул очракта гына мин - чын кеше. Монафикъ түгел. Куркудан намус кагыйдәләрен истә тотып, нидер кылам икән - бу инде мин үз табигатемнән чыгып эш кылдым дигән сүз түгел. Бу чын-чыннан монафикълык. Курку да һәр очракта берүк нәрсә түгел. Алладан курку - бу бер. Ә инде намусыңны югалтудан курку - бу бит бөтенләй икенче нәрсә.

Алладан курку безне берләштерә торган көчме соң? Минемчә, максат берләштерә. Шул максатка карап аның рухи дөньясы барлыкка килә. Димәк, Рәшат Әмирхан да, Рәшат Сафин да бу очракта идеалистик караштә тора, чөнки алар рухи көч беренчел, ә җәмгыятьнең объектив тормышы икенчел, дип ышаналар. Милләтебезнең максатын билгеләмичә, аның рухи тормышы турында фикер йөртү файдасыз.

Милләт алдында торган максат - батрак хәленә бер татар да төшәргә тиеш түгел. Димәк, җитештерү көчләрен югары дәрәҗәгә күтәрү белән гадел социаль мөнәсәбәтләр урнаштыру да безнең максат булып тора. Икенче максат - авыл тормышын шәһәр тормышы дәрәҗәсенә күтәрү. Менә шул максатлардан чыгып, без рухи тормышыбызның формалары, эчтәлеге, сыйфатлары турында уйларга тиешбез.

Идеологияне бармак суырып кына тудырып булмый. Безнең идеология дин дип раслау нәкъ менә шул бармак суырып утыруга тиң. Теге замандагы халыкны һәм мәдәниятне бүгенге көннәрдәге халык һәм мәдәният белән чагыштыру да мөмкин түгел. Халкыбыз алдында торган максатлар да башка. Теге заманда Алладан килгән дип саналган сыйныфларны бетерү турында сүз дә була алмый иде. Без бүген шул караштә торсак, намуссыз булабыз. Мин бүген ничек инде батраклар булырга тиеш, дип кычкырып йөрим, ди! Бу бит наданлык та, үз халкыңа карата намуссызлык та. Бер татар да мескенлектә яшәргә тиеш түгел! Әгәр муллалар батраклар, ярлылар, мескеннәр булмасын дип чыкса һәм шуның өчен төрмәгә керергә әзер булса, мин бүген үк мөселман динен яклаган булыр идем. Ләкин бу караш мөселман дине кагыйдәләренә туры килми һәм андый мулланы көндез ут кабызып та таба алмабыз.

Рәшат Әмирхан фикерен фәнни юрганнарга төрөп алга сөрә. Рәшат Сафин шул ук фикерләрне ачыктан-ачык, бернинди фәнни юргансыз ярып сала. Мөселман диненең "гуманистик" мөмкинлеген бу ике автор ике яктан ачып бирде. Шул инде: караңгы халыкка - дин. Зыялыларга - фәлсәфә. Батракларга муеннарына үгез камыты, байларга - коттеджлар.

Солтан ИСХАКОВ һәм
Рөстәм МӨХӘММӘТҖАНОВ
фотолары.

Туфан МИҢНУЛЛИН,
драматург.

Бирде дөнья кирәкне -
Еламаска өйрәтте...

(Хәсән ТУФАН).

Язылачы роман

Беляев Рәис Кыям улы 1935 елның 13 гыйнварында Аксубай районының Яңа Татар Әдәмсуы авылында туа. 1959 елда Казан дәүләт университетын, 1967 елда финанс-икътисад институтын тәмамлый. Философия фәннәре кандидаты, профессор. Беляев Р. К. 1958-69 елларда республика комсомол оешмаларында җитәкче постларда эшләде. 1969 елда КПССның Бауман райкомы беренче секретаре, 1969-84 елларда партиянең Чаллы шәһәр комитеты беренче секретаре, КамАЗ һәм шәһәр төзүне оештыручыларның берсе булды. 1984-87 елларда КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре иде. 1987 елны Рәис Кыямович Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать академиясе ректоры итеп билгеләнә, 1996 елда вакытсыз үлем аны безнең арабыздан алып китте.

Рәис Беляев...

Тынгылык бирми миңа бу исем. Үзе исән чагында юбилее уңае белән мәкалә дә яздым, вафат булгач хушлашу сүзем дә матбугатта чыкты. Әмма барыбер әйтергә теләгәнемне әйтә алмадым шикелле. Югыйсә миңа әллә ни якын кеше дә түгел бит инде. Бергә уйнап үсмәдек, бер партада янәшә утырмадык, бер табактан ашамадык. Икебезнең юлыбыз ике яктан барды. Ул һәрвакыт түрә булды, мин түрәләрдән көлебрәк йөрүчеләр рәтендә идем. Ул минем барлыгымны да белми иде. Соңрак исемем колагына чалынгалаган булса да хәтерендә калмаганына шигем юк. Үзәк Комитет Политбюросы членнары белән мунча кергән кеше каян инде татар язучысының исемен хәтерләп мәшәкатьләнсен.

Без дә сер бирмәдек. Ул туганнары, дус-ишләре белән шаулап-гөрләп театрга мин язган пьесаны карарга килгәндә бер дә исем китмичә генә исәнләшә идем. Мактанчык бер түрәгә караган кебек кенә карый идем. Ул форма өчен генә исәнләшкәндә, мин дә баш селкеп кенә җавап бирә идем, үземә карамыйча гына күрешергә кулын сузса, мин дә башымны читкә борыбрак кул суза идем дә, эчтән генә "Син дә әллә кем түгел, мин дә әллә кем түгел" дигән татар җырын искә төшерә идем.

Хәтердә бер вакыйга саклана.

Каракалпак язучылары килгәч, аларның бер төркемен Чаллыга алып бардылар. Татарстан ягыннан кунакларны мин озатып йөрдем. Чаллыда безне Рәис Беляев кабул итте. Үзен гадәттәгечә иркен тотып, сүзнең ин саллыларын сайлап, ерак җирдән килүчеләрне котлады да истәлеккә кул сәгатьләре өләште. Миңа сәгать эләкмәде.

Сәгатькә исем китмәсә дә, кунаклар алдында мине түбәнсетүенә ачуым килде. Кабинетыннан чыгып киткәндә ул һәрбер кунакка кулын биреп саубуллашты. Мин махсус ике кулымны кесәгә тыгып чыгып киттем.



Зур проблемалар белән эш итәргә күнеккән иде ул.

Мине чын-чынлап хөрмәт иткән каракалпак язучыларының берсе бүләк сәгатен миңа тәкъдим итте:

- Секретарьлар бөтен җирдә дә мәгънәсез икән, - диде.

Мин инде, әлбәттә, сер бирмәдем, үзебезнең кешене яекладым.

- Без Беляев белән дуслар, барысы да алдан сөйләшенгән! - дидем.

Бу турыда бүген язып та тормас идем, ләкин әлеге вакыйганың ахыры кызыклы.

Еллар үткәч, матур итеп дусларча сөйләшеп утырганда, Рәис миңа урысчалап әйтеп куймасынмы:

- Ты помнишь свой приезд с каракалпаками? Заметил тогда мою ошибку с часами? Знаешь, я не забыл. Когда все уходили, мне стыдно стало. Исправить было уже поздно. Прости, - диде.

Мин онытканга сабышып:

- Хәтерләмим дә инде, - дип ялганладым.

Бу Рәис Беляев холкын билгеләүче бер сыйфат, дип саныйм. Ул үз ялгышын танырга ашыкмаса да, ялгыш ясаганын анлаучы, анын өчен борчылучы һәм җае чыкканда ялгышын төзәтергә әзер кеше иде.

Менә берзаман язмыш безне якынайтты. Чаллының легендар героен Казанга күчерделәр. Өлкә комитетның идеология буенча секретаре иттеләр. Миннән дә үзенә күрә бер төрә кисәге ясадылар - Язучылар берлегенең рәисе итеп сайладылар. Мин Рәис Беляев белән еш очрашып аның күрсәтмәләре буенча эш йөртергә тиеш идем. Ләкин ул бүтән секретарьлар сыман ничек язарга өйрәтеп маташмады. КамАЗдан ияреп килгән, канына сеңгән гадәт буенча төзелеш эшенә чумды. Татар Дәүләт академия театрының яңа бинасы ничәмә-ничә еллар төзелеп бетә алмый ята иде, Беляев көне-төне диярлек шунда ятты. Тукай музее булачак бинаны бик ныклап ремонтларга кирәк иде, Беляев шунда кайнашты. Язучылар берлегенең безгә бирелгән бинасын ремонтлап бетерергә кирәк иде, Беляев аны да үз өстенә алды. Киңәшмәләр үткәрде, утырышлар ясады. Тик аңа Чаллы җитмәгәне сизелеп тора иде шул. Ремонт-фәләннәр аның өчен вак-төякләр генә иде. Зур проблемалар белән эш итәргә күнеккән иде ул.

Республика идеологиның безнең эшкә кысылып, безгә акыл өйрәтеп вакланып йөрмәве миңа ошый иде, әлбәттә. Һәм мин бу кешегә тартыла башладым.

Кабинетына кергәндә мишәрчәләп сөйләшүе дә безнең ише авыл малаеның күңеленә якын иде. Ара-тирә сүгенгәләп алуы да кызык тоела иде. Сүгенүе аның ямьсез түгел, ничектер яңа гына сүгенергә өйрәнгән малайның бүтәннәргә

Беляев студентлар, педагоглар белән уртак телне тиз тапты.

“осталыг“ын күрсәтү кебегрәк иде. Аның үзен-үзе тотышына игътибарсыз гына карасаң, авылның бер хулиган малае дип уйларлык иде. Әмма бу аның авыл малае булып уйнавы гына иде. Мин, Ходайның хикмәте, әлеге уенны вакытында аңлап алдым. Һәм обком секретаре Беляев белән корсакка төртеп сөйләшергә ашыкмадым. Зирәк кеше булганга Рәис Беляев тә миңа тиешле хөрмәт белән сөйләшә башлады.

Язучы буларак та күзәттем - өйрәндем мин әлеге кешене. Анардагы Ходай биргән энергиягә соклана да, әзмәз генә кызгана да идем. Әйе, әйе, кызгана идем. Язмыш аны ялгыш юлдан алып киткән, ахрысы, дип уйлана идем. Холкы-фигыле, “бизбашка”лыгы-болгавырлыгы, туктаусыз кайнап торуы, бик тиз хискә бирелүе белән сәнгать кешесе иде ул. Мин аның гармун уйнавын тыңлаудан бигрәк карарга ярата идем. Бөтен җаны уйный иде аның. Биегәндә җаны бии иде. Ул андый чакта кем белән, кайда утырганын да онытып тора иде шикелле. Бервакыт биегәндә кызып китеп берәр центнерлы ике ханымны, ике кулына җиңел генә күтәреп алып зырылдатып әйләндерде. Талантлы музыкант яки үтә талантлы артист булырга тиеш иде ул.

Хәер, акыллы кеше буларак, артистлык талантын төрле урыннарда түрә булганда да бик оста файдалана белә иде. Үзеннән өстәгеләр белән дә, астагылар белән дә шәп иттереп уйный белде. “Авыл малае” ролен аның кебек башкарган бер генә җитәкчене дә, артистны да күргәнем юк әле минем. Кайберәүләр, “карале, прастуй” халык икән бу дип, Рәис Беляевка бик якын килеп бармакларын аның авызы тирәсендә уйната башласалар, ул әрсез бармакларны тешләп өзәргә дә күп сорамый иде.

Комсомолда чакта партия түрәләре тирәсендә йөреп шактый шомарган булса да, табигать тарафыннан бирелгән ихласлыгын югалтмады Рәис. Андый чакта аның янында булу кызык та, рәхәт тә иде.

Коммунистлар партиясеннән, аның идарә итү системасыннан бүген кайберәүләр көләргә яраталар. Ләкин үзенә кирәк кадрларны күреп алу, үстерү буенча ул партиядән өйрәнергә дә өйрәнергә кирәк әле. Рәис Беляев намус белән хезмәт итте үз партиясенә, үзеннән таләп ителгән эшне җиренә җиткереп башкарды. Кайвакытта Рәис Беляев “кыланышлар”ын искә төшерәләр. Бүтән түрәләрдән артыгын кыланмады Беляев. Дөресен әйтергә кирәк, әгәр дә ул “кыланмаса”, андый карьера эшли алмый иде. Партия җитәкчелегендә тәртипле, тыйнак, тәти мокытларны тотмыйлар иде. Рәис, бу системаны бик тиз төшенеп алып, төлкеләр белән төлкечә, бүреләр белән бүречә яшәү серен үзләштерде. Сарыклар белән сарык булырга гына теләмәде, гаҗәеп сизгер кеше иде ул.

Чаллыдан китеп ничек алданганын мин әле дә аңлый алмыйм. Күрәсең, сәнгать кешеләренә хас беркатлылыкның чаткысы аның акылын томалагандыр. Сәнгать кешеләрен һәрвакыт алдыйлар бит. Дәрәҗәле исем биреп тә авызларын каплыйлар, теге яки бу мәҗлескә чакырып мактап та үсендерәләр җаннарымны. Кул чапканга алданып яши торган халык бит инде алар, нишләтәсең. Аларны төзәтеп тә, тәрбияләп тә булмый. Минемчә, Казанга килеп обком секретаре булып эшли башлагач алдануын сизде Беляев. Ләкин Чаллыга кире китәргә соң иде инде. Әлегрәк ничек иде? (Хәер, хәзер дә шулайдыр ул.) Берәр кешедән котылырга кирәк булса, әмма куарлык сәбәп табылмаса, ул кешене үстерәләр иде. Югарырак урынга, көче җитмәсрәк яки табигатенә ятрак эшкә күчерәләр иде. Күпләр шул “үскән” урыннарында яналар һәм юкка чыгалар иде.

Рәис Беляевне дә “үстерделәр”. Һәм энергиясе ташып торган, җир җимертеп эшләп йөргән, өр-яңа шәһәр төзегән кеше безнең арага кереп батты. Язучылар, артистлар, рәссамнар, композиторлар - ыгы-зыгылы халык. Без бер-беребезне бик яхшы аңлаганга шау-шу килсәк тә, үзара уртак тел табабыз. Җүләрләр йортының да бүтәннәр аңлап бетерә алмаган үз тәртибе бар. Чын акыллы кеше дә анда бик тиз акылдан яза.

Юк, мин үзебезне мыскыл итәргә җыенмыйм. Мин шул “җүләрләр йорты”ның бер пациенты булуым белән хәтта горурланам. Акыл белән көн итәргә маташучылардан көләм.

Табигать Рәис Беляевне безнең “агай-эне” итеп яратса да, ул инде, әйткәнемчә, “бозылып” өлгергән иде. Безнең уен тәртибен аңлый алмый интекте. Суслов кебек салкын, рәхимсез, хәйләкәр идеолог чыкмады анардан. Аны өстәгеләр бик тиз аңладылар. Капкынга әләкте арыслан.

Мәскәүдә узган Тукай һәм Җәлил юбилейларында әчү мәҗлесе оештырган дип юлдан алып ыргыттылар Беляевне. Форма өчен генә юбилейда катнашып, мәҗлестә утырганнарга, ягъни мәсәлән, безгә дә выговор чәпәгән булдылар. Ләкин нәрсә ул безгә выговор? Ул чакта, билгеле, безнең өчен дә партия выговоры бүләк түгел иде түгелен, әмма безнең кулдан каләмне тартып ала алмыйлар. Аннары, без кыйнала-сүгелә, эт типкесендә йөреп каешланып беткән, югалтасы нәрсәбез дә юк, шуна күрә ничек тә тырмашабыз. Ә партия түрәләре капкынга бер эләксә, котылу юк инде. Карьерасы белән бергә шәхесен дә югалталар иде алар.

Рәис белән дә шулай була язды. Президиум өстәле артыннан безнең рәткә төшеп утырды. Як-ягына каранды, элек аны уратып алган эреле-ваклы түрәләр каядыр киткәннәр. Янында без генә калганбыз икән.

Әгәр дә мин психологик романнар язучы кеше булсам, Рәис Беляевнең шул чоры турында калын китап язар идем. Аның бәргәләнүләрен, рәнҗүен, үз-үзен битәрләвен, алдануларын сизеп ачынганын мин аңлый идем. Канаты имгәтелгән бөркетнең җиргә егылып төшеп тә очарга азаплануын күреп тору ифрат авыр иде.

“Мин Беляев белән корсакка төртеп сөйләшергә ашыкмадым”...

Без - иҗат кешеләре, түрәләрне әллә ни өнәп бетермәсәк тә, аны ташламадык. Обком пленумнарында янында беркем утырмаса да, Марсель Сәлимҗанов белән икебез ике ягында була идек. Безнең арада ул күпмедер дәрәҗәдә юаныч тапты, аңына килде, тернәкләнә башлады. Бәхетенә каршы, хатыны Фәһимә ханым да сизгер һәм акыллы хатын булды.

Рәис Кыямович Беляев мәдәният институтының ректоры булып эшли башлады.

Беляев колачы өчен бу эш бик бәләкәй иде, әлбәттә. Әмма сайланырга мөмкинлек калдырмадылар аңа. Теләр-теләмәс кенә эшкә тотынды ул. Ләкин бара-тора үз стихиясенә кереп китеп, институтны республикадагы югары уку йортлары белән ярышырлык дәрәҗәгә күтәрде. Институт инде, сәнгать академиясе дәрәҗәсен алып, анда укырга теләүчеләр күбәйгәннән күбәйде.

Тәхеттән төшерелгән түрәне башта институтта өнәп тә бетермәгәннәр иде,

Гаиләсендә, оныкларында ул юаныч тапты.

әмма Рәис педагоглар, студентлар белән дә уртак телне тиз тапты. Аны хөрмәт итәләр һәм яраталар да иде.

Эшләгән эшеннән тәм тапса да, булганы белән канәгатьләнә белмәүче тынгысыз Беляевнең планнары зурдан булды. Ул аларны очынып-очынып миңа сөйли иде. Тик менә көтмәгәндә-уйламаганда йөрәге тибүдән туктады. Аны соңгы юлга озатырга бик күп кеше килгән иде. Рәис Беляевне кыйнаганда дәшмичә калган “дуслары” да шактый күп килде. Алар мәет өстендә нинди уйлар уйлаганнардыр, белмим. Бәлки, дусларының рухыннан сонлап булса да гафу үтенергә килгәннәрдер.

Мин аларны әллә ни гаеплисем дә килми. Безнең тормыш шундыйдыр инде. Әгәр дә бәлагә юлыккан кешене якласаң, үзеннең дә шул кеше хәленә калуың ихтималдыр. Хәер, алай дисән, мин Беляевне яклап ачыктан-ачык үз фикеремне пленум трибунасына чыгып әйтсәм дә, мине эзәрлекләүче булмады.

Менә Рәис Кыям улы Беляев турында тагын яздым. Тик барыбер күңелемдә канәгатьсезлек. Фаҗигале заманның фаҗигале шәхесе турында уйлануларымның бик әзе генә монда. Дөнья тәгәрмәчен әйләндерергә туган шәхеснең шул тәгәрмәч астында калып һәлак булуын сөйләр өчен роман язарга кирәк.

Мин ул романны язарга ничә тапкыр утырдым. Көчем җитмәгәнне тоеп туктадым. Яза алмамдыр, ахрысы. Минем өчен авыр булган жанрда психологик кичерешләрдән торган роман язарга көчем дә, гомерем дә җитмәстер.

Һич булмаса, шул языла алмаган романның ничә тапкыр башлап, ничә тапкыр тукталып калган беренче битләрен язып калдырыйм.

“Әллә нинди төн иде ул. Кичтән буран котырды. Аннан кинәт аязды. Тулган ай күктә пәйда булды. Ап-ак җир өстенә гаҗәпләнеп һәм сокланып карап торды. Йолдызлар да күзләрен кыскалап җирне күзәттеләр...

Кинәт кенә әллә кайдан адашып калган җил килеп чыкты. Дөнья тагын бөтерелергә тотынды. Салкыннан туңган агачлар ыңгырашып, капкалар шыгырдады. Капка баганасына беркетелгән ятим сыерчык оясы сызгырды, өй түбәсендәге калай шапылдады, кар бөртекләре тәрәзәләргә ком булып сибелде...

Буранның дулавына кичтән үк иләшеп өлгергән авыл, ни булса шул булыр, дип йоклый иде.

Югары очтагы бер өйдә генә ут яна. Тулгак тотып интеккән Сәрбиҗамал тирәсендә кендек әбисе Шәмсеҗиһан карчык бөтерелә иде.

- Хәзер, кызым, хәзер... Сабыр, сабыр, сабыр... Беренчесе түгел бит инде, нигә алай бәргәләнәсен?.. Йә, йә, була... Менә хәзер, менә хәзер... - дип туачак баланың әнисен юата иде ул...

Ниһаять, бала дөньяга килде. Ир бала. Кендек әбисе гадәттәгечә баланың арт чүмеченә уч табаны белән сугып алды. Бала җылап җибәрде.

- Тавышы төптән чыга. Ни житте генә булмас бу, - диде Шәмсеҗиһан карчык.

Хәлсез ана елмайды.

Кендек әбисе тарафыннан чоланга куып чыгарылган Касыйм ике улын толыпка төреп чоланда утыра иде. Балаларны алып күршеләргә керергә кушты-лар ана, ул кермәде. Чоланда фонарь яндырып утырды, өйдән бала тавышын көтте. Колакка сак иде ул, авылның танылган гармунчысы иде. Чоланга керә алмаган ачуыннан ишек артында җил сызгырса да, баласының тавышын ишетәчәк иде.

Һәм ишетте дә. Ишетүгә толып эченнән инде йокыга китеп маташкан ике малаен тартып чыгарып:

- Булды бу, анасын саткыры! - дип кычкырды ул һәм өйгә атылып кереп караватта яткан хатыны янына тезләнде.

- Булды бу, хатын. Маладис! - дип Сәрбиҗамалны кочакламакчы иде, кендек әбисе:

- Салкын тидерәсең бит, юньсез! - дип аны янадан куып чыгарды.

Чоланда рәхәтләнеп дулады Касыйм. Ана ике малае иярде. Фонарьның сүрән яктысында аларның сикерешүе, күләгәләренең чолан тактасында уйнавы сихри әкиятне хәтерләтә иде.

Малайга Рәсим дип исем куштылар".

Бу язылмаган роман башының әллә ничәнче варианты. Шуннан ары китә алмыйм.

Романның ахыры да күңелдә йөри. Шуны да язып куйыйм, булмаса.

Хәер, кулыма каләм алгач, роман уртасындагы иң киеренке, кульминация ноктасын да теркәп калдырыйк. Болайрак булырга тиештер инде ул.

"Көз айларын ярата иде Рәсим. Яз, җәй айларында хуҗасын сагынып көткән гармуны белән ешрак кавыша иде ул. Күңеле якты моңсулык белән тула иде. Бабалары теленнән сөйләшүдән бизгән булса да, гармуны аны малай чагына алып кайта, әнисенең назлап әйткән сүзләрен искә төшерә, әтисе уйнаган шаян-сагышлы көйләр күңел кылларына чиртә. Ярты сәгать, кайвакытта берәр сәгать гармун күрекләрен тартып өзәрдәй итеп тә, гармунны тезләрендә биетеп тә, бармакчаларга сизелер-сизелмәс кенә салмак кагылып, гармун иркенә үзе буйсынып та уйный иде. Көз аңа дәрт бирә, күңелен җилкендерә, җанын кытыклый.

Көзнең бүгенге көне эчпошыргыч, шомлы, шыксыз. Эшләнеп бетмәгән дача өенең тәрәзәсенә пыяласын тишәргә теләгән сыман карлы яңгыр бәреп ява. Өй каршына утыртылган чиянең шәрә ботаклары пыялага сыдырылып-сыдырылып алып, җан сорап килгән әҗәлнең сөяк бармаклары белән тәрәзә шакыганын хәтерләтәләр. Шундый эт чыкмаслык көндә нигә килде соң әле ул монда? Югыйсә, җәйнең матур көннәрендә дә сирәк килә иде. Бер-ике тапкыр дусишләре белән шаулы компания булып чирәмдә утырып киткәне генә бар. Дәрәҗәле җитәкчеләр өчен генә бирелгән бу җирдә күпләр инде менә дигән йортлар җиткерделәр. Ул гына ашыкмады. Хатынының:

- Бүтәннәргә кара, бераз гына хурлан ичмасам, - диюенә, - сиңа ЦК санаторийлары җитмимени? Кайчан да кайчан иренне пенсиягә озатырлар, шул чакта җирдә казынырсың, рәхәтләнеп икәү дачада яшәрбез, - дия иде.

Менә ул көн килеп җитте. Пенсиягә чыгарга ун ел кала тәхеттән алып ыргыттылар һәм ул бер ялгызы тезелеп бетмәгән өенең тәрәзәсе төбендә шөкәтсез дөньяга карап утыра.

Күңелендә бушлык. Ләкин әле өмет сүнмәгән. Обком бюросында әйтелгән мәрхәмәтсез, рәхимсез, нахак сүзләрнең ачысы бераз басылган. Аек акыллы кеше буларак, ул белә: аңа инде киләчәккә юл киселгән, бер егылганны монда күтәреп торгызмыйлар, шулай да өмет бар. Дуслары, җыелып ук булмаса да, берәмләп килеп хәленә керерләр, юатырлар кебек. Тик берәү дә күренми.

Башта ул аларны өендә көтте. Телефоннан шылтыратмаячакларын белә, чөнки телефон тыңлана, кемнең кемгә шылтыратканы минуты-сәгате белән тиешле җиргә барып җитәчәк. Берәү дә үз язмышын Рәсим аркасында кыл төбенә куярга теләмәс. Ләкин бит өйгә килеп китәргә була. Көтә-көтә арыгач аңлады - килмәячәкләр. Ул яшәгән йортта кемнәр торганы һәм кемнең кемгә йөргәне билгеле ләбаса. Кайсы җүләре тәвәккәлләп килсен.

Рәсим кем тарафыннандыр бүләк ителгән плащ-палаткага төренеп урамга чыкты. Бәлки, берәрсе машина белән махсус үтеп китешли тукталыр да, аның кайгысын-хәсрәтен уртаклашыр. Юк, үтүче булмады. Тәссез, ямьсез, иләмсез, котсыз урам буш иде.

Аннан соң Рәсим дачасына китте. Бәлки, дусларының берсе шунда сугылыр. Ни әйтсәң дә аулаграк урын. Бәлки, әле кайберләре шундагы дачаларындадыр. Рәсим килгәнне махсус көтәләрдер. Юк, килүче дә, керүче дә табылмады. Дөнья белән күзгә-күз калды Рәсим. Япа-ялгыз. Юаныр өчен дуслар да юк, сугышыр өчен дошманнар да юк..."

Инде килеп романның ахырын язып куйыйк.

"Җәйнең иң матур көне. Кояш көлә, кояш елмая. Җылысы белән һәркемне назлый, иркәли. Мондый көндә шәһәрнең таш йортларыннан качып табигать кочагына чумасы килә. Хуш исле яшел үлән өстенә чалкан авып зәңгәр күккә багып ятасы, хозурланасы килә. Юри генә ялкауланасы, дөньясына кырын күз белән карап гамьсез булып кыланасы килә. Адәм баласына да ял кирәк ләбаса.

Ләкин Рәсим ял итә алмый. Институтта имтиханнар чоры - урак өсте. Укытучыларның вәкарьлеге йөзләренә чыккан чак. Кыш буе укымыйча, лекцияләрне "тозлап" трай тибеп йөргән студентлардан бүген алар үч алалар.

Студентларның кайберләре чыннан да борчыла бүген. Куркалар. Элегрәк исәнләшергә оныткан педагогларын ясле балалары кебек хор белән сәламлиләр. Кыска итәкле, озын һәм шәрә ботлы кызлар инсафлы икәнлекләрен күрсәтү өчен өлкән яшьтәге хатын-кыз укытучылар белән очрашканда итәкләрен тарткалап куйгандай итәләр. Ир затыннан булган педагоглар белән исәнләшкәндә киресенчә итәкләрен күтәребрәк куеп, төче итеп елмаялар.

Рәсим шул кызлар арасыннан кабинетына атлый. Барысы белән дә елмаеп исәнләшә. Күңелдә вәсвәсәле уйлар. Әмма андый уйларны тизрәк куарга кирәк, вәсвәсәгә бирелергә ярамый. Сокланырга мөмкин, кызыгу тыела. Болай да инде гөнаһы шактый җыелгандыр.

Күңеле шат Рәсимнең. Иртәгә ул, ниһаять, туган авылына кайтачак, малайлык сукмакларыннан тагын бер кат үтәчәк, урман аланында дуслар белән учак ягып төн уздырачак.

Рәсим кабул итү бүлмәсендәге секретарь кызга сәлам биреп үз бүлмәсенә узды. Кәнәфиенә утырып маңгай тирләрен сөртер өчен кульяулык алырга дип янтаеп чалбар кесәсенә тыгылды һәм шул хәлендә идәнгә авып төште. Бу мизгелдә ул ниләр уйлап өлгергәндер, берәүгә дә билгеле түгел. Уйлаганнарын әйтеп калдырырга вакыт бирелмәгән иде...

Җеназасына кеше бик күп килде. Җитәкләүчеләр дә, җитәкләнүчеләр дә бергә кайнадылар. Сүзләр сөйләнде, истәлекләр белән уртаклаштылар. Мактадылар, әлбәттә. Ләкин Рәсимгә ни әйтсәләр дә барыбер иде инде".

Яздым да язуын, роман күңелсезрәк бетә икән шул. Әсәрнең ахырын өметсез итеп тәмамлауны мин яратмыйм. Бәлки, кабат-кабат уйланып романны язсам, бүтән төрле финал да табылыр иде. Тик бу очракта күңелгә шундый җөмләләр килде. Нишләтәсең, еш кына иҗат эше безнең теләккә, безнең ихтыярга буйсынмый шул. Кабатлап әйтәм: Рәис Беляев иҗат кешесе иде.

Октябрь, 1998.

Журнал өчен фотоларны Рәис Беляевнең тормыш иптәше Фәһимә ханым тәкъдим итте.

Сарман

“Чебешне күз күне саныйлар, диләр. Безгә, мөгаен, алай мәшәкатьләнәсе булмас. Чөнки безнең чебиләр, үрдәк бәбкәләре җәйдән үк кырылып беттеләр.

Быел май аенда Тәкермән күмәк хуҗалыгы хезмәт хакы исәбенә Сарман инкубатор-кошчылык станциясендә чыккан чебиләр алып кайтып өләште. Әмма никадәр генә тәрбияләмик, аларны тернәкләндереп булмады, үлеп беттеләр диярлек. Исән калганнарының да күзгә кадәр торуы икеле.

Станция чыгарган үрдәк бәбкәләре дә кыска гомерле булды.

Бездә Чаллы, Түбән Кама кошчылык фабрикаларында чыккан чеби, үрдәк-каз бәбкәләрен алып кайтып үстерүчеләр дә шактый. Берсе дә үлми”.

Х. Хәсәншин атлы авторның “САРМАН” газетасында басылган “Санама, карчык, санама” дигән язмасыннан китерелде бу факт. Хәбәрче, Сарман чеби-бәбкәләренең һәр елны чәрексез булуын исбатлап, моның сәбәпләре хакында да фараз йөртә. Станциядә йә йомыркаларны алып кайтканда салкын тия, йә эштә технология бозыла торгандыр.

Кошчылык станциясе житәкчеләре, белгечләр моның сәбәпләрен эзләргә һәм ачыкларга, халыкка саусәламәт, таза чебиләр һәм бәбкәләр генә сатарга тиешләр.

Минзәлә

“МИНЗӘЛӘ” газетасы үз укучыларына Коноваловка авылында яшәүче Нәгыймә Шәрифҗанованың йөрәк авазын җиткергән. Безнең журналны укучыларга да гыйбрәт булыр ул.

“Мин... күңелемне җәрәхәтләгән, дистә еллар буе тынгы бирмәгән бер нәрсә белән уртаклашырга булдым.

Балаларымны татарча өйрәтә, татарча укыта алмавым күңелне әрнетә. Шуңа күрә үземне җәмгыять, Ходай Тәгалә каршында гөнаһлы саныйм.

Улым татар кызына өйләнде. Ләкин киленебез дә чатырдатып татарча сөйләшә алмый, гәрчә әйткәннәрнең барысын да аңлый. Улымның да телне белү дәрәҗәсе шул чамадарак.

Инде кызыма килгәндә, ул татар теленә нисбәтән шыр надан. Атанаң татар була торып, туган телендә сөйләшә-аңлаша алмаудан да хурлыклы, кимсетелерлек нәрсә бармы соң бу дөньяда!

Без атасы белән шуңа сөенәбез: ярый әле үзебез руслашып бетмәгәнбез.

Миңа хәзер 52 яшь. Әнием яраткан җырларны иңләп кенә көйләп йөрим. Балаларым исә моннан да мәхрүм.

Әйтер сүзем шул: өегездә, урамда, эштә татарча сөйләшегез, балаларыгызны, оныкларыгызны татарча укырга-язарга өйрәтегез. Элеккеге хаталарны төзәтүе кыен. Терсәк якын, әмма аны тешләп булмый”.

Чирмешән

Хәзерге заманда мәзәкләр урнаштырмаган газетаны табу кыен. “БЕЗНЕҢ ЧИРМЕШӘН” газетасы да “Мәзәкләр” исеме астында рубрика алып бара. Шул рубрикадан бер мәзәк.

Тәмәке белән котылган

Кода базарда икенче авылдагы кодасын очраткан да аны өенә алып кайткан. Утырышкач, хуҗа:

- Әйдә, чәй кайнаганчы бер тартып керик әле! - ди.

Бер тарталар - чәй юк, ике тарталар, өч тарталар - чәй һаман юк. Көн кичкә авыша.

- Ярый, кода, миңа кайтырга вакыт! - ди кода.

- Ярый инде, алайса, хуш иттек. Икенче килгәндә кодагыйны да алып кил! - ди хуҗа.

- Әй, кодакаем, - дип җаваплый кунак, кодагыең тәмәке тартмый шул.

Түбән Кама

Татарстан хор сәнгате тарихында беренче буларак “Мечта” дигән Түбән Кама балалар музыкаль-хор коллективы XXIX Бөтендөнья хор конгрессында катнашкан.

Менә илле елдан артык инде барлык кыйтгаларның иң яхшы хорлары дөньяның иң матур каласында җыелып, иҗат уңышлары белән уртаклашалар. Быел конгресс Испаниянең иң гүзәл шәһәрләреннән берсе Барселонада узган. Бу конгресска кадәр “Мечта” хоры Мәскәүдә узган VI Бөтендөнья хор ассамблеясендә һәм Болгариядә үткәрелгән I Бөтендөнья хор ассамблеясендә уңыш казана. Бу коллектив Россиядән Барселона конгрессында катнашкан биш коллективның берсе була.

Конгресс йөз унөч хорның җиде мең башкаручысы катнашында алдан өйрәнелгән берничә җырны башкару белән ачыла. “Мечта” икенче көнне шәһәрнең бер соборында үз программасы белән чыгыш ясый. Шул ук көнне ул иң яхшы коллектив буларак конгрессның гала-концертында катнаша. Коллективның чыгышы тамашачылар тарафыннан көчле кул чабулар белән каршылана. “Моннан да яхшырак башкаруны ишеткәнем юк иде”, - ди Америка хорлары федерациясе президенты Патрик Флайв. “Сезнең хор иң яхшысы булды”. - Бу - Каталониядән хормейстер Карина Фаберг фикере.

“Мечта”ның Маскоу шәһәрендәге чыгышы да коллектив өчен онытылмаслык була. Концертка бөтен шәһәрчек халкы җыелгандай тәэсир кала. Тыңлаучылар аяк өсте торып кул чабалар.

Хор җитәкчесе С. Калинкина һәм концертмейстер И. Короткова, “ЛЕНИНСКАЯ ПРАВДА” газетасында шатлык-куанычларын уртаклашып, әлеге бәхетле сәяхәтне оештыручыларга - шәһәр һәм район хакимияте башлыгы И. Метшинга, “Камател” җәмгыяте директоры Р. Дибухка, “Интеркомбанк” директоры О. Двоеглазовага һәм башка спонсорларга рәхмәт белдерәләр.

Ютазы

Су чыганакларын төзекләндерү күптәннән изге гамәл саналып килә. Ютазылылар бу традицияне дәвам иттерәләр. Ютазы авылының җәмәгать оешмалары, аерым алганда хатынкызлар шурасы (рәисе - Н.Хөснетдинова), сугыш һәм хезмәт ветераннары шурасы (рәисе - Ф. Латыйфуллин), мөселманнар җәмгыяте (Ф. Зәйнуллин) инициативасы белән ял көннәренең берсендә, кырык эшне кырык якка ташлап, плакатлар күтәреп, җырлар җырлап авыл читенә чыгып киткәләр. Алар өч чишмәне чистарталар. Бер чыганак яныннан гына да бер “КамАЗ” чүп төяп озаталар. Коръән сүрәсен укып, Фатыйх хәзрәт ике чыганакка “Наратлы чишмәсе”, “Бөдрә каен” дигән исем куша.

Энтузиастлар башлангычын җирле предприятиеләр һәм оешмалар күтәреп ала. Алар йөк машиналары, автобуслар җибәрәләр, туклануны оештыралар.

“ЮТАЗИНСКАЯ НОВЬ” газетасы яктырткан бу күркәм тәҗрибәне районның башка авылларында гына түгел, ә республика күләмендә җәелдерә алсак, никадәр файдасы буласы.

Мөслим җире алтынлы

**Рифат ФӘТТАХОВ,
Госман ГОМӘР.**

Р. М. Шәрипов.

Күптәннән җыена идек Мөслим якларына. Беренче сәбәбе - Рөстәм Мирзагали улы Шәрипов район хакимияте башлыгы булып сайлангач, Рамазан-шәрифтә авылларда хәмер сатуны тыйган иде, шул уңайдан барасы иттек. Әмма бу сәфәргә җыену озаккарак сузылды. Инде менә алтын вакыйгасы калкып чыкты...

Яшел төбәк. Сезнең җәйге кичтә Мөслим урамнарыннан узганыгыз бармы?

И, андагы хозурлык! Үзәктәге Пушкин урамының (әйтик, ни өчен әле Колгали яки Колшәриф урамы түгел?!) ике ягы буйлап ябалдашлы юкә агачлары тезелгән. Кичке эңгердә алар, күктә ак юл калдырып, күрешергә, кавышырга теләгәндәй бер-берсенә якынаялар. Сихри тынлык, екияти хозурлык. Язгы-җәйге кичләрдә Ык сандугачларының моңлы җыры урамның бер башыннан икенче очына таба агыла. Тирән итеп бер суласаң, бал исеннән башлар әйләнә. Бәхетле инсаннар яши бирдә.

Җир-суына, урман-тауларына күз сал син аның. Урал таулары нәкъ шушыннан башлана инде. Тау итәгеннән иркәләнеп кенә боргаланып-сыргаланып мул сулы Ык елгасы ага. Хикмәт әнә шул тауларда, елганың комлы ярларында инде.

Ләкин бу хакта бераз соңрак...

Табигать үзенең байлыгын кызганмаган бу төбәккә. Мөслим күршесе Азнакай, Сарман, Минзәлә, Актаныш, Башкортстанның Бакалы районнары белән чикләнә. Районның гомуми җир мәйданы 146.431 гектар тәшкил итә. Шуның 96.024 гектары файдаланудагы сөрү җирләре. Бирдә 19 җирле үзидарә бар. Алар 71 авылны берләштерә. Заман таләпләренә туры китереп районда 22 күмәк хуҗалык, 6 совхоз, бер крестьян-фермер хуҗалыгы ассоциациясе, өч ярдәмче хуҗалык оештырылган. Болары турыдан-туры авыл хуҗалыгы продуктлары житештеру белән шөгыльләнә. Узган ел бөртекле-кузаклы культураларның һәр гектарыннан уртача 34 центнер уңыш җыеп алынган. Быел исә озакка сузылган корылык район икътисадына нык кына бәргән, бөртеклеләрнең һәр гектарыннан 12 центнер ашлык чыккан. Хакимият башлыгы Рөстәм әфәнде Шәрипов бу хәл белән һич тә килешергә теләми, киләчәктә табигать бәла-казаларына әзер булып торырга, аны җиңә белергә кирәклеген искәртә. Әйдә, бары тик шулай гына булсын!

Район хакиме дәүләткә ашлык сату планын үтәп чыгуларына, житәрлек күләмдә чәчүлек орлык, яртылаш кына булса да фураж салып куюларына куана. Терлек азыгы дигәннән, районда салам, печән кебек тупас, силос, сенаж ише сусыл азыклар мулдан хәзерләнгән. Көзге чәчүне, тунга сөрүне агротехник срокларда үткәргәннәр. Киләчәк турында сөйләгәндә Рөстәм әфәнде, бәлки, шушы нәрсәләрне дә күз уңында тоткандыр.

Җыеп алынган байлыкны ашлык кабул итү пункты директоры Хәмзә әфәнде Мирзанов урнаштыра. Ул бу постка 14 ел колхоз рәисе булып эшләгәч килгән. Алдан ук ашлыкны саклау чараларын күргән. Эшчеләргә хезмәт хакын айданайга биреп бара, он, ит, май, бал белән дә тәэмин итә. Халыкка көнкүреш техникасыннан алып жинел автомобильгә кадәр бирә. Хезмәт хакы хисабына 12 гаилә "Жигули"ле булган. Тагы ике заявка бар.

Төбәктә авыл хуҗалыгын үзгәртеп коруга, продукцияне эшкәртү сәнәгатен үстерүгә нык игътибар ителә. "Метрәй" ассоциацияләнгән крестьян-фермер хуҗалыгы шундый беренче карлыгачлар-

Табигать үзенең байлыгын кызганмаган бу төбәккә!

дан саналырга хаклы. Хуҗалыкны тәҗрибәле игенче, галим-агроном Рафаэль Зиннур улы Камалов җитәкли. Ул хезмәтен гади механизатор булып башлаган. Кечке мәктәптә укып урта белем алган. Армиядә чыныгу уза. Кызык бит! Өйдә улларының хәрби хезмәттән кайтуын зарыгып көтәләр. Ә Рафаэль Казанда туктап кала. Югары уку йортына керү өчен хәзерлек курсларында укый. Имтиханнарда гел дүртле-бишле билгеләре генә алып, Казан авыл хуҗалыгы институтының агрономия факультетына укырга керә. Инде эти-әнисен сөендерсә дә ярый. Гаиләдә очрашу әнә шулай икеләтә куанычлы була. Аннары диплом сөенече. Уналты ел дәвамында Рафаэль әфәнде өч колхозны аякка бастыра. Бусы дүртенчесе.

Моннан өч ел элек "Метрәй"гә килгәч тә эшне үзгәртеп корулардан башлый ул. Җир крестьяннарга бүлеп бирелә, шулай итеп, фермер хуҗалыклары оештырыла, аннары алар ассоциациягә берләшеп, "Метрәй" берләшмәсен төзиләр, генераль директор итеп сыналган җитәкчеләре Рафаэль Камаловны сайлап куялар. Наряд бирүләр, эшкә кушулар бетерелә. Гомумән, бередә бригадир дигән вазыйфа бөтенләй юк. Кешеләр һәр эшне үзләре белеп башкара, үземнеке дип хезмәт итә. Хуҗалыкта бары тик намуслы, сәләтлеләр генә кала. Белгечләргә исә контрольлек вазыйфасы йөкләнә. Заманча, яңача эшләү системасы менә шулайрак көйләнгән.

Үзгәртеп коруларның хуҗалык икътисадына тәэсире ничегрәк диярсез инде. Чокыр-чакырлы тауларда, әрләм балчыклы җирләрдә бөртекле-кузаклы культураларның һәр гектарыннан быелгы авыр елда да уртача 24 центнерга якын уныш җыеп алынган. Кыйммәтле ярма культурасы саналган карабодайдан ул 18 центнер чыккан. Киләсе ел уңышы өчен 600 гектарда арыш, 100 гектарда көзге бодай чәчеп калдырылган. Хуҗалыкта терлекләрнең барлык төре дә асрала. Шул нигездә эшкәртү предприятиеләре төзелгән. Монда җитештерелгән сырны, мәсәлән, күп җирдә бик теләп алалар. Мөслимдә, Чаллыда фирманың үз кибетләре бар. Аларда ит, май, сөт, катык, сыр гына түгел, балы, балыгы да сатыла. Бал дигәннән, хуҗалыкның урманда 300 баш умартасы бар икән. Мәсәлән, Ольгино бригадасындагы 100 баш умартаның һәркайсыннан уртача 28 килограмм тамак төбенне өтеп алырлык шифалы чәчәк балы алынган. Су саклагычта карп, сазаннар симерә.

Яңалык юлны тиз яра. Метрәйлеләр үрнәгендә эшләүче "Дуслык" крестьяннар ассоциациясе берләшмәсе, "Сәфәр", "Кырымтау" фермер хуҗалыклары тотрыклы эшләү юлына басканнар. Соңгы икесендә алтышар егет, 200 әр гектар җир алып, югары хезмәт үрнәкләре күрсәтә. Алар таркалган авылларны янадан торгызалар, яшәешкә җан өрәләр.

- Үзгәрми мөмкин түгел, башкача яшәп булмый, - ди район хакиме.

- Рөстәм әфәнде, хәмер мәсьәләсенә кайтыйк әле. Сезнең районда төрле милләт вәкилләре яши, аракысыз калуны алар ничек кичерде соң теге чакта? Район бюджетына да сукканды бит.

- Без, әнә шулай, олы брат нәрсә әйтер дә, кече братка зыян салмыйбызмы, тегеләй-болай итсәк, ертык-тишек зураймасмы, дибрәк яшәргә күнегеп киткәнбез. Иман, әхлак нормаларын онытып бара-

Р. Гыймаев һәм М. Нәбиев махсус иләкләр ясатып куйганнар.

Данлыклы "Метрәй" хуҗалыгын Р. Камалов җитәкли.

Җыеп алынган байлыкны ашлык кабул итү пункты директоры Х. Мирзанов урнаштыра.

быз. Хакимияткә килеп эшли башлавымның беренче елында ук Рамазан-шәрифтә аракы сатуны тыю үзенә күрә бер инкыйлаб булды ул. Шулай да халык хуплап каршылады: мөселманнар гына түгел, урысы, марие, районда яшәгән барлык милләт вәкилләре. Алай гынамы әле, килеп үземә рәхмәтләрен җиткерделәр, "Башлар айныды, акча да янга калды", - дип куандылар. Моны гадәткә кертергә исәп.

Ә бюджет мәсьәләсенә килгәндә, анын районга бер тиен дә зыяны юк. Хәмерне җитештерүчеләргә, бәлки, бардыр да. Без бит сатып алганны гына сатабыз, акчаны бер кесәдән икенчесенә күчерү сыманрак килеп чыга. Ә халык аек. Бу инде зур нәрсә! Мин булып кайткан Согуд Гарәбстанында, Әмирлекләрдә аракы сатмыйлар бит, халык әнә ничек яши!

Хакимиятнең аракы сатуга вакыт-вакыт вето салуына тагын бер сәбәп бар икән әле. Хәмер аркасында авыру балалар туу очраклары ешайган. Андыйлар Мөслимнең үзәк балалар бакчасында да бар. Алар аерым группада тәрбияләнә. Авыру балалар белән махсус логопед шөгыльләнә. Монда Нәфисә Мәннапова, Әлфирә Ильясова, Гөлүзә Хәйретдинова, Ләйсирә Фазлыева кебек тәрбиячеләргә эш җитәрлек. Яшь буынны тәртипле, инсафлы итеп үстерүгә күп көч куя алар.

Кешеләргә рухи азык җитми бу заманда, илдәге икътисадый кризис аларны тупасландыра, әхлаксызлыкка этәрә. Районда менә шушы нәрсәне сындырырга ниятләгәннәр. Клуб, мәдәният йортларының йозаклары ачылган. Башта кадрлар барлана, бу өлкәдә эшли алырлык кешеләр туплана. Аннары кирәкле уен кораллары сатып алына. Үзешчән сәнгать түгәрәкләре оештырып җибәрелә. Ниһаять, Мөслим халык хорының элеккеге даны кире кайтарыла. Ансамбльнең чыгышларын хәзер тирә-як төбәкләрдә дә күрергә туры килә. Тикмәгә генә бу яктан Ф. Мусин, Л. Шәрифуллин, Г. Гәрәев, В. Гайфуллин, Р. Шәймәрдәнов, М. Вәлитов, Р. Ганиев, Д. Галләмова, Р. Мөхәммәтҗанов кебек галимнәр, фән докторлары һәм кандидатлары, Зөлфәт, Харрас Әюп, Шәмсия Җиһангирова, Наис Гамбәр, Флүс Латыйпов һәм Фоат Садриев кебек әдипләр, Наил Әюпов халык артистлары үсеп чыкмагандыр инде, мөгаен! Халкыбызның кабатланмас моң иясе Зифа Басыйрова да шул төбәктән. Татарстанның Актаныш, Мөслим районнары үзенең чын татарлыгын саклап калган сирәк төбәкләрдән исәпләнә. Ходай куәт бирсен аларга киләчәктә дә!

- Мөслим алтын өстендә утырамы, Рөстәм әфәнде?

- Шулай диләр ич.

- Сездә нинди мәгълүматлар бар соң?

- Кызыл кырачлы таулары да, сары комлы Ык буйлары гына әлегә.

Табигатьнең сер сандыгы - алтын хәзинәсе әнә шул тауларга, комлыкларга яшеренгән икән бит. Галимнәрнең исәпләвенчә, Татарстан җирендә кимендә 20 тонна алтын запасы бар. Идел буендагы "Монастырь чокыры" һәм Шөгер тирәсендәге "Күкертле чишмә" чыганаклары хакында элек тә сүз йөри иде. Чыннан да ул төбәкләрдә шактый алтын запасы булганлыгы ачыкланды. Ә менә "Уфа катламы" токымы дигәне барыбызны да дерт иттерде. Бусы күбрәк Мөслим районына туры килә инде. Мөслимнән нибары 2,5 километрдагы Олы Чакмак авылы тирәләре, җәелеп аккан Ык елгасының сул ягы комлыкларында... Кара

Нефте дә булыр Мөслимнең!



син аны! Сигез метр тирәнлеккә кадәр алтынның чыгышы 2 дән алып 7 грамм/тонна микъдарга чаклы тәшкил итә. Бу исә алтынның "бишеге" саналган Хакасия, Африкадагы Зимбабве һәм Боливиядәге чыганаклардан да куәтлерәк дигән сүз.

Ышаныргамы, ышанмаскамы?! Шикләндерә дә, гаҗәпләндерә дә, җәмәгать! Журналистлар киләсен белгәч, "Маяк" күмәк хуҗалыгы рәисе Радик әфәнде Гыймаев махсус иләкләр ясатып куйган икән. Район хакимияте башлыгының беренче урынбасары Мизхәт әфәнде Нәбиев белән икәүләп, безне җилтерәтеп, теге Олы Чакмакны урап агучы Ык ярына алып төшеп киттеләр. Илиләр дә илиләр комны.

- Нәрсәдер бар да кебек, - ди хуҗалык рәисе.

- Валлаһи, ялтырый бу, - дип раслый аның сүзләрен хакимият башлыгы урынбасары. - Килегез әле, кил, сез дә карагыз!

- Бардыр инде, юдырмыйча, махсус эшкәртмичә, аны кайдан беләсен?

- Ну, миңа өстәмә мәшәкать арта болай булгач - җыен әтрәк-әләм җыелачак инде, - дип үзенең борчылуын да яшермәде хуҗалык җитәкчесе.

Менә сиңа Магадан! Уйлансаң, исең китәрлек! Моңа кадәр Мөслим туфрагы республикабызны гәрәбәдәй бодае белән генә куандыра иде. Малайлар су коенып чыккач мәтәл-чүкән атынып, кояшта кызынып яткан комлыкларда алтын бөртекләре тәгәрәп ятсын әле!

- Бу эшне бүгеннән үк туктатабыз, Мөслим җирендә ком бетмәгән, - ди Мизхәт әфәнде, Ык ярындагы казылган комлыкларга ишарәләп.

Башта ук уйлаган идек аны. Яр буйлары күп урыннан экскаватор белән казылган. Юлларга асфальт җәю өчен комны шуннан ташыйлар икән. Болай булгач, Мөслимнең юлларына да алтын түшәлгән икән ич. Зимбабве, Боливияләрнең үзләрендә дә мондый хәл юктыр, мөгаен?!

Кызыл кырачлы таулар дигәннәре - Ыкның уң як яры, Иске Вәрәш авылы таулары икән. Биредәге утырмаларда файдалы катламның калынлыгы 0,5 тән 3 метрга чаклы. Алтын микъдары 0,8 - 1,2 грамм/тонна тәшкил итә. Бик тә гаҗәп: геологлар теле белән әйтсәк, мондагы элювиаль-делювиаль утырмалардан алынган анализ микъдары 0,1 миллиграммга чаклы алтын пластинасы чыгуын күрсәтте. Ә менә атом-адсорбция анализы 1,2-1,6 грамм/тонна алтын микъдары булуын раслады. Зимбабвеларың бер якта торсын!..

Иске Вәрәш, Вәрәшбаш таулары Урал таулары инде ул. Әлегә биредә таш чыгаралар, известь тарттыралар. Карьерда куәтле известь тегермәне эшләп тора. Бу кыйммәтле ашламаны Мөслим, Актаныш, Минзәлә районнары хуҗалыклары бик теләп файдаланалар. Сыйфаты югары известьның. Ә катламнарның бер өлеше алтынга төренгән... Менә сиңа кызыл кырачлы таулар! Бар икән байлык Мөслим туфрагында, тик аны файдалана белергә генә кирәк.

Хәер, базар шартлары барысына да өйрәтә. Кайчандыр "Татнефть" бораулап киткән җирләрдә берничә скважина сураеп кала. Сарман, Минзәлә районнарында ду китереп "кара алтын" табалар. Сары, ак алтыннары булган Мөслим туфрагында карасы гына бардыр, шәт!? Район хакимияте, аның башлыгы Рөстәм әфәнде бу форсатны һич тә кулдан ычкындырырга теләми. "Азнакайнефть" идарәсендә эшләүче югары квалификацияле бер белгечне үзләренә чакырып кайтаралар. Ул - Рәйхан Шәйхетдинов. Бергәләп киңәш-табыш итәләр. Президентыбызның кәсәбәчелекне үстерү турындагы Указына туры китереп, "Мәлләнефть" (Мәллә елгасыннан алып куелган) кече нефть компаниясен оештырып җибәрәләр. Әлбәттә инде, аның генераль директоры итеп энергияле яшь белгеч Рәйхан әфәнде билгеләнә. Скважиналарның икесе шунда ук эшкә җигелә. Чыгарылган җир мае, үткәргеч торбалар сузылмау сәбәпле, әлегә "Татнефть" хуҗалыгына автотранспорт белән ташыла. Кыска вакыт эчендә 2090 тонна нефть озатылган. Җирле компания тагын 4 скважинаны сафка бастырырга җыена. Хәмердән түгел, нефтьтән керә район бюджетына акча. Без моны алга карап эшли белүнең якты бер үрнәге дияр идек.

Бәлки, сорау туар: "Татнефть" ул скважиналарны ник калдырып китте икән соң? Хикмәт тә шунда шул. Мөслим җирендә без күнеккән гадәттәге ятмалар юк. Девон нефте атып тормый. Кыскасы, девон-карбон катламнары арасындагы нефтьне алырга кирәк - бик авыр процесс. Шуңа күрә дә аны файдаланмаганнар. Базар шартларында авырлыклардан өркеп яшәп буламы соң?! Мәлләлеләр 1560 метр тирәнлектәге җир маен өскә күтәрү әмәлен тапканнар. Акча кирәк, акча! Горбачев әйтмешли: "Процесс пошел!"

Икмәге дә, алтыны да, нефте дә булыр Мөслимнең. Иншалла! Эшләр шуңа таба бара.

Солтан ИСХАКОВ фотолары.

Иске Вәрәш, Вәрәшбаш таулары Урал таулары инде ул...





Бүген республикабызда гына түгел, Россия һәм аннан читтәге өлкәләрдә дә "Стройпласт" заводы җитештергән продукцияне - пластик ишек-тәрәзәләрне яратып, үз итеп өлгерделәр. Зәвык белән эшләнгән, җылы һәм тавыш үткәрми торган тәрәзәләр бүген күпчелек йортларга куелган. Әлеге заводның генераль директоры Фәнүс әфәнде ШӘКУРОВ белән бүгенге әңгәмәбез предприятие турында гына түгел, бәлки тормыш-көнкүреш турында да.

БЕР ГОРУРЛЫК ХИСЕ... юк ул бездә

- Фәнүс әфәнде, сүзне бүгенге тормыштан башлыйк әле. Сез аны ничегрәк бәяләр идегез?

- Бүгенге тормышны бер генә дә анлап була торган түгел. Югыйсә, яшебез дә кечкенә түгел, нинди генә чорларны кичермәдек, ләкин бүгенгесе янәшәсендә алары түзәрлек булган. Мактаулы "могучая держава" дигәннәрен дә шушы хәлгә китереп җиткергәч... Йөрәк әрни...

Без - бүген хезмәт хакын үз вакытында бирүче бик сирәк предприятиеләрнең берседер. Кешегә эшләгән өчен түләү бүген гадәттән тыш вакыйга санала. Безнең завод эшчеләре хезмәт хакын чагыштырмача аз алмый кебек, ләкин шуңа карамастан, мин безнекеләр дә иркен тормыш белән яшиләр дип әйтмәс идем.

Ә эшсез халык, пенсионерлар бүген ничек яшиләр икән? Никадәр яшь гаилә әбисе-бабасы пенсиясенә өметләнеп яшәргә мәҗбүр. Русча бик әйбәт яңгырый ул: "Обидно за нашу державу!" Эшчене генә түгел, житәкчене дә тезләндерде бу тормыш... Күңел биреп эшләргә мөмкинлек юк. Көн туу белән көтелмәгән проблемалар чыга, шуларны чишә-чишә көн үтә.

Хәтерлисездер, мәктәптә укыганда В. Маяковскийның бер шигырен ничек илһамланып укый идек, ә?! Бүген мин дә, башкалар да "Мин - Россия гражданины!" дип горурлана алмыйбыз. Горурланып йөрергә "хут" калмады безнең. Илең белән горурлана алмагач, милли горурлыгың булмый. Безгә бүген мескен итеп карыйлар. Күп илләр "Россиягә ничек ярдәм итәргә", дип лаф ора. Хәтта безнең предприятиеләргә килгән чит ил кешеләре карашында да һәрдаим тоям мин ул кызгану хисен...

Иртәгә ни булыр дип фараз кылырга да мөмкин түгел. Хәтта бүгенге көннең нәрсә белән бетәчәге дә билгесез. Иртәгәсе көнгә нидер планлаштыру да нигезсез, чөнки телевизорга дип җыйган бүгенге акчаң иртәгә урындык сатып алырга да житмәве бик ихтимал!

- Сезгә эшегез буенча чит илләрдә еш булырга туры киләдер. Алай да кайсы ил күңелегездә аеруча соклану хисе уятты? Шул чакларда безнең илдә туганыгызга үкенгән вакытларыгыз булмыйммы?

- Чит илләрдә эш белән бер-ике көн генә булырга туры килә. Минемчә, Европа илләренең барысында да кешегә яхшы яшәү өчен бөтен уңайлыклар да тудырылган. Үрнәк алырлык итеп эшлиләр, яшиләр, халык шат-көләч.

Немецлар яшәгән ике ил - Австрия һәм Германия турында аерып әйтергә телә идем. Австрия немецлары милләт ягыннан үзләрен Германия немецлары белән бутаганны да, чагыштырганны да яратмыйлар. "Бутамагыз, без башка немецлар!" - диләр. Илләре, милли үзенчәлекләре белән горурлану бик көчле аларда! Әйе, бу ике илне чагыштырырга бөтенләй мөмкин түгел. Хәтта тормыш дәрәҗәсе югары саналган ике ил арасында гына да тәртипләр үзенчәлекле. Бай, житеш, чиста, цивилизациясе югары Австриягә тагын нинди ил җитә икән!? Хәтта әлеге ике ил белән Чехословакияне, Венгрияне дә чагыштырырга мөмкин түгел. Капиталистик лагерь белән элекке социалистик лагерь арасындагы аерма җир белән күк арасы. Ә безгә әлегә Чехословакиягә житәргә дә хәйран ерак. Мәдәнилек ягыннан да, житештерү, тормыш дәрәҗәсе, чисталык, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре, әхлак ягыннан да...

Хәтерлим әле: мин бәләкәй чакта безнең авылда унмаган, булдыксыз кешене "төрек" дип мыскыллыйлар иде. Миңа төрекләр иле Төркиядә булырга туры килде. Безгә ул төрекләргә җитәргә әле?! Төркия - Европа түгел, ләкин без дә түгел инде!..

- Сез беренче күргә тормышта нииндидер сискәну, шок кичергән кешене хәтерләттегез. Чәчләрегезнең иртә көмешләнүенең дә сәбәбе бардыр...

- Чәчләр иртә агару нәсел үзенчәлеге ул безнең. Мин белгәндә бабайның да чәче ак иде, этинеке дә иртә агарды...

- "Нишләргә?" дип аптырауга калган вакытларыгыз буламы?

- Башны учка кыскан чаклар еш була. Соңгы вакытта "тере акча" дигән термин кулланышка керде бит. Менә шул тынгылыкны бетерә. Халыкка хезмәт хакы түләү дә берни түгел, ә менә чималны Германиядән кайтартканлыктан түләү өчен тере акча таба алмый интегергә туры килә. Безнең продукциянең күп өлеше торак фондына, салымга, башка түләүләргә китә. Сатуга аз өлеше кала. Бүгенге көндә, бәяләр 4-5 тапкыр күтәрелгән мәлдә, без тәрәзәләргә бәяне бер тиен дә күтәрмәдек. Әлегә әчке резервларны эшкә җигәбез. Курс болай торса, без дә киләчәктә бәяне күтәрергә мәҗбүр булачакбыз. Башка илнекеләр белән чагыштырганда, безнең бәя ике тапкырга очсызрак. Сыйфаты да югары. Югыйсә Мәскәүдә узган "Торак-98" халыкара күргәзмәдә дипломант исемен безгә бирмәсләр иде. Безнең казаныш бу! Чит илләрдән һәм Россиядән барлыгы 200 дән артык предприятие катнашкан күргәзмәдә "Стройпласт" беренчеләр исемлегенә эләкте, кубок, диплом белән бүләкләнде. Тыйнаклык сакларга яратсам да, мактанырга урын бар безнең. 1998 елда чыккан "XX век. Элита - бизнес. Золотая книга российского предпринимательства" дигән китапта безнең республикадан алты предприятиегә урын бирелгән, алар арасында "Стройпласт" та бар.

Мин дә күргәзмәнең алтын медале белән бүләкләндем. Мәрхүм этием чирәм җир күтәрүчеләрнең алгы сафында иде. 1956 елда ул да Мәскәүдә узган күргәзмәдән бронза медаль белән кайткан иде. Исән булса, "Без сине дә уздырдык, эти", дип мактанып алырга булыр иде. Кызганыч, күрә алмады.

- Сез, җитәкчеләр - дәүләт кешеләре. Ә менә сирәк кенә булса да эшкә барасы килмәгән чак буламы җитәкче кешенең?

- Әгәр авыру гына аяк чалмаса, эшкә бармый калган көнне хәтерләмим. Җитәкче көнен генә түгел, төнен дә эше белән яши. Иртәниртүк чыгып китәм, кичке 9-10 да гына кайтып керәм, бала-чаганы җүнләп күргән дә юк. Тәүлегенә 15 сәгать эшлисең, чөнки, әйткәнемчә, проблемалары баштан ашкан. Гаҗәп түгел, "мә" дип килми халык, "бир" дип килә. Аңа арзан да булсын, әйбәт тә булсын.

- Киеренке хезмәт көненнән соң Сезгә дә азрак "йомшап алу" гаеп саналмыйдыр...

- Җай туры килсә, дуслар белән җыелышып мунча керергә, дөнья хәлләрен, мәзәкләр сөйләшеп, бильярд уйнарга яратам. Минем хобби - бильярд. Кайвакыт табигать кочагына элдерәбез, шашлык кыздырабыз.

- Президентның якташы булу Сезгә карьера ясауда ярдәм иткәндер, бәлки?..

- Юктыр. Актанышлылар тырыш, эшчән халык, диләр. Әгәр биографиям белән танышсагыз, минем прорабтан башлап җитәкчелектә баскыч арты баскыч үсүемне күрерсез. Арттан этеп торучы да, алдан тартып баручы да булмады. Тормышта нигәдер ирешкәнмен икән, ул бары тырышлыгым нәтиҗәсе.

- Җитәкчеләрнең чын дусларына караганда, кирәк өчен дус булып йөрүчеләре күбрәк. Сез кешеләр арасындагы икейөзлелеккә яки ихласлык кебек сыйфатларга игътибар итәсезме?

- Кешенең тормышта чын дуслары күп булмый. Бер була ул, йә ике. Танышлар, әшнәләр күп. Мин белмәгән, аралашмаган җитәкчеләр юктыр республикада. Күп еллар җитәкчелектә эшләргә туры килгәч, хезмәт буенча таныш-белешләр күп җыелгандыр. Әлбәттә, кирәк өчен дус булып йөргәннәр дә бихисап. Төрлесе бар. Ни өчен аралашканнары сизелә инде: кирәк өченме, әллә кызыксыныпмы...

Бүгенге тормыш күп кешене сындырды, кемнедер урыныннан алып атты. Ә минем, тфү-тфү, эшем яхшы бара икән, аңа көнләшүчеләр дә аз түгел. Иртәгә бер-бер хәл булса, шул "дуслар"ның исәнләшмичә, бәрелеп узып китүләре дә бик ихтимал. Бу дөньяда беренигә гаҗәпләнәсе юк.

- Сезне бик матур җырлый, хәтта халык артистлары исемен йөртүчеләргә дә Сездәгедәй моң җитенкерәми, диләр. Мәҗлеснең җаны, матурлыгы ул Фәнүс, диде миңа бер уртак танышыбыз...

- Китегез әле, шулай ук диләрме, кем әйтә аны!

Җырлаганчы биеп йөрдем әле мин. 7 класста укыганда ук үземне укыткан укытучылар белән сәхнәдә бии идем. Аннан соң кинәт кенә үсеп киттем дә, бу кадәр озын буй белән сәхнәдә биергә кыенсына башлагач, җитәр, дидем. Институтта укыганда бал биюе мәктәбенә, Төзүчеләр мәдәнияте сараена балет түгәрәгенә дә йөрдем. Сәнгатькә мәхәббәт балачактан күңелемә сеңеп калды. Институтта укыганда, мине ел да отряд командиры итеп сайлыйлар иде. Җыелышып җырлаган чаклар да булгандыр. Үзешчән сәнгать көчле иде ул вакытта. Татар авылларында концерт куйганда үзем теләп түгел, көчләп диярлек берничә тапкыр сәхнәгә җырларга чыгардылар. Зал гөрләтеп кул чапты. Шуннан соң җырлаштыра башладым. Мәҗлесләрдә дуслар тамада итәләр.

Әти гармунда уйнап җырлый иде. Әни 73 яшьтә булуына карамастан, җырлый да, биеп тә җибәрә. Сөбханалла!

- Минемчә, Ходай Тәгалә һәрнәрсәне сөеп, өеп биргән кебек Сезгә - эшчән, мәзәкчән, җырчы, биюче, шуның өстенә буйсын, хәтта матурлыкны да... Янәшәгездәге хатын-кызлар Сезнең йөрәкне яулап алу өчен ятьмәләр корып интектереп бетермиләрме?

- (Көлә!) 47 яшь ич инде миңа.

- Ир-ат өчен менә дигән яшь ул!

- Шулай дисезме... Мин алай күзгә бәрелеп торырга, игътибар үзегездә булырга бик омтылмыйм. Алай тыйнаксыз түгелмен. Авыл баласы бит. Күзгә ташланып торырлык ачык төсләргә киемнәрне дә киярго тырышмыйм. Болай да буй озын, чәч ап-ак, әллә кайдан күренеп торам. Алай бәйләнеп, шылтыратып интектереп бетерәләр димәс идем.

Беренчедән, эшкә килү белән: өйләнгәнмен, өч балам бар, дип таныштырдым үземне. Гаилә тормышыннан канәгатьмен. Ир-ат өчен гаиләсендә анлашу, хөрмәт, бер-береңә тартылу бар икән, минемчә, ул чит-ят белән мавыгырга ашкынып тормый.

Хәтерлим: армиядән кайткач, мәктәптә укытырга туры килде миңа! Менә кайчан бәйләнеп карадылар да инде миңа кызлар! Бүген искә төшерәм дә...

- Хатын-кыз мәсьәләсендә дә анлаштык шикелле. Шуны да беләсе килә: җитәкче кеше өчен кием мөһим нәрсәме?

- Мин гомер-гомергә киемне үзем-үзем алам. 5 нче класстан әни янынннан чыгып китеп, үз көнемне үзем күрергә туры килгәч, әйберне саклап кына, юып, үтүкләп кию кагыйдә иде. Еллар үткәч укытучыларым: "Бикбау мәктәбе егетләрен чалбарны үтүкләп киярго син өйрәттен", - диделәр. Киемсалым мәсьәләсендә пөхтәлекне яратам. Өстәлдә дә тәртипсезлекне өнәмим. Җитәкчеләр янында булганда, башта аларның өсләренә игътибар итәм.

- Фәнүс әфәнде! Сез тормышта үз урыныгызны тапкансыз. Яраткан эшегез, чибәр хатыныгыз, өч балагыз бар. Тулы бәхет өчен тагын нәрсә җитми Сезгә?

- Тирә-юньдә хәер эстәп, ярым фәкыйрь хәлендә яшәүчеләр күп булгач, үзенне "мин бәхетле" дип хис итеп булмыйдыр ул! Мин "крутой" эшкуар түгел, дәүләт кешесе, предприятие җитәкчесе - күпчелекнең, халыкның ничек яшәгәнен күрәм ич! Утрауда яшәмим! Дуслар, күршеләр, танышлар житеш яшәп, йөзләрендә яшәү нуры балкыса, муллыкта йөзсә, мин дә үземне алар янәшәсендә бәхетле сизәр идем.

- Байлыкка мөнәсәбәтегез нинди соң?

- Яшермим, икейөзләнмим, байлык дип һушым китми. Дөрес, мохтаҗлык кичерми, житеш яшәү кирәк адәм баласына...

Минем акчасыз кесә белән йөргәнем юк анысы. Гел машинада ич, ГАИга штраф түләү өчен генә булса да кесәдә акча йөртергә кирәк инде ул. Хатыннан да тиенләп сораганым юк.

Житеш яшәү - оекка акча җыйнау түгел ул, тормыш өчен кирәкле һәрнәрсә дә кул астында булу.

Икенче байлык - күңел байлыгы, җан юмартлыгы да кирәк кешегә! Анысы мөһимрәк...

Әңгәмәдәш - Резидә НИЗАМИЕВА.

Солтан ИСХАКОВ фотосы.

Ханның колак төбендә ханбикә пышылдавы, дигән борынгылар. Хәер, бу әйтем һәр заман өчен дә көнүзәк. Бүген, мәсәлән, хан сүзен җитәкче дип кенә алыштырасыдыр. Чөнки хатын-кыз иренең карьерасы, казанышлары өчен һәрвакыт җаваплы.

Һәм ул аңа җылы сүзе, зирәк киңәше белән булышып килә. Ләкин, гадәттә, хатын-кыз югары посттагы хәләл җефетенең күләгәсендә күмелеп кала. Күпләр, ни сәбәпледер, җәмәгатьләрен халыкка күрсәтергә атлыгып тормыйлар.

Табигате әле ахыргача ачылып җитмәгән әлеге хәлне типик күренеш дип уйламыйк. Үз сүзен өздереп әйтә белгән, тәвәккәл җитәкчеләребезнең тормыш юлдашлары да, күбесенчә, каләм ияләре белән ачыктан-ачык сөйләшүдән курыкмыйлар.

Шундый ханымнардан бүгенге әңгәмәдәшебез — Фәния Хәсән кызы ИСХАКОВА.

Фәния Исхакова: “Мин кияүгә шәһәр башлыгына чыкмадым”

Фәния ханым - Казан шәһәре башлыгы Камил Исхаковның хатыны. Кызлары Тереза һәм Альбинага - әни, оныгы Каринага - дәү әни. Ул журналистлар белән аралашмый диярлек. Чөнки мэр хатыны булу ул беркадәр өстәмә мәҗбүрият тә йөкли. Ә үтә кызыксынучылар белән дөнья тулы. Шулай да Фәния ханым “Татарстан” журналына эксклюзив интервью бирергә риза булды.

- Югары урыннар биләгән җитәкчеләрнең хатыннарына, гадәттә, көнләшеп карыйлар. Имеш, балда-майда йөзәләр... Фәния ханым, Сезнең моңа мөнәсәбәтегез ничек?

- Бу - көнче кешеләрнең үз проблемасы. Андый сүзләргә әллә ни игътибар итмим. Мин кияүгә шәһәр башлыгына чыгам дип чыкмадым ич. Без өйләнешкәндә Камил студент иде. Аның киләчәктә кем буласын каян белим? Тормышта кыенлыклар күп очрады. Язмышыбызга язылганнарны бергә кичердек.

- Ялгышмасам, Сез бит Казанда туып-үскәнсез?

- Әйе. Мин гап-гади эшчеләр гаиләсендә туып-үскән кыз. Әнием 15 яшендә Саба районыннан килеп мех берләшмәсенә эшкә кергән. Гомер буе шунда эшләп, пенсиягә чыкты. Әтием Лаеш районыннан, 9 айлык чакта әнисез, 11 яшьтә этисез калып, Казанда балалар йортында үскән. Шуннан сугышка киткән, разведчик булып Берлинга кадәр җиткән, Ерак Көнчыгыштагы сугышны тәмамлап Казанга кайткан. Шул ук мех берләшмәсендә эшли башлаган. Әнием белән дә шунда танышкан, бер ай эчендә өйләнешеп тә куйганнар. Бер-берсен аз белсәләр дә, озын гомерле, нык гаилә корганнар. 4 кыз бала үстерделәр. Минем апам һәм ике сеңелем бар.

- Әти-әниегез исәннәрме?

- Әтием 1981 елда, 60 яшендә вафат булды. Сугышны башыннан алып азагына кадәр кичкән кешенең сәламәтлеген үзегез чамалыйсыздыр. Ул гел авырый иде, әнигә бик кыенга туры килде. Әтинең 60 яшькә җитә алуы аның тырышлыгы һәм, әлбәттә, үзенең көчле ихтыяры, күтәренке рухлы, көләргә-шаярырга яратуы аркасында гына булгандыр, мөгаен. 1981 елда алар икәүләп, үз гомерләрендә беренче тапкыр “Васильево” санаториена ял итәргә барганнар иде, эти шунда кинәт, йөрәк өянәгеннән үлеп китте. Әниебез исән, аның да йөрәге авырта, аны һич тә берүзен калдырмыйбыз, кайгыртып торабыз. Хәзер минә балалары да, оныклары да үсеп җитте. Яшәргә дә яшәргә бит югыйсә. Әмма әнә шул ачлык чорлары, сугыш вакытлары, авыр тормыш һаман үзләрен сиздереп тора.

- Үзегезнең тормыш юлыгыз турында да сөйләсәгез иде.

- Мәктәпне тәмамлагач, Казан элемтә техникумына, радиотелевидение бүлегенә укырга кердем. Аннан соң институт тәмамладым. Сүз уңаеннан, элемтә техникумында үз вакытында Камил дә укыган булып чыкты. Гомумән, бер-беребезне белгәнче үк, без бер үк юллардан йөргәнбез икән. Әниемнең бертуганы - апам Савиново бистәсендә яши иде, балачагым шунда үтте дисәм дә ярый. Шул тирәдәге торф сазлыкларында уйнап йөргәннәр исемдә. Баксаң, Камил дә шунда үскән, шул җирләрдә уйнаган икән. Апам йорты алардан юл аркылы гына булган. Соңыннан, боларны ачыклагач, көлештек тә әле: Ходай безне гел очраштырырга тырышкан икән, дибез.

- Кая һәм кайчан танышырга насыйп иткән соң?

- Миңа 20 яшь иде. Ул вакытта без комсомол оештырган кичәләргә йөрергә ярата идек. Шундый кичәләрнең берсендә минем янда торган бер таныш егет белән исәнләште ул. Танышым: “Менә бу Камил Исхаков, университетның маягы, Ленин стипендиаты”, - дип әйтте. Мин Камилгә артык игътибар да бирмәдем шикелле. Башка кичәләрдә дә очраштыргалый башлады бу. Аннан соң комсомолда бергә эшләргә туры килде. Шушы егеткә кияүгә чыгармын дип башыма да китермәдем. Камил үзсүзле булып чыкты. Ул миңа гашыйк иде һәм үз дигәнендә нык торды. Мин аңа моның өчен хәзергәчә рәхмәтле. Мәхәббәт шулай башланып китте...

- Камил Шамилевич бик илтифатлы кавалер булгандыр ул...

- Әлбәттә. Чәчәкләр бүләк итә, киноларга йөртә... Әмма ул шул вакытта ук баштанаяк җәмәгать эшенә чумган иде. Иркенләп йөри идек дип әйтә алмыйм. Галиәсгар Камал театры без яшь чакта да популяр, аңа билет юнәтү авыр иде. Камил, студент чакта ук ТАССР халык депутаты буларак, билет алу җаен таба. Кичләрен соңга кадәр йөрмәдек, чөнки минем әтиәни ул яктан кырыс иде... Аннан инде өйләнештек тә.

- Гадәттә яшь гаиләләр күрә торган кыенлыклар сезгә кагылдымы соң?

- Башта әле минем әти-әниләрдә, әле аныкыларда тордык. Аннан комсомол гаиләсе дип, коммуналкада 9 метрлы бүлмә бирделәр, Журналистлар урамында. Кызыбыз Тереза беренче класска укырга кергәч, Космонавтлар урамында ике бүлмәле фатир бирделәр. Альбина шунда туды, Тереза мәктәпне тәмамлады. 15 ел гомер шунда узды. Тереза кияүгә чыкты, яшьләр ел ярым бездә тордылар. Әтиебез гел эштә булды. Комсомолдан соң, аны “Алгоритм” оешмасының директор урынбасары, аннан соң генераль директоры итеп куйдылар. Хәтерләсәгез, ул вакытта иң алдынгы техника - ЭВМнар “Алгоритм”да, чит ил белгечләре дә шунда укый иде. Камил тырыша-тырыша яна бина,

ашханә, кунакханә салдырды. Гел командировкада, министрлыгы Мәскәүдә иде. Ишектән кусалар, тәрәзәдән кереп диярлек, үз оешмасы өчен акча табып йөрде. "Министрлыкта мине күргәч, "тагы теге үзсүзле татар килгән", дип кача башлыйлар", - дип сөйли иде Камил үзе. Фатирга миңа караганда да мохтаҗ кешеләр бик күп дип, үзенә фатир да сорамады. Аннан соң Камилне шәһәр башкарма комитетына алдылар. Анда 2 ел эшләгәч кенә, 1991 елда, ниһаять, өч бүлмәле фатирга күчтек. Хәзер дә шунда яшибез. Тереза кечкенә чакта миңа "ашыгыч ярдәм" машинасында төннәрен эшләп йөрергә дә туры килде. Ул балалар бакчасына йөри башлагач, шунда эшкә кердем. Яшерен-батырын түгел, яшәргә акча җитми иде. Зур әйберләрне кредитка ала идек. Акча мәсьәләсе 40 яшьләрдән узгач кына, азмы-күпме җиңеләйде кебек. Гомумән, без бик бай яшәдек, дип әйтә алмыйм. Барысына да тырыш хезмәт белән ирешелде.

- Фәния Хәсәновна, Сез хәзер кайда эшлисез?

- Хәзер мин хуҗабикә. Күп еллар фәннитикшеренү институтында эшләдем. Альбина укырга кергәч, тулы булмаган эш атнасына күчтем. Әни дә авырый башлады. Үзгәрешләр башлангач, институтның да хәлләре мөшкелләнде. Шуннан Камил: "Әнисе, өйдә торсаң, үзенә дә, безгә дә әйбәтрәк булачак", - диде. Үзем дә шундый карарга килдем. Холкым буенча да шундый мин, күбрәк өйдә торырга, өйне ямьләргә яратам. Өйдә генә утырмыйм, әлбәттә. Хәзер, мәсәлән, инглиз телен өйрәнәм. Камал театрына, опера һәм балет театрына йөрим. Камилнең эше күп булганлыктан, күбрәк дуслар белән барабыз. "Мин - Исхаков хатыны", - дип, аерым ложаларда утырмыйм. Гап-гади тамашачы булып, тамашаны залдан карарга яратам. Оныгым Карина белән дә калам. Гомумән, һәрбер хатын-кыз өлешенә тия торган гаилә мәшәкатьләре минем өстә.

- Фәния ханым, зур кызыгыз Терезаның инде үз гаиләсе, биш яшьлек кызы бар. Ә кече кызыгыз Альбина әле мәктәп укучысы. Яшь аермалары зур диюем...

- Хатын-кыз ничек кенә план корса да, барысы да Ходай кулында. Тереза мәктәпкә кергәч үк, тагын бала табарга теләгән идем. Әмма бездән генә тормый шул. Сәламәтлек тә бераз какшап китте. Шуңа күрә Альбинаны 33 яшемдә таптым. Тик Ходай вакытын белеп биргән, дип уйлыйм, яхшыга гына булган.

- Ни өчен?

- Ике кызым да үсеп җитеп үз тормышлары белән яшәсә, мин оныклар карап утырып кына үземне әби дип хис итәр идем сыман. Хәзер исә, оныгым булса да, мин әле яшүсмер кызның әнисе бит, үземне яшьрәк хис итәм. Онык - ул кунак, килә дә китә. Ә Альбина һәрчак янымда, үзем белән. Камил бит иртән чыгып китә дә кич белән соң гына кайта. Ходай шушыларны да күздә тоткан, күрәсең.

- Баламның баласы балдан татлы, диләр. Карина да Сезнең өчен шулайдыр?

- Оныгымны мин бик яратам, ул миңа бик кадерле. Шул ук вакытта әле Альбинамның да биләүдә ятканы, ничек үскәне онытылмаган. Тереза да минем өчен һаман бала. Үз тормышы белән яшәсә дә, ул минем рухи ярдәмемә, киңәшләремә мохтаҗ. Мин аларның барысын да яратам. Бәлки, бераз өлкәнрәк яшькә җиткәч, мин ул гыйбарәнең асылын ныграк аңлармын.

- Шәһәр жирендә бала үстерүнеңборчу мәшәкатьләре шактый. Алар Сезгә дә кагылмый үтмәгәндер...

- Аллага шөкер, кызларыбыз безгә артык мәшәкать тудырмадылар. Хәзер дә шулай. Тереза мәктәптә яхшы укыды, музыка мәктәбен тәмамлады. Гел лидер ролендә, пионервожатый, комсорг булды. Ул авырса, бөтен класс өйгә, аның хәлен белергә җыела иде. Кызларым әтисенең исеме белән файдаланып, мактанып йөрмәделәр, аларга мөстәкыйльлек сыйфаты хас. Тереза университетка да үз көче, үз белеме белән керде. Кергәндә бер имтиханын өчкә биргәч, көндезге бүлеккә уза алмам дип, безгә әйтмичә генә эшкә урнашкан булып чыкты ул. Инде көндезге бүлеккә узуы билгеле булгач та, әтисенең үгетләвенә дә карамыйча, үз сүзен сүз итеп, бер ел читтән торып, эшләп укыды. Хәзер дә әтисеннән һичнинди ярдәм сорамыйча, "Бәла Карина" дигән балалар мода театры оештырды. Костюмнарны да үзләре тегәләр. Терезаның хыялы - балалар белән эшләү иде, инде хыялы тормышка ашып килә. Театр зур сәхнәләрдә уңышлы чыгышлар ясый.

Безне Ходай үзе очраштырды. 1973 ел.

- Альбинаның холкы бераз тынычрак, ахры.

- Әйе, ул тыйнак бала. Альбина бик мавыгып, гитарада уйнарга өйрәнә. Инглиз теле белән шөгыльләнә. Терезаның мода театрында чыгыш ясый. Һәрнәрсәгә үз карашы, үз зәвыгы бар. Гел бишкә генә укый. Бишлеләрне тырышып, үз хезмәте белән ала. Укытучылар аңардан бик канәгать. Минем беркайчан да мәктәпкә аңа бишле куегыз, дип барганым юк. Бу яктан берәү дә миңа бармак төртеп күрсәтә алмас. "Исхаков кызы булгач, бишле куялар инде", - дигәннәрен ишетеп, борчылып кайткан чаклары да булды. Кызларыбызның мөстәкыйльлеккә, үз көчләренә таянып яшәргә омтылуларына шундый сүзләр дә сәбәпчедер, бәлки. Үзебез дә аларны иркәләп үзындырмадык. Мин, мәсәлән, аларга карата гел таләпчән.

- Ә Камил Шамилевич?

- Ул йомшаграк. Ул балаларны көннәр буе күрми, сагына. Мин балалардан әзрәк зарлана башласам, "Син аларны аңларга тырыш", - дип мине үгетли башлый. Үзенә нидер ошамаса, беркайчан да кызларның үзләренә әйтми, миңа сөйләп бирү белән чикләнә.

- Әтиләренең һәрчак эш белән мәшгуль булуына кызлар үпкәләмиме соң?

- Юк, әлбәттә. Эше ничек кенә күп булмасын, ул бит безне онытмый. Көн буена берничә кат шылтырата. Без аның эштән кайтуын көтеп торабыз. Безнең гаилә киче соң башлана, әтисе кайтып, бергәләп сөйләшмичә-серләшмичә йокларга ятмыйбыз. Иртәрәк кайтуын сорап шылтыратсак, ул: "Матурым, ярты сәгатьтән кайтырга чыгам, тырышам", - ди. Карыйсың - ике сәгатьтән кайтып та җитә. Ул бит моны махсус эшләми, эше шундый.

- Ә Сез үзегез беркайчан да үпкәләмисезме?

- Яшьрәк чакта булгалый иде. Ләкин аның холкы шундый: эшли икән - эшкә чума. Монда инде үпкәләсәң дә, еласаң да, үзгәртә алмыйсың. Камилдә җаваплылык хисе көчле. "Мин дә тотынмасам, кем генә эшләр соң?" - ди ул. Мәсәлән, ул - төп казанлы, туып-үскән, газиз шәһәрен матурлыйсы, төзекләндерәсе килә аның. Шуңа күрә тырыша да, эше дә күренә. Казанны хәзер кунакларга күрсәтергә дә оят түгел, чистарды, бизәлде. Мин боларны иремне мактар өчен әйтмим. Ул чынлап та намуслы, хезмәт сөючән, принципиаль. Әлбәттә, шәһәр башлыгы бар кешегә дә ярый алмый, кемнәргәдер ошамыйдыр да. Чөнки ул үзе дә начар гамәлләр кылмый, башкаларга да моңа ирек бирми. Һәм тагын бер яхшы сыйфаты: эштәге күңелсезлекләрне өйгә ташымый, өйдә ул чын-чынлап ял итә.

Камил Исхаковның гаилә хакимияте: (сулдан уңга) Тереза, Фәния ханым, Альбина, Карина. 1998 ел.

- Эш мәсьәләләре буенча Сезнең белән киңәшәме соң?

- Кайвакыт сөйли, киңәшә. Мин үз фикеремне әйтәм. Киңәшләремә колак саламы, юкмы - бусын үзе хәл итә.

- Ул Сезгә киенү-бизәнү турында киңәшләр бирәме?

- Юк. Аның үз зәвыгы бар. Һәм минем киемнәрем аның зәвыгына, гадәттә, туры килә. Киемем, кыяфәтем турында мактау сүзләре генә ишетәм.

- Сез бер-берегезгә ничек дәшәсез?

- Камил миңа "матурым", "әнисе" дип дәшә. Яшьрәк чакта мин дә аңа "матурым" дия идем. Хәзер, балаларга ияреп, күбрәк "әтисе" дим.

- Фәния ханым, Камил Шамилевич - сөйкемле ир-ат, Сез дә күз төшәрлек гүзәл ханым. Бер-берегезне көнләү хисе туганы юкмы?

- Яшьрәк чакта булгандыр андый мизгелләр. Ләкин без көнләшү дигән авыруга бирешмәдек. Чөнки бер-беребезне бик яхшы беләбез. Бер-береңне аңлауга, үзара ышанычка нигезләнмәсәк, мондый гаилә кора алмас идек, дип уйлыйм.

- Еллар узган саен гаиләдә мәхәббәт хисе сүнә бара, диләр. Сез ничек уйлыйсыз?

- Мәхәббәтнең бергә яшәгән һәр чор өчен үзенә күрә бер мәгънәсе бар. Яңа кавышкан елларда ул - хиссиятле, кайнар мәхәббәт. Балалар тугач, мәхәббәтнең башка ягы ачыла, иреңне балаларыңның атасы буларак та, димәк, тагын да ныграк ярата башлыйсың. Ул да сине балаларның әнисе итеп күреп, яңадан гашыйк була. Еллар узган саен, бер-береңне кайгыртып, аңлап яши торгач, мәхәббәткә яңа төсмерләр өстәлә, аның кадерен беләсең, димәк, һаман яратасың. Минемчә, мәхәббәт - ул рухи бергәлек.

- Фәния Хәсәновна, сезнең гаиләдә үзенчәлекле бәйрәмнәр бармы?

- Бергә җыела алсак, һәрвакыт бәйрәм безнең өчен. Моннан ике ел элек, гомердә беренче тапкыр барыбыз да бергә ял итәргә барган идек, шуны хәзергәчә сагынып сөйлибез. Быел миңа Камилнең ялы бөтенләй булмас та шикелле. Иң күңелле бәйрәмнәр - туган көннәр, әлбәттә. Минем туган көндә, Камил иртән-иртүк тора да, шыпырт кына чыгып, чәчәк алып кайта. Кәгазьләр кыштырдатып йөрүен сизсәм дә, күзләремне ачмыйм. Югыйсә кызыгы бетә. Балаларны уятып, чәчәкләрен, бүләген күтәреп килә дә, әкрен генә миңе уята, бергә котлыйлар. Алдан алып куйса да, бүләген беркайчан да вакыты җитмичә күрсәтми, әллә кайларга яшереп куя. Ә мин үзем аңа бүләгемне алу белән бүләк итәм, түзеп тора алмыйм. Кызларны да шулай иртүк, икәүләп котлыйбыз. Камил котлау сүзләре әйтә дә, "Кызым, йокла, йокла әле", - дип әкрен генә эшкә чыгып китә. Бәйрәм үзе кич белән була.

- "Хатын-кыз бәхете" дигән фәлсәфи төшенчәне Сез ничек аңлыйсыз?

- Минем бәхетем - ул минем гаиләм. Яраткан иремнең, балаларымның янымда булуы. Ирем белән өч дистә елга якын яшибез икән һәм ул миңа һаман "матурым" дип дәшә икән, димәк, мин - иң бәхетле хатын-кыз.

- Фәния ханым, минем уңайлы һәм уңайсыз сорауларыма җавап биргәнегез өчен зур рәхмәт. Гаилә тормышыгызда уңышлар теләп калабыз.

P.S. Шәһәр башлыгы гына түгел, гаилә башлыгы да булган Камил Шамилевич Исхаковның үзенә дә сорау бирмичә булдыра алмадым:

- Әйтегез әле, Сез бәхетле гаилә коруның берәр серен беләсезме әллә?

- Беләм. Сере бик гади аның. Көн саен, эштән кайтып ишекне ачуга, Фәниянең күзләренә карыйм. Әгәр дә анда бераз тынычсызлану тойсам, шунда ук: "Әйтмә син авыр сүз, әйтмә син", - дип җыр башлыйм. Мин җырлап бетергәнче, Фәниям кояш кебек елмайган була. Бу ысул әлегәчә нәтиҗәле. Инде тәэсир итми башласа, башкасын уйлап табарга туры килер... - диде ул.

Әңгәмәдәш - Нурсөя ШӘЙДУЛЛИНА.

Рамил ГАЛИЕВ һәм гаилә архивы фотолары .

Көз - алтын бизгәге...

Шулай ул
кешене ел саен искәртә:
“Үтелгән вакытның кыйммәтен
алтынга күчереп исәплә!..”

Көз - алтын сарае...

Бар анда
хикмәт тә,
акыл да,
исәп тә...
“Син кылган эшеңнең зурлыгын
алтынга күчереп исәплә!..” -

Көз безне ел да бер искәртә...

Зиннур МАНСУРОВ.

Солтан ИСХАКОВ һәм
Василий МАРТИНКОВ фотолары.

И туган тел, и матур тел, әткәм-әнкәмнең теле!

ХИССИЯТЕ МИЛЛИЯ

(Махсус кушымта)



Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы "ТР халыклары телләре турындагы" Законны гамәлгә кертү комитеты ярдәме белән әзерләнде.

ТЕЛЛӘР САГЫНДА - ДӘҮЛӘТ

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Телләр комитеты соңгы елларда татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә куюда күзгә күренерлек эшләр башкарды. Комитетның эш юнәлешләре, бүгенге проблемалары белән якыннанрак танышу өчен без аның сәркатибе, Министрлар Кабинеты аппаратының баш референты Ким Мөгаллим улы МИҢНУЛЛИН белән әңгәмә кордык.

- Ким Мөгаллимович, Телләр комитетының оешу тарихына тукталып китик әле.

- Безнең комитет, тулы исеме белән әйтсәк, болай атала - Татарстан Республикасы халыклары телләре турында Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы комитет. Атап үтелгән закон, мәгълүм булганча, 1992 елда кабул ителгән иде. Ике елдан соң аны тормышка ашыруга юнәлдерелгән дәүләт программасы расланды. Нәкъ менә шушы программада законны тормышка ашыру өчен Министрлар Кабинеты каршында махсус комитет оештыру каралган иде. Җәмәгать тәртибендәге бу структура әнә шулай барлыкка килде.

Комитет составына күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, халык депутатлары, галимнәр - барлыгы 30 га якын кеше керә.

Комитетның рәисе - республика Премьер-министры. Аның ике урынбасары бар: Премьер-министр урынбасары И.К.Хәйруллин һәм академик М.З.Зәкиев.

Күргәнегезчә, комитет җитәкчелегендә сүзләре теләсә кайсы дәрәҗәдә үтәрдәй олы җитәкчеләр дә (урыннарда законның үтәлешен тәэмин итәр өчен монысы аеруча мөһим), катлаулы тел процессларына фәнни бәя бирә алырдай абруйлы галимнәр дә бар. Мин исә комитетның агымдагы эшләрен һәм, гомумән, хөкүмәттә бу законга караган мәсьәләләрне алып барам.

Комитетта өч төп комиссия эшли: терминология, топонимия һәм тел хезмәте күрсәтү комиссияләре.

- Татар телен тулы канлы дәүләт теле итү турында сүз барганда, бөтен җәмгыятьне шушы максатка туплау бурычы торганда, Телләр комитетының җәмәгать тәртибендәге бер структура гына булып калуы аңлашылмый...

- Телләрнең яшәеше белән бәйле мәсьәләләрне җәмәгать тәртибендәге комитет җилкәсенә генә дә, Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтына гына да йөкләп бетереп булмый. Бездә еш кына тел мәсьәләсенә караган һәрнәрсәне телче галимнәр карамагына тапшырырга була, дигән шактый хаталы фикер алга сөрелә.

Тел - сәясәт тә бит ул. Шуңа күрә аның үсеш перспективалары белән тел белгечләре генә түгел, сәясәтчеләр, юристлар, икътисадчылар, социологлар һәм башка бик күп төрле һөнәр ияләре дә шөгыльләнергә тиеш. Телләр үсешенең стратегиясен эшләү өчен берәр махсус үзәк булдыру зарур.

Телнең яшәешенә контрольлек итүче дәүләти структуралар күп илләрдә уңышлы эшләп килә. Кытайда шундый махсус министрлык бар икәнлеген беләм. Илнең аерым субъектларында, мәсәлән, Синьцзян-Уйгур автономияле районында телләр үсешен тәэмин итүче, аларны куллануны җайга салучы дәүләт комитеты эшли. Комитетның контроль ясау вазыйфасы көчле, административ җаваплылыкка тарту хокукы бар. Шуңа күрә финанс ягыннан үз-үзләрен тәэмин итеп тә тора алалар.

Тиешле норматив-хокукый документлар кабул иткәндә мондый оешмаларны инде бүгеннән республикабыз шәһәрләрендә төзергә мөмкин булыр иде. Шәһәр тормышының бөтен өлкәләрендә телне куллануга күзәтчелек итүче, ярдәм күрсәтүче ул структура хуҗалык исәбенә дә яши алачак. Киләчәктә Татарстан кебек күпмилләтле республиканың хөкүмәтендә тел сәясәтен алып баручы махсус бер бүлек, ә Президент аппараты каршында махсус департамент кебегрәк подразделение булыр дигән өмет бар.

- Җәмәгать тәртибендә эшләп тә, Телләр комитеты шактый гына эшләр башкарып өлгерде кебек.

- Баштан ук шуны ачыклап китсәк дөрес булыр: бер әңгәмәдә генә комитетның барлык эшләрен яктыртып

бетеру, телләр мәсьәләсенә караган проблемаларның һәр ягына тукталу мөмкин түгел. Иң мөһимнәренә генә тукталыйк.

Комитет эшне берничә юнәлештә алып бара: законның, дәүләт программасының үтәлешен контрольдә тоту; хокукый һәм норматив документлар эшләү; әлеге мәсьәләне фәнни яктан өйрәнү; шәһәр һәм районнарда оешкан комиссияләргә гамәли һәм методик ярдәм күрсәтү. Комитет, кварталга бер тапкыр җыелып, Телләр турындагы законны гамәлгә ашыруның барышын тикшерә. Узган утырышларда аерым районнарда законның үтәлеше каралды. Әйтик, Әлмәт, Аксубай, Кукмара, Алабуга шәһәре һәм районында, Чаллыда татар телен гамәлгә кертү турындагы мәсьәлә җентекләп тикшерелде. Шулай ук кайбер министрлыклар һәм дәүләт комитетларының, мәсәлән, республика Элемтә министрлыгының законны үтәү буенча эшчәнлеген тикшердек.

- Бу уңайдан аеруча Мәгариф министрлыгына зур бурычлар йөкләнә, шулаймы?

- Телләр турындагы законны гамәлгә куюда Мәгариф министрлыгы шактый гына эшләр башкарды инде. Закон кабул ителгәннән соң, балалар бакчаларында, мәктәпләрдә никадәр алга китеш булуы - барыбызның да күз алдында. Бүген телне укытуның сыйфатына игътибарны арттыру - көнүзәк мәсьәлә.

Гомуми урта белем бирү системасыннан тыш, махсус урта белем һәм югары белем бирү учреждениеләребез дә күп бит әле. Менә аларда эш кыенрак бара. Бигрәк тә техникумнарда һәм училищеларда. Дөрес, хәзер татар телен укытуга игътибар аларда да арта төште. Фәннәрне татар телендә укытуга килсәк, хәлләр аяныч. Ә бит уку йортларының күбесендә татар телен камил белергә тиешле урта буын җитәкчеләре әзерләнә. Без, энтузиастларны тартып та, махсус совет оештырып та, эшне җанландырырга тырышып карадык. Соңгы вакытта бу эшне җайга салуның нәтиҗәле юлын таптык кебек: уку йортларының үзенчәлегенә бәйле рәвештә берничә училище базасында махсус координацион советлар оештырдык. Уңышлар булыр дип өметләник.

Югары мәктәпләребездә эшләр җайга салына башлады, дияр идем. Татар телен гамәлгә кертү буенча вузара махсус гыйльми-методик совет оештырылды. Совет утырышларында сүз татар телендә укытуны яхшырту турында бара, югары уку йортларына Татарстан хөкүмәте тарафыннан бирелгән өстәмә акчаның ничек сарыф ителүе тикшерелә. Узган ел дәүләт вузларына ул вакыттагы акча белән 1 миллиард 500 миллион сум, быелның беренче яртыеллыгында 500 мең сумнан артыграк акча бүлеп бирелде. Югыйсә, татарча укыту мәсьәләсен кузгата башласак, вуз җитәкчеләре акча юклыктан зарлана иде. Хәлбуки, акчаны федераль бюджеттан гына алган очракта да, югары уку йортлары татарларга татар телендә белем бирүне оештырырга тиеш. Бу хакта Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы хөкүмәтләре арасында югары белем өлкәсенә караган килешүнең беренче маддәсендә акка кара белән язып куелган.

Телләр турындагы законны тормышка ашыруда республикабызның барлык педагогик уку йортлары, шулай ук Казан архитектура-төзелеш академиясе, авыл хуҗалыгы академиясе, Кама политехник институты уңышлы эшли. Мәдәният һәм сәнгать академиясендә татарча укытуны гамәлгә кую эшен махсус программа нигезендә алып баралар.

Соңгы елларда гына "Мәгариф" нәшрияты югары уку йортлары өчен математика, гомуми химия, теоретик механика кебек фундаменталь фәннәр, авыл хуҗалыгы белгечлекләре буенча шактый дәреслекләр чыгарып өлгерде. Бу эш дәвам итә.

Вузара гыйльми-методик совет безнең комитет белән берлектә югары уку йортларында татарча укыту проблемаларына багышланган махсус фәнни-практик конференция дә уздырды.

- Мондый конференцияләр үткәрү Телләр комитетының мөһим бер эш юнәлешенә әйләнеп бара бугай.

- Әйе. Бая әйтелгәннән тыш, быел гына да "Татар теле һәм яңа информацион технологияләр", аннары "Татарстан Республикасында ономастика мәсьәләләрен хәл итү юллары" дигән темага фәнни-практик конференцияләр уздырдык. Бу конференцияләрнең материалларын туплаган махсус җыентыклар чыгарабыз.

Менә шушы уздырган конференцияләрне йомгаклау һәм Телләр турындагы законны үтәүдәге алты еллык эшчәнлегебезгә йомгак ясау максатында, шулай ук бу юнәлештәге стратегик бурычларны ачыклау өчен быелның ноябрь аенда Казанда тагын бер бик зур фәнни-практик конференция уздырачакбыз. "Татарстан Республикасында телләрнең бүгенгесе һәм киләчәге" дигән исем астында оештырыла торган бу чарада тел галимнәре, вуз укытучылары, мәктәп хезмәткәрләре генә түгел, төрле министрлык һәм ведомстволар вәкилләре дә турыдан-туры катнашачаклар. Мәсәлән, республиканың Кулланучылар хокукларын яклау дәүләт комитеты һәм Татарстан Сәүдә министрлыгы белән берлектә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә икетеллелекнең тормышка ашырылуы мәсьәләләре буенча махсус секция эшләячәк.

Конференция уңаеннан татар телен гамәлгә куюда булган тәҗрибәне гомумиләштергән ике җыентык әзерләнә. Аларның беренчесе "Татарстан Республикасында тел сәясәте: 1920-30 еллар", икенчесе "Татарстан Республикасында тел сәясәте: 1980-90 еллар" дип атала.

- Телләр комитетының тагын бер мөһим эш юнәлеше - туган телебезне гамәлгә кую белән бәйле хокукый-норматив документлар эшләү. Моның әһәмияте нидә?

- Моның әһәмиятен дәлилләү өчен бер генә мисал китерим. Менә хәзер шәһәр һәм район хакимиятләре каршында Телләр турындагы законны тормышка ашыру буенча комиссияләр оешты. Ләкин ул комиссияләрнең структурасын, бурыч-функцияләрен, эш юнәлешләрен, республика Телләр комитеты белән үзара мөнәсәбәте нинди булырга тиешлеген әлегә тулысы белән беркем күзалламый иде. Без, шушыларның барысына да ачыклык кертүче нигезләмә эшләп, районнарга тараттык.

Гомумән, Телләр турындагы законны тормышка ашыруның бердәнбер юлы - аны төрле юнәлешләрдәге өстәмә хокукый-норматив документлар белән көчәйтү һәм шуларга таянып эш итү. Дәүләт Советы трибунасыннан Телләр комитеты рәисе урынбасары И. Хәйруллин да законны тормышка ашыру буенча дәүләт программасының мөһим кимчелеге буларак бу программада әнә шундый документлар эшләү күздә тотылмавын билгеләп үтте. Телләр турындагы законны үтәргә юнәлеш бирә, мәҗбүр итә торган механизмнарыбыз юк. Чувашиядә, мәсәлән, үзләренең Телләр турындагы законнарына әлеге документны үтәмәгән предприятие, учреждение, оешма җитәкчеләре, милек формасы нинди булуга карамастан, 5 тән алып 10 га кадәр минималь хезмәт хакы күләмендә штрафка

тарттырылалар диган өстәмә кабул иткәннәр. Мондый энтәлектәгә законны кабул иту безнең Дәүләт Советында озакка сузылмасын иде.

- Урамнарда элмә такталар язудагы хаталар хакында купме язабыз. Шундый хатага юл куйган житәкчеләр жавапка тартылырга тиештер бит.

- Анысы дөрес. Кызганычка каршы, безнең комитетның да, Казан кебек эре шәһәрләр хакимиятләренең дә бу мәсьәләне әле дә булса хәл итә алганнары юк. Мондый элмә такталарның ничек һәм кем тарафыннан расланырга тиешлеген махсус норматив документ аша рәсмиләштеру иң нәтижәле юл булыр иде. Ә хәзергә аларны кем ничек булдыра, шулай яза. Коллективларында берәр татар кешесе булса, шуңа мөрәжәгать итәләр дә, йөз төрле хата белән язып куялар.

Торак пункт атамаларын, географик исемнәрне татарча язуда да норматив документларның булмавы комачаулык итә иде. Хәзер андый документлар эшләү жайга салынып килә. Әйтик, узган ел Татарстан Республикасының географик объектларына исем биру һәм исемнәрен алыштыру буенча тәкъдимнәр эшләп, Министрлар Кабинеты карары белән расладык. Бүген исә Дәүләт Советының Мәдәният һәм милли мәсьәләләр буенча даими комиссиясендә республика Топонимия комиссиясе белән берлектә географик атамаларга караган берничә закон проекты хәзерләнә.

- Ким Мөгаллимович, татар телен гамәлгә куюдагы иң зур кыенлык нидән гыйбарәт?

- Иң кыены - шушы эшкә жаны-тәне белән бирелгән, теория белән коралланган кадрлар житешмәве. Булган фәнни потенциалның да бу эшкә тартылырга бик ук теләмәве. Шуңа күрә без бик еш кына мөмкинлекләрне тиешенчә файдалана алмыйбыз. Мәсәлән, икетеллелекне гамәлгә ашыру өчен максатчан булеп бирелә торган акчаны тагын да нәтижәлерәк файдаланып булыр иде.

- Андый акча нинди оешмаларга каралган?

- Телләр турындагы законны тормышка ашыруда турыдан-туры катнашучы министрлыкларга, фәнни оешмаларга, газета-журналларга, нәшриятларга, дәүләт карамагындагы югары уку йортларының һәркайсына да өлеш чыгарырга тырышабыз. Узган ел 5 миллиард 800 миллион сум акча булеп бирелде. Быел яңа акча белән 6 миллион сум планлаштырылды. Бу акчаны тиешле оешмаларга булу принципларында уйлап бетерәсе яклар бар әле. Бәлки, күбрәк телне гамәлгә куюның аерым юнәлешләрен житәкләгән оешмалар аша эшләү максатка ярашлырак булыр. Әйтик, компьютерларны татарчалаштыру мәсьәләсенең күп кенә яклары белән һәр оешма узе шөгыльләнә алмый. Бу эш белән хөкүмәттән бирелгән средстволар хисабына махсус узәк шөгыльләнсә, финанс чыгымнары да азрак тотылачак. Латин графикасында укытучылар әзерләүне дә, гомумән, графика алыштыру белән бәйле барлык юнәлешләрне дә алдан ук узәкләштеру кирәк булыр, дип саныйм мин. Республикабыз халыклары телләрен яклау һәм саклау белән шөгыльләнүче махсус фонд оештыру телэгебез бар. Югарыда саналган проблемаларны хәл итүдә зур бер таяныч булыр иде ул.

- Латин дигәннән, Телләр комитеты бу алфавитны кайтару проблемалары белән дә шөгыльләнәме? Әлеге реформа тормышка ашачакмы?

- Әйе, бу мәсьәлә белән турыдан-туры Министрлар Кабинеты шөгыльләнә. Быелның апрель башында Телләр комитетының киңәйтелгән утырышы махсус латин графикасына кайту мәсьәләләренә багышлап уткәрелде. Әлеге проблема моңа кадәр ныклап өйрәнелгән иде. Төрле оешмалар, ведомстволар, белгечләр, аерым кешеләрнең тәкъдимнәре анализланды һәм югарыда әйтелгән утырышта тикшеругә латиницаның төп ике варианты - уртак төрки һәм узебезнең Яңалифкә якын вариантлары куелды. Шушы ике вариантны яклаучылардан торган килештеру комиссиясе төзелде. Комиссиянең эш нәтижәләре буенча латин графикасының соңгы вариант проекты әзерләнде. Ул - төрки телләрнең уртак графикасы нигезендә эшләнгән яңа татарча алфавит. Бүген аерым министрлыклардан латинга кайту белән бәйле документлар тупланды. Әйтик, Финанс министрлыгыннан реформа таләп итә торган чыгымнар күрсәтелгән бәяләмә керде, Юстиция министрлыгы мәсьәләнең хокукый ягы белән бәйле документлар эшләде. Якын араларда әлеге закон проекты Дәүләт Советы карамагына тәкъдим ителәчәк.

- Күчеш озак вакытны алачакмы һәм, гомумән, моңа күчебез житәрме икән?

- Бу мәсьәләне төрле яклап өйрәнергә тырыштык. Мәсәлән, латиницага күчкән Әзәрбайжан, Үзбәкстан кебек төрки илләрнең тәжрибәләрен эшкә жиктек. Яңа графикага күчүнең оптималь сроклары да тәкъдим ителә. Проектта каралганча, бу эш 2001 елның 1 сентябреннән башланып, ун ел эчендә төгәлләнергә тиеш. Соңгы сүзне Дәүләт Советы әйтәчәк, билгеле.

Ә инде күчебез житү-житмәве мәсьәләсенә килсәк, минем фикеремчә, бу, һичшиксез, тормышчан проект. Монда иң мөһиме акча мәсьәләсе генә дә түгел. Хөкүмәт тарафыннан тел проблемаларын хәл итүгә игътибар зур. Иң мөһиме - латинга кайтуга караган дәүләт программасын һәм башка документларны алдан жентекләп эшләү. Телләр турындагы законны тормышка ашыру вакытында жибәргән хаталарны кабатламыйсы иде. Хәтерлисездер, әлеге закон кабул ителеп ике ел узгач кына, аны тормышка ашыру программасы кабул ителде, ә аны гамәлгә куючы норматив-хокукый документлар исә әле эшләнә башлады гына. Шулай итеп күп вакытны югалттык. Татар телен гамәлгә керту өчен уңайлы булган милли күтәрелеш еллары, мина калса, тиешенчә ук файдаланылмады. Латинга кайту турында закон кабул ителә калса, бу реформаны тормышка ашыруның стратегик юллары билгеләнергә, конкрет механизмнары булдырылырга тиеш.

Сүземне йомгаклап шуны әйтәсем килә, бүген республикабызда татар телен тулы хокуклы дәүләт теле итүгә, бездә яшәүче башка милләт халыкларының телләрен саклауга һәм үстерүгә юнәлдерелгән зәлекле сәясәт алып барыла. Туган телебезне яклауга, үстерүгә юнәлдерелгән бер генә инициатива, бер генә яңалык та кире кагылмый, киресенчә, хуплана гына. Татар телен яңа баскычка күтәрү өчен тарих безгә мөмкинлек бирде. Аны кулдан ычкындырмыйча, милләтебезнең бөтен көчен ана телебезгә хезмәткә туплыйсы иде!

Әңгәмәдәш - Васил ГАРИФУЛЛИН.

Солтан ИСХАКОВ фотосы.

Без каян килеп чыкканбыз?

(Татар халкының барлыкка килүенә яңа караш)

Хәзерге татарлар йә болгарларның, йә Казан ханлыгы татарларының турыдан-туры варислары дип раслаучы кайбер галимнәрнең чик карашларыннан тыш, күпчелек җитди тикшеренүчеләр хакыйкать кайдадыр урталыкта ята, ягъни хәзерге татарларның барлыкка килүендә болгар элементы да, татар элементы да булган, дип саныйлар. Бу галимнәрнең карашларындагы аерма халкыбызның килеп чыгышында кайсы элементның күбрәк урын тотуын раслауда гына. “Болгарчылар” белән “татарчылар” арасында бүген нәкъ менә шушы мәсьәлә тирәсендә бәхәс бара да инде.

Рафаэль МӨХӘММӘТДИНОВ,
ТР Фәннәр академиясе Тарих институтының өлкән гыйльми хезмәткәре.

Мин тикшеренүчеләргә биш сорау (икесен “болгарчылар”га, өчесен “татарчылар”га) бирмәкче булам. Үзем дә бу сорауларга озак вакытлар җавап табарга тырыштым. “Болгарчылар”ның да, “татарчылар”ның да җаваплары мине канәгатьләндерә алмады.

Бу сораулар тарихыбыздагы “ак тап”ка кагыла. Татар халкының килеп чыгышын өйрәнү мәсьәләсендә алга китешебез аларга дөрес җавап табуга бәйле булачак.

Сорауларым түбәндәгеләр:

“Болгарчылар”га:

1. Ни өчен болгарлар тормышында Кара диңгез буеннан Урта Иделгә күчеп килү кебек гаять зур вакыйга татар халык авыз иҗатында чагылмый калган? Ни өчен Кара диңгез буенда Бөек Болгар, болгарларның Византия белән элемтәләре һәм, гомумән, аларның көньяк чорындагы тормышы турында бернинди риваятьләр сакланмаган?

2. Ни өчен болгарлар Ибн Фадлан белән сөйләшкәндә Кара диңгез буендагы якын тарихларын телгә алмаганнар?

“Татарчылар”га:

1. Ни өчен татар фольклорында Казан ханлыгы гаскәрләренең яудагы батырлыкларына дан җырлаган героик дастаннар һәм тарихи җырлар юк? Мәгълүм булганча, алар Вологданы, Костроманы, Муромны алганнар, Мәскәүдән ясак түләткәннәр, ел саен дистә меңнәрчә русларны әсир иткәннәр һ. б.

2. Ни өчен Мөхәммәдьяр руслар Казанны яулап алыр алдыннан иҗат иткән “Төхфәи Мәрдән” исемле поэмасында татарларны дошманнарча искә ала, аларны башка килмәстәй иң әшәке сыйфатлар белән сурәтли?

3. Ни өчен Казан халкы 1552 елда һәм аннан соң 6-8 ел эчендә руслар белән сугышлар вакытында, әйтерсең лә, икегә бүленә: берничә дистә мең кеше Казанны саклый, шуннан да күбрәк кеше Шаһгали җитәкчелегендә дошман ягыннан сугыша, аннары Казан алынгач, бер өлеше русларга каршы партизан сугышы алып бара, ә икенче бер өлеше Мәскәү ягыннан Ливон сугышында катнаша?

Шушы сорауларга җавап эзләп, мин үзебезнең фольклорга мөрәҗәгать иттем. Беренче гомуми тәэсорат шундый: Византияне тетрәткән, аннары Урта Иделгә күчеп килгән, Костроманы, Муромны яндырган һәм Мәскәүне калтыратып торган халык - бер халык, ә безнең фольклорны иҗат иткән халык - бөтенләй башка халык. Бу - күпчелек очракта урман белән бәйле шактый дәрәҗәдә тыныч халык фольклоры, чөнки анда дала өстенлек итми. “Каган” яки “хан” кебек төшенчәләр дә күп түгел, ә күбрәк “патша” (падишаһ) сүзе кулланыла. Гомумән алганда, безнең фольклор нигезендә хәрби-героик фикер сөреше түгел, ә ниндидер тыныч халык фикерләве ята.

Шул ук вакытта “болгарчылар” безнең халыкның нигезе итеп үз заманында Византияне тетрәткән болгарларны, ә “татарчылар” Мәскәүне куркытып торган татарларны алалар.

Фольклорны хан яки президент сарайларында югары катлаулар түгел, ә халыкның төп һәм иң күп санлы өлеше иҗат иткәнен исәпкә алсак, түбәндәге нәтиҗәгә килергә мөмкин: хәрби яктан яхшы оешкан болгарлар, көньяктан килеп Урта Иделдә дәүләт төзи алсалар да, анда яшәгән ниндидер күпсанлы җирле төрки халыкка нисбәтән бик аз санлы булганнар. Безнең борынгы фольклор Кара диңгез ярында беркайчан да булмаган һәм Византияне белмәгән шушы җирле халык тарафыннан тудырылган, шуңа күрә дә анда әлеге фактлар юк. Болгарлар дәүләткә исем генә биргәннәр һәм җирле төркиләргә хәрби һәм административ гадәтләрен, традицияләрен сеңдергәннәр, ә үзләре тиз арада җирле төрки халык эчендә эреп югалып беткәннәр.

Икенче төрле әйткәндә, болгарлар җирле төрки халыкка цивилизация элементларын алып килгәннәр, әмма фольклор калдырмаганнар, чөнки фольклорны аз санлы хәрби-административ катлау түгел, ә халык иҗат итә.

Икенче сорауга җавап биргәндә, шу-

ны күздә тотарга кирәк: болгарларның Иделгә күчеп килүеннән (VIII гасыр уртасы) Ибн Фадланның Болгариядә булуына (922 ел) гасыр ярым гына вакыт үткән, ә гарәп сәяхәтчесе белән әңгәмәләрдә Византиягә һәм көньяктан Иделгә күчеп килүләренә бәйле бөек вакыйгаларны бер тапкыр да искә алмаганнар. Бу - шул вакытта болгарларның җирле төрки халык тарафыннан тулысынча йотылуы турында сөйли. Кем әйтмешли, халык юк, истәлекләр дә юк. Бары дәүләт кенә һәм бу дәүләтнең болгар дигән исеме генә торып калган.

Өченче сорауга җавап бирер алдыннан, әйтергә кирәк: Казан ханлыгы гаскәрләренең сугыштагы батырлыклары һәм җиңүләре турында фольклорыбыз юк.

Хикмәт шунда, барлык бу батырлыклар Казан ханлыгының хәрби-административ катлавы тарафыннан кылынган. Әлеге катлауны үз вакытында 3000 сугышчының, Олуг Мөхәммәт җитәкчелегендә килеп, Казан вилаяте (өлкәсе) белән идарә итә башлаган күчмә нугайлар төркеме тәшкил иткән. Нәкъ менә шул нугайларны татарлар дип атаганнар да инде, чөнки нугайлар үз заманында хәрби яктан Алтын Урда дәүләтен тотып торган этнос булган. Әмма алар илнең төп халкын тәшкил итмәгәннәр. Төрле сәяси низаглар вакытында алар Казанга йә килә, йә китә торган булганнар. Руслар Казанны алгач, аларның бер өлеше Мәскәүгә хезмәткә күчкән, икенче өлеше туган далаларына качып киткән.

"Төп җирле халык" үзен "Казан кешеләре", "казанлылар" яки "мөселманнар" дип атап йөрткән һәм, табигый инде, аның фольклорында "татар-нугай"ларның җиңүле сугышлары берничек тә чагыла алмаган. Менә ни өчен безнең фольклорда хәрби-героик юнәлеш юк та.

Кызыклысы шул: Алтын Урда һәм Казан ханлыгы халыкларының руслар "татар" дип йөрткән өлеше үзен "татар" дип атамаган. Алтын Урда һәм Казан ханнары төрек солтанына һәм поляк короленә юллаган бер хатта да үзләрен "татарлар", ә ханлыкларын "татар ханлыклары" дип язмаганнар. Хәзерге көндә алтын урдалыларның һәм нугайларның ике очракта гына үзләрен "татар" дип атаулары билгеле.

1. Беренче очрак: Казан ханы Сафа-Гәрәйнең поляк короле Сигизмунд I гә (1538-1545) язган хатында: "Сез хәзрәтләр миңа тылмачыгыз татар Әфәндәй хезмәтчесен һәм кәгазьләрегезне җибәрдегез" дигән тезмә бар.

2. Икенче очрак: ул - Нугай Урдасы кенәзе Исмәгыйльнең Иванга грамотасы, 1555 ел. Исмәгыйль яза: "Әстерхан патшасыз һәм "татарлар"сыз яши алмый, һәм син (Иван - **Р. М.**) патша малае Кайбатулланы патша ясап безгә җибәр. Ә инде татар кирәк булса, без татарны табарбыз. Татар бездән булыр".

Уйлавымча, беренче очракта Казан ханы "татар тылмачы" дигән тезмәне үз хатының Европадагы христиан монархына юллануын күздә тотып куллана, чөнки Европада ул заманда нугайларны һәм Көнчыгыш Европаның башка төрки халыкларын "татарлар" дип атап йөрткәннәр, ягъни хан җиңел аңлашыл-

сын өчен, чит ил атамасын кулланган булып чыга.

Икенче очракта Нугай Урдасы кенәзе, рус терминологиясенә күчеп, Әстерханның булачак ханы якындагы нугай хәрби отрядларын “татарлар” дип атарга мәҗбүр булган. Ул турыдан-туры: “Татарлар бездән булачак, ягъни “татар” отрядлары бездән, “нугайлар”дан төзелгән, дип яза.

Ике очракта да “татар” сүзе нугайлар өчен үзатама булмаган, ул руслар белән сөйләшүләр алып барганда кулланылган.

“Татар” сүзе нугай мохитендә башта христианлыкны кабул иткән һәм рус патшасына хезмәткә күчкән төркиләрне белдергән дип фараз кылырга урын бар. Ә аннары Казан ханлыгында “татар” атамасы сүгенү сүзе булып, исламны белү җәһәтеннән күчеп йөрүче надан урдалыны,үзенә бертөрле дала маргиналлыгын белдергән.

Дүртенче сорауга, ягъни Мөхәммәдьярның татарларны күрә алмавына килгәндә, әйтергә кирәк: Мөхәммәдьяр үзен татар, ягъни дала баласы нугай дип санамаган. Ихтимал, Казан ханлыгында ике элита яшәгәндер, берсе - нигездә “татар” дип аталучы нугайлардан торган хәрби-административ элита һәм икенчесе - “казанлы мөселман”нардан, ягъни төп җирле халык вәкилләреннән торган интеллектуаль-дини элита.

Халыкның бу ике төркеме, ягъни шәһәр мөселманнары һәм дала нугайлары арасында көндәшлек яшәп килгән, ә ул тарихның кискен борылышларында дәүләттә кайсы элита хакимияттә булырга тиешлеген хәл иткәндә каршылыкка үсеп җитә торган булгандыр, мөгаен.

Бишенче сорауга җавап бәян ителгәннәрдән килеп чыга. Дини элита һәм аңа кушылган аз санлы татарлар ислам байрагы астында башка дин тотучыларга каршы соңгы кешегә хәтле сугышу ягында булганнар. Дин галиме Колшәрифнең үз шәкертләре белән Казанны саклаганда һәлак булуы бер дә очраклы хәл түгел.

Татарлар өчен, дала нугайларындагы кебек, дин сәясәттә төп фактор булмаган. Алар өчен көчле, йогынтылы һәм түләүгә юмарт феодал кирәгрәк булган, ә анын нинди дин тотуы дала кешеләре өчен мөһим роль уйнамаган.

Үзләренең патшабикәсе Сөембикәне русларга әсирлеккә бирү кебек чирканыч факт, дистәләгән мен татарның руслар ягыннан Казанны штурмлашуы һәм шул чамасы татарнын Мәскәү ягыннан Ливон сугышында катнашуы, ә аннары аларның күпләп чукынуы һәм рус морзалары сафына басуы әнә шуның белән анлатыла.

Җирле “казанлылар” һәм “мөселманнар” үз авылларында һәм шәһәрләрендә ислам байрагы астында русларга каршы партизан сугышы алып барганнар. Шунысы характерлы: халкыбызның моннан соңгы восстаниеләренең күпчелеге татар яки Казан ханлыгын торгызу байрагы астында түгел, ә ислам байрагы астында барган.

Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин: болгарлар килгәнче үк Урта Иделдә күпсанлы төрки халык яшәгән. Бу халык бердәм этнос булмаган, ә төрле кабиләләрдән торган. Барлык бу кабиләләр, болгарлар тарафыннан бер дәүләткә берләштерелгәч тә, үз атамаларын йөрткәннәр һәм дәүләтләре генә болгар дәүләте дип аталган. Бу, әйтерсең лә, дәүләткә нигез салучы болгарлар икәнлеген искәртүче тарихи атама булган.

Ул чордагы этник хәлне болай анлату Болгар дәүләте җимерелгәннән соң “болгар” этнонимының акрынлап юкка чыга баруы белән дә раслана, чөнки күпчелек халыкның болгарларга бернинди галәкәсе булмаган, алар бары “Болгар” дәүләте гражданнарын тәшкил иткәннәр.

Болгарларны йоткан һәм гасырлар дәвамында үзен ислам мәдәнияте белән ныгыта килгән җирле төрки халык исә Казан ханлыгынын төп халкы булган. Анын феодаль өске катлавы татар дип йөртелгән далалы нугайлардан торган.

Моннан түбәндәге нәтиҗә соралып тора: халкыбызның килеп чыгышында төп этник компонентлар болгарлар да, татарлар да түгел, ә ниндидер күпсанлы һәм борынгырак җирле төрки этнос булган. Ул гасырлар дәвамында болгарлардан да, татарлардан да иң яхшы тәҗрибәне үзләштерә килгән. Анын бер генә нәрсәне эшләргә кодрәтеннән килмәгән: “төрки” этнонимын гасырлар аша саклап кала алмаган.

Бу җәһәттән бер факт бик кызыклы. Хиҗрәт белән 433 елда (безнең эранын XI гасыр уртасы) Багдадта бер болгар хаҗиеннән: “Болгарлар нинди халык соң?” - дип сораганнар. Ул: “Бу - төркиләр белән сакалабалар кушылу нәтиҗәсендә килеп чыккан халык”, - дип җавап биргән.

Ихтимал, телгә алынган бу “төркиләр” Урта Иделнен болгарларга кадәрге күпсанлы халкы булгандыр. Ул фин телле җирле кабиләләр белән нык катнашып беткәндер. Гарәпләр бу кабиләләрне “сакалаба” дигән җыелма исем белән атап йөрткәннәр. Аннары болгарлар килгәннәр, җирле төркиләр белән катнашып беткәннәр, алар белән дәүләт төзегәннәр һәм үзләренең исемнәрен беркетеп калдырганнар.

Этногенезны болай анлату фольклор мәгълүматлары белән дә раслана. Болгар шәһәренә нигез салыну турындагы тарихи риваятьтән кыскартып кайбер мәгълүматлар китерәбез.

“Нух пәйгамбәрнең өч улы булган. Аның бер улы Яфәс атлы икән. Яфәснең Газый, Төрек, Алып исемле өч улы булган.Төрек үзенең кардәше Алып һәм башка туганнары белән ерак җиргә күчеп киткән. Ул шул китеше белән ерак салкын якнын зур бер суы янына барып урнашкан. Бу сунын ул вакытта аты булмаган. Шулай бу елга ул илдә үзенең зурлыгы, балыкның күплеге белән дан тоткан. Болар килеп утырган җирнең урыны саз-ламык һәм кап-кара урман булган.

Бервакыт Алып ауга чыккач үзе белән бер телдә сөйләшә торган кешеләр очраткан. Тел бер булгач, Алып белән бу кешеләр үзара анлашканнар. Шуннан соң Алып кардәше Төрек янына кайта алмагач, бу кешеләр белән яши башлаган. Ул шул кешеләр арасында үзенә бер кыз да сайлап өйләнгән. Алып үзенең хатыны белән киңәшкән дә, балага, елаган чагында кулларын болгаганлыктан, Болгар дип ат кушкан. Икенче балаларына алар Бортас исеме биргәннәр. Шушы исемнәргә бәйле рәвештә Болгар һәм Бортас шәһәрләре барлыкка килгән”.

Әгәр Алыпның төрки туганы икәнлеген - аны шартлы рәвештә Төрки дип атарга була - исәпкә алсак, гарәп тарихчыларының югарыда китерелгән һәм болгарларнын төркиләр белән сакалабалар катнашуыннан килеп чыгуы турындагы мәгълүматлары әлеге тарихи риваять сюжетына тулысынча туры килә.

Этногенезыбыз турындагы минем фаразны Татарстанда тамыры “төрки” булган берничә атаманың яшәп килүе дә ныгыта: Төрекләр, Төрек-Тәмте, Төркеш.

Шулай итеп, безнең халыкның килеп чыгуында төп этник компонент “төркиләр” дип аталган кабиләләр булырга тиеш, дип фараз кылырга мөмкин. Хәзер аларны шартлы рәвештә “Идел төркиләре” дип атарга була.

Бу - мәсьәләнең фәнни ягы. Ә сәяси күзлектән караганда, мин хәзерге “татар” этнонимын үзгәртү тарафдары түгелмен, чөнки бу - безнең халыкны бүгәләүгә китерер һәм чын бәйсезлеккә ирешүгә бәйле иң мөһим проблемаларны хәл итүдән читләштерер иде. Кем әйтмешли, тарих борылышларындагы этнонимнарны үзгәртмиләр. Әмма үз тарихыңны белү зарур. Халкыбызның төрле этнонимнарының килеп чыгуы һәм югалуы тарихын яктыртудан куркырга ярамый. Иң ярамаганы шул: фәнне сәясәт белән бутарга, этнонимнар проблемасын сәясәтләштерергә һәм, шуның белән империя көчләрен шатландырып, бердәм этник үзанны какшатырга кирәкми.

Рөстәм МӨХӘММӘТҖАНОВ фотосы.

Афәрин, милләттәшләр!

Соңгы вакытларда республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләребез тормышында мәчет-мадрәсә ачылу кебек куанычлы күренешләр артты. Мәсәлән, ӘСТЕРХАН каласының "Хажи Тархан" Югары мөселман мәдрәсәсендә булачак имам-хатыйплар, шәригать һәм гарәп теле укытучылары белем алуга керештеләр.

САМАРА өлкәсенең Похвистнев районы Гали авылы мәдрәсәсендә 15 сентябрь көнне алтынчы уку елы башланды. Ә менә шул ук өлкәнең Яңа Куйбышев районы мөселман җәмәгатьчелеге исә мәчет төзү эшенә керешге.

"Чишмә"гез саекмасын!

САНКТ-ПЕТЕРБУРГ. Әнвәр Сәетбагин җитәкчелегендәге "Чишмә" татар-башкорт милли-мәдәни үзәге эшчәнлеген башлап җибәрде. Үзәк каршында татар якшәмбе мәктәбе ачылды. Аның директоры итеп күпьеллык педагогик тәҗрибәсе булган Мөхлисә Зарипова билгеләнде.

Санкт-Петербургның мөселман дини оешмаларында да яңа уку елы башланды. Ел дәвамында милләттәшләребез Коръән уку сәләтенә төшенәчәкләр, намаз кылу кагыйдәләренә һәм башка дини тәртипләргә өйрәнәчәкләр.

"Бердәмлек" бергә туплый

БИШКЕК. Кыргызстан Юстиция министрлыгы тарафыннан "Бердәмлек" татар берлеге теркәлде.

Әлеге иҗтимагый оешманы республика галимнәре һәм эшкуарлары җитәкли. Оешманың төп максаты - канкардәшләрне социаль яклау, тарихи Ватан - Татарстан белән икътисадый һәм мәдәни элемтәләрне ныгыту.

Көч - бергәлектә

ЧУВАШИЯ Республикасында яшәүче татар яшьләре үзләренең иҗтимагый оешмаларын булдыру теләген белдерделәр. Ул Татар яшьләре үзәге дип аталачак. Хәзерге көндә оештыру комитеты үзәкне рәсми теркәү белән шөгыльләнә. Республика татар яшьләрен туплау, проблемаларны бергәләп хәл итү максат итеп куела.

Булдырасыз!

КРАСНОУФИМСК. Свердловск өлкәсенең Красноуфимск районында сигез татар авылы бар. Быелгы уку елыннан алардагы барлык мәктәпләрдә татар теле укытыла башлады. Ә татар теле укытучыларын 1993 елдан бирле Красноуфимск педагогия училищесы әзерли.

Бу шәһәрнең татар халык театры мәктәпләрдә еш чыгыш ясый. Сентябрьдә ул унынчы сезонын башлап җибәрде. Артистлар Хәй Вахитның "Кияүләр" әсәре буенча әзерләнгән спектакльнең премьерасын күрсәттеләр.

Аксакаллар тарихны хәтерли әле

КРАСНОЯРСК педагогика институтына караган этнография экспедициясе Пиров районы татарлары тарихын һәм мәдәниятен өйрәнү эшчәнлеген тәмамлады. Тарихчы студентлар әлеге төбәкнең дүрт авылында булдылар. Алар җирле аксакаллардан мондагы татарларның гореф-гадәтләрен язып алдылар, шулай ук матди һәм рухи мәдәният үрнәкләре белән дә кызыксындылар. Киләсе елда бу эш тагын да дәвам итәчәк.

Минскида Коръән өйрәнәләр

МИНСК шәһәрендә ислам нигезләрен һәм Коръән китабын өйрәтү мәктәбе ачылды. Анда Беларусь Республикасы уку йортларында белем алучы мөселман студентлары укыта. Теләге булган һәркем әлеге мәктәпнең шәкерте була ала.

Сәхнәдә - "Сембер" кызлары

УЛЬЯНОВСК шәһәрендәге "Октябрь" кинотеатрында "Сембер" вокаль-бию ансамбленең концерт сезоны ачылу тантанасы үткәрелде. Тамашачылар кичәдә үзләренең яраткан җырларын тыңладылар, халык биюләрен карадылар. Барысына да драматург Туфан Миңнуллин пьесасы буенча сәхнәләштерелгән спектакль аеруча ошады.

Җир читендә татар моңы

ТАСМАНИЯ. Удмуртиянең Сарапул шәһәрендә туган татар кызы Зөлфия Камалова хәзерге вакытта Австралиядә яши. Торган җире - Аделаида каласыннан 500 чакрымдагы Тасмания утравы. Зөлфия - музыкант, берничә тел белә. Ире Мартин Гакер да тормышын моңга бәйләгән, флейтада уйный.

Канкардәш үз илендә татар җырларын башкаруы белән күпләрне әсирләндерә иде. Башка халык моннарын да тиң күрде ул. Австралиядә яши башлагач та, сагыну-сагышлары үзенеке итте: Зөлфия үзе башкаруында татар җырлары тупланган лазер тәлинкәсен чыгарды.

Хәзер Зөлфиябез җир читендәге ошбу кыйтгада икенче дискын әзерләү белән мәшгуль. Бу эше тәмам булгач та, туган-үскән иленә кайтып китмәк була.

Әрҗияз тавы кунаклар җыйды

ТӨРКИЯНЕҢ милли хәрәкәт фиркасы тарафыннан Әрҗияз - Зөфәр корылтае ел саен үткәрелә. Быелгысы - тугызынчысы иде. Корылтайда Халыкара төрки академия академигы, Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты профессоры Гали Арсланов та катнашты. Профессор үзенең чыгышында 7 миллионлы татар халкының илчесе буларак килүен ассызыклады.

Корылтай кысаларында фәнни конференция дә үткәрелде.

Мәскәү татарлары берләшә

МӘСКӘҮ хөкүмәтенең юстиция идарәсендә башкала татарларының гомумшәһәр милли-мәдәни автономиясе рәсми рәвештә теркәлде. Президенты Рәсим Акчурин рәислегендә узган автономия советында Бөтендөнья татар конгрессына, федераль милли-мәдәни автономиягә һәм Мәскәү мэриясе каршындагы халыкара киңәшмәгә әгъзалыкка кабул ителү турындагы карарлар чыгарылды. Шулай ук автономия катнашында үтәсе чаралар хакында да сөйләшенде.

("ТАТАР-ИНФОРМ")

Журналыбызның редколлегия әгъзасы, Казан дәүләт педагогика университеты ректоры Рүзәл Абдуллаҗан улы ЮСУПОВ сентябрь аенда туган көнен билгеләп үтте. Быел аңа 60 яшь тулды. Шул уңайдан безнең хәбәрчебез аның белән очрашып әңгәмә корды.

Рүзәл ЮСУПОВ: “Тәрбия буенча ДӘҮЛӘТ ПРОГРАММАСЫ кирәк”

- Рүзәл әфәнде, Сез аңлы яшәү дәверендә мактаулы исемнәргә, зур дәрәҗәләргә ирештегез. Ректор, кафедра мөдире, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, берничә академия әгъзасы... 150 ләп фәнни хезмәт, шул җөмләдән берничә монография, уку ярдәмлеге авторы... Телләр арасындагы элемтәләрне өйрәнүгә багышланган хезмәтләрегез быел республиканың Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителде... Кыскасы, күп юллар үтелгән, күпьяклы эшләр башкарылган. Сез үзегез аларны ничек бәялисез?

- Тормыш үзе каршылыклы булган кебек, сорауларыгызга җавапларымда да каршылык булмый калмастыр.

Әйе, эшли алган кадәресен эшләдем, кулдан килгәнчә тырыштым. Моның нигезендә иренмәү ята. Табигать биргәне белән генә канәгатьләнеп калырга ярамый. Әлбәттә, хәзерге күзлектән караганда, нәтиҗәлерәк тә эшләгән булыр идем. Баштарак тәҗрибә җитмәгәндер. Тормыш шундый бит ул: гел үзгәреп тора. Аның артыннан куып бару гына түгел, ә алгарак карап эшләү фарыз. Бездәге мәгариф системасы яшьләргә белем бирә, әмма аларны тормышка, яшәешкә җитәрлек әзерләми иде. Башка илләрдә яшьләрне гамәли әзерләүгә игътибарны күбрәк бирәләр. Җитәкче эшкә әзерләнүдә бу аеруча нык сизелә. Бездә менеджментлыкка махсус әзерләү системасы юк. Чит илләрдә махсуслашу тирәнрәк. Бездә үзең өйрәнәсең, тәҗрибәне бөртекләп җыясың. Абынып-сөртенеп, борын канатып. Вакытында махсус курслар үтелсә, кемнәрдер өйрәткән булса, һичшиксез, нәтиҗәлерәк эшләгән булыр идек.

Шулай да соңгы елларда башкарылган эшләрем өчен үкенмим. Фикер җыю, тәҗрибә туплау, өлгереп җитү ярдәмгә

килде. Аннары мин җитәкче буларак кына түгел, хезмәткәр буларак эшлим. Ярдәмчеләремне, коллегаларымны тиешенчә эшләтә дә белмимдер әле. Күбрәк үзем эшлим, аларны шәхси үрнәккә ияртергә омтылам, анлы булуларына өмет баглыйм.

Бездә бит җитәкче кешенең эшен бәяләү күрсәткечләре, ана куела торган таләпләр аныкланып җитмәгән. Менә шул шартлар үтәлгәндә күбрәк тә, яхшырак та эшләргә мөмкин булыр иде.

- Шулай да, башкарылган эшгамәлләрнең кайсысын иң әһәмиятлеләрдән санийсыз?

- Мин байтак тормыш юлы үттем. 1955 елдан бирле тынгысыз хезмәттә. 17 яшь тә тулмастан, техникум тәмамлап, Себергә эшкә җибәрелдем. Аннары армиядә хезмәт итү, Казан дәүләт университетында уку, телевидениедә эшләү, педагогика университетында ассистенттан башлап факультет деканына кадәр ара үтү. Шулай да иң нәтиҗәле дәвер ректор булып эшләү чорыдыр. Укытучы, фән эшлеклесе буларак, инде тупланган тәҗрибәгә таянып, үз-үзенне аямыйча эшләү. Минем яшәү кагыйдәм: алындыңмы - гамәленне җиренә җиткер. Әйбәт күрсәткечләргә ирешим дисең икән, бик күп эшләргә кирәк.

Остазым Мирфатыйх ага Зәкиев җитәкчелегендә институтның сизелерлек уңышлары бар иде. Шулай да институт ничектер икенче пландарак кала килде. Үзем дә сизеп тора идем: укыту белән чын-чынлап шөгыльләнү җитми иде. Бу эшнең эченә керергә кирәк булды. Факультетларның совет утырышларында катнашам, кафедраларда булам, кадрларның мөмкинлекләрен өйрәнәм, һәр мәсьәләнең төбенә төшәргә тырышам.

Һәр эштә, бигрәк тә җитәкче эштә, бурыч кую әһәмиятле. Бурыч укытучылар әзерләүнең дәрәҗәсен күтәрүдән гыйбарәт иде. 4-5 ел элек мин аеруча ачык тойдым: укыту системасы камиллектән ерак, формализм, стереотип көчле, белгечләребезгә практика җитми. Менә шул киртәләрне ватарга керештем. Моның өчен актуаль проблемаларга җәмәгатьчелек фикерен тупларга кирәк булды. Укытучылар, студентлар белән очрашам, институтны тәмамлап мәктәптә укытучылар белән фикер алышам: эшебездәге кимчелекләрне ачарга тырышам. Җитешсезлекләрне, аларның сәбәпләрен белү бик мөһим. Алар хакында сүзне үзем кузгатам, шикләремне ныгытырга омтылам. Беләм ич: бөтенесе дә яхшы түгел. Хезмәттәшләремне дә эшебезгә тәнкыйди күзлектән карарга чакырам. Мактанышуга гына китсә, үсеш тукталачак. Тормыш проблемаларны куеп кына тора бит ул. Берсен хәл итәсең, икенчесе туа.

Яңартуны педагогика кафедрасыннан башладык. Анда докторлар күп, дистәгә якын. Әмма теория практикадан ерак, аны бүгенге таләпләр белән бәйләү җитми. Песталоцци тәгълиматын бәян иттең дә, шуның белән вәссәлам дип саныйлар иде. Әлбәттә, Песталоцци да, Макаренко да, башкалары да - бөек педагоглар, ләкин хәзер заманы башка, аның ихтыяҗлары башка. Узган мирасның бүгенге көн өчен файдасы нидә - шунысы кыйммәт ич безгә. Теория белән артык мавыгудан котылу, практиканы күбәйтү зарур иде. Әлбәттә, урнашкан традицияләрне какшату җиңелдән булмады, аерым шәхесләр белән низагка да керергә туры килде. Нишлисең - яңалык кертү ансат гамәл түгел шул. Шунысы куанычлы: тырышуларыбыз бушка китмәде, үзгәрешләр уңай якка булды.

Әдәбиятны укыту мәсьәләсе дә шактый кискен булып алга килеп басты. Проблеманы үзем өйрәндем: программаларны күздән кичердем, имтихан билетларын анализладым, имтиханнарда булып, студентларның белемнәрен тикшердем. Нәтиҗәсе шул: әдәбиятны укыту тарихны укыту икән бит. Иҗатның, әсәрнең идеясе өйрәнелә, авторның чорны ничек чагылдыруы өйрәнелә. Идеология өскә чыга. Ә төп хасият - кешене эстетик тәрбияләү, аны фикерләргә, хисләнергә өйрәтү, аның җанына керү читтә кала.

Әдәбият укытканда авторларны, әсәрләрне сайлап алу бик мөһим. Ә без бик күп язучыларның әсәрләрен колачларга омтылабыз икән. Әдәбият океан бит ул. Пушкинны, Толстойны гына алыйк. Димәк, күбрәк эстетик тәрбия бирә торганнарын сайларга, әсәрләрне тәэсирле итеп укып күрсәтергә, хисләрегезне ачып бирергә кирәк.

Проблеманы гыйльми совет утырышында тикшердек, әдәбият кафедраларына төпле юнәлеш бирдек.

Укытып чыгарган белгечләребезгә мәдәнилек җитмәү үтә борчый иде мине. Шул кимчелекне күпмедер дәрәҗәдә бетерү максаты белән эстетика һәм художество культурасы кафедрасы ачтык. Ул иң зур кафедралардан. Һәр факультетта көнбатыш, рус, татар мәдәнияте, үзенне тоту культурасы буенча 150 сәгатькә җитәрлек курслар керттек. Студентларга башлангыч музыка белеме бирүне оештырып җибәрдек. Ул да аларны эстетик тәрбияләүгә мәгълүм бер өлеш кертәдер дип уйлыйм. "Педагог осталыгы" курсын кертү дә булачак укытучыларның әзерлеген камилләштерүгә юнәлдерелгән.

Сөйләгәннәрем аерым мисаллар гына. Гомумән, без бөтен укыту системасына реформа ясарга омтылабыз. Аның нигезе - укыту планнарын һәм программаларын үзгәртү, яңа алымнар куллану. Шунсыз системаны үзгәртү мөмкин түгел. Без барлык көчебезне әнә шул системаны камилләштерүгә, заманча итүгә туплыйбыз.

- Сез, Рузәл әфәнде, педагогика университеты ректоры гына түгел, сәяси эшлекле дә бит әле. Сез тоталитар режимга каршы көрәштә актив катнаштыгыз, республикабызның мөстәкыйльлеге өчен җан атып йөрдегез, узган сайлауларда республиканың Югары Советына депутат итеп сайланып, яңа законнар эшләүдә актив булдыгыз. Шуңа бәйләнешле ике сорауга җавап аласы килә. Җавапларыгыз өч өлештән торса иде. Өч саны - безнең татарда традициягә кергән сан. Халык авыз иҗатын гына искә төшерик.

Шулай итеп, мөстәкыйльлек алганнан соң ирешелгән өч уңай нәтиҗәне атасагыз икән.

- Күтәрелеш чоры, яңып-көеп йөрүләр бушка китмәде.

Беренчесе. Мөстәкыйльлек иң элек мәдәният өлкәсендә уңай чагылды. Мәдәниятебез күзгә күренеп үсеп китте. Мәктәпләребез рухы үзгәрде. Татар телен өйрәнүгә игътибар артты. Рус балаларын татарчага өйрәтү дә безгә хезмәт итә. Алар беренче сыйныфтан ук телебезне, халкыбызны ихтирам итәргә өйрәнәләр.

Массакүләм мәгълүмат чаралары челтәре кинәйде, радиода, телевидениедә татарча тапшыруларга вакыт артты. Сыйфат ягыннан да үсеш юк түгел. Рубрикалар күбәйде, халыкка эстетик тәрбия бирү мөмкинлекләре ишәйде.

Икенчесе. Фикер хөрлеге җәһәтеннән алга китеш бар. Курку, коллык, "Ходай бәрәңгедән аермасын!" психологиясеннән чигенә төштек. Фикерләү дәрәҗәсе үсә бара. Активлык шактый үсте, әмма ул хәзергә сүрелде шикелле. Кыскасы, кешеләр үзләрен иркенрәк хис итәләр.

Өченчесе. Рухыбыз бераз баеды. Чит илләр белән элемтәләр урнаша бара. Халыклар аралаша. Халыкның күзе ачыла. Элек бөтенләй изоляциядә идек бит. Чит илләрдә йөрүчеләр элек ач булмау өчен яшәвебезгә, тормышның нинди булырга тиешлегенә төшенәләр.

- Хәл ителеп җитмәгән өч проблемага тукталсагыз иде.

- Беренчесе. Тулы мәгънәсендә суверенлыкка ирешә алмадык әле. Сәяси мөстәкыйльлегебез юк. Халыкара хокук субъекты булып булмады. Халыкның пассивлыгы, коллык психологиясенең бетеп җитмәве аркасында җитәкчелек ни тели шуны эшли. Кыю парламентның булмавы да җәмгыятьнең алга барышына комачаулый. Парламент башкарма хакимиятнең һәр тәкъдименә "ләббәйкә" дип торган шартларда хөкүмәт ни тели - шуны эшли.

Халыкның барлык катлаулары активлаша алмый калды. Күтәрелеш елларында интеллигенциянең бер тар катлавы гына уянып өлгерде. Әйдәп баручылар, Марат Мөлековлар күп түгел алар. Милли хәрәкәт таркалды, дөресрәге, аны таркаттылар. Ә эшчеләр, крестьяннар пассив килеш калды. Битарафлык аркасында төп хыял гамәлгә ашмады.

Икенчесе. Икътисад кризисы халык-

ка авыр йөк булып төште. Аның тормыш хәле начарланды: ул булганын да югалтты. Илдәге соңгы вакыйгалар яшәешнең рәтләнүенә өмет уятмый.

Демократиянең үсеш дәрәҗәсе дә канәгатьләнерлек түгел. Кызганыч, тоталитар режим өрәге һаман итәктән тартып тора.

Өченчесе. Мине рухи кризис аеруча борчый. Бу өлкәдә без элек ирешелгәннәрне дә югалттык. Шәхес деградациясе, халык деградациясе тирәнәя бара. Фаҗига бит: наркомания, эчкечелек, җинаять, бозыклык чәчәк ата. Яшьләрне тәрбияләүдә өзеклек килеп чыкты. Совет заманындагы тәрбия системасын кире кактык, ә яңасын тудыра алмадык.

Спортны гына алыйк. Ул массовыйлыгын югалтты. Мәктәпләрдә спорт заллары кызганыч хәлдә. Ә бит чит илләрдә спортка зур игътибар бирәләр. Сәламәт тәндә - сәламәт акыл, дип юкка гына әйтмәгәннәр.

Әхлакый, эстетик тәрбиядәге бушлык турында сөйләгән дә юк. Дискотекадан башка нәрсә бар соң? Кыскасы, рухи фәкыйрьлек.

Мин депутат чагымда да Югары Совет утырышларында халыкны, бигрәк тә яшьләрне тәрбияләү проблемалары турында чаң кагып чыгышлар ясадым. Тәрбия буенча дәүләт программасын төзеп кабул итәргә тәкъдим керттем. Әмма ул үтмәде.

- Революцион фикерле педагоглар һәм психологлар кешене тәрбияләргә кирәкми, ул үзтәрбия белән шөгыльләнсен өчен шартлар гына тудырасы, дип раслыйлар, ә Сез дәүләт программасы турында сүз алып барасыз...

- Илгә, дәүләткә каршы кешеләр генә шулай әйтергә мөмкиннәр. Демагоглар, җинаятьчеләр алар. Тәрбия эше ничек кенә кирәк әле!

Без педагогика университетында нәкъ менә тәрбия эшен үзәккә куябыз. Ул күптөрле чараларны үз эченә ала: студентларны үзешчән сәнгатькә тартабыз, КВНнар, каз өмәләре һ.б. үткәрәбез. Алар вакытны кызыклы итеп уздыру өчен генә түгел, ә яшьләрдә матурлык хисе, әхлаклылык тәрбияләүгә хезмәт итә.

Әмма мин әле үзебездә тәрбия эшенең куелышыннан канәгать түгел. Мәсәлән, мин яшьләрнең өлкәннәр белән еш аралашуын теләр идем. Чит илләрдә укытучы белән укучы арасында якынлык бар. Профессор студент белән чәй эчә, фикер алыша, ана тәҗрибәсен бирә, тик имтиханнар вакытында аның башыннан сыйпамый. Бездә менә шундый аралашу житми.

- Тәрбия эшенең нигезендә нинди идеология ятарга тиеш соң? Бүгенге демократия идеологлары: дәүләттә идеология булырга тиеш түгел, диләр бит.

- Идеологиясез дәүләт була алмый. Тәрбия нигезендә гуманизм, кешелеклелек идеологиясе ятарга тиеш.

* * *

Әлбәттә, Рүзәл Абдуллаҗан улы Юсупов белән әңгәмә корганда күп нәрсәләргә җавап алырга мөмкин. Аның проблемаларга үз карашы, үз фикере бар. Без киләчәктә Рүзәл әфәнде белән журнал битләрендә очрашырбыз әле. Ә хәзергә аны юбилее белән ихлас күңелдән котлыйбыз, ана күпьяклы эшчәнлегендә бәрәкәтле уңышлар телибез.

Эдвард ХӘКИМОВ һәм Солтан ИСХАКОВ фотолары.

Государственная телерадиовещательная компания “Татарстан”

Рекламно-информационный центр радио “Радио Татарстана” вещает на татарском и русском языках.

ТРТ

Нас слушают более **30** миллионов человек, жители республик Татарстан, Башкортостан, Марий Эл, Чувашия, Мордовия, Удмуртия, областей – Нижегородской, Самарской, Ульяновской, Кировской, Пермской и других.

- ИЗГОТОВЛЕНИЕ И ТРАНСЛЯЦИЯ РЕКЛАМЫ, ЗАКАЗНЫХ РАДИОПРОГРАММ, РАДИОФИЛЬМОВ, ОБЪЯВЛЕНИЙ
- МУЗЫКАЛЬНЫЕ ПОЗДРАВЛЕНИЯ “Бүләккә җыр”
- ПЕРЕЗАПИСЬ МУЗЫКАЛЬНЫХ ФОНОГРАММ ИЗ ФОНДА РАДИО
- СОБОЛЕЗНОВАНИЯ

Радио Татарстана принадлежит эксклюзивное право на размещение рекламы на ТВ и РАДИО в Башкортостане, Нижнем Новгороде, Коми и других регионах Поволжья и Урала.

420015, Казань, ул. Максима Горького, 15. Тел./факс 38-52-08.

"КАЗАХСТАН" - ТАТАРСТАНДА

Сәгыйть ЖАКСЫБАЕВ,
"Казахстан" оешмасы рәисе.

Татарстан җөмһүриятенең милли-мәдәни оешмалары берләгенә кергән иң олы җәмгыятьләрнең берсе - "Казахстан" оешмасы. Ул 1991 елда Казан югары уку йортларында укыган казах студентлары җирлегендә оешты. Хәзер аңа Казанда даими яшәүче казахлар да керә. Алар арасында ортопедия һәм травматология институты профессоры Газиз Неттов, КДУ доценты Равил Имангалиев, ветеринария академиясе деканы урынбасары Орзали Муллакаев, техник университетның фәнни хезмәткәре Манарбек Тлеулинов, шул ук университетның өченче тулай торак коменданты Бахытжан Сейткулов һәм башкалар бар. Җәмгыять шуларның актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә яши.

Җәмгыятьнең төп максаты - Татарстанда яшәүче казахларның этник, тел һәм мәдәни үзенчәлекләрен саклап калу һәм үстерү.

"Казахстан" җәмгыяте казах халкына якын булган башка милләт вәкилләре белән дә аралаша. Күп кенә казах галимнәре һәм җәмәгать эшлеклеләре Казанда укый. Казан университетын тәмамлаган Мөхәммәтҗан Кадабаев беренче казах календарен эшли. Шул ук университетны тәмамлаган Әхмәт Беремжанов 1917 елга кадәр ике мәртәбә Россия Думасына сайлана. Казан укытучылар семинариясен тәмамлаган Сентпазы Мендешев Казахстанның беренче хөкүмәт җитәкчесе була. 1917 елга кадәр уку йортларын тәмамлаган казахларның эшчәнлеген ачыклау белән җәмгыятьнең мәрхүм әгъзасы Батыржан Кенжетаев шөгыльләнде. Аның тарафыннан 82 казахның исеме ачыкланды.

Бер үк вакытта Казахстанда иҗат иткән татар язучыларының да исемнәре торгызыла. Алар арасында Латыйф Хәмиди, Рәшит Абдуллин, Фоат Мансуров бар. Габдулла Тукай да үзенең иҗат эшчәнлеген Казахстанда башлаган.

"Казахстан" җәмгыяте ике республика арасындагы мөнәсәбәтләрне үстерү һәм ныгыту юнәлешендә дә эшли. Казахларның 1989 елда үткәрелгән I Бөтендөнья корылтаенда Татарстан Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов җитәкчелегендәге делегация дә катнашты. Ике академия арасында махсус килешү төзелде. 1994 елда Алматы шәһәрендә Татарстан хәрби предприятиеләренең продукциясен сату күргәзмәсе булды.

1995 елда Татарстан Фәннәр академиясе белән берлектә бөек казах шагыйре Абай Кунабаевның 150 еллыгына багышланган фәнни-практик конференция үткәрелде. Шул ук елның августында Абай юбилеенда Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев җитәкләгән хөкүмәт делегациясе составында, "Казахстан" оешмасы җитәкчесе буларак, миңа да катнашырга туры килде. 1997 елның августында Президент М. Шәймиев җитәкчелегендә Казахстанга рәсми визит ясаган делегация составында да бар идем, Татарстан делегациясе составында Казахстанның яңа мәркәзе итеп Астананы игълан итү вакыйгаларында катнаштым. Болар барысы да ике республика арасындагы бәйләнешләрдә "Казахстан" җәмгыятенең уңай эшчәнлеге турында сөйли. Шушы елның май-июнь айларында төрки халыкларның Казанда үткәрелгән VI театр фестивалендә Габит Мусрепов исемендәге балалар һәм яшүсмерләр театрының уңышлы чыгышы да Татарстан казахларының мәдәни тормышына яңа этәргеч бирде.

Шагыйрь Серик Тургынбеков Казанга, Татарстанга һәм татарларга үзенең җылы хисләрен белдерде.

"Казахстан" җәмгыяте үзенең эшчәнлеген студентлар һәм хәрби училище курсантлары арасында да алып бара. Җәмгыять шулай ук Казахстаннан килгән студентларга мөмкин кадәр матди һәм рухи ярдәм күрсәтә.

Шушы елның 29 июнендә "Казахстан" җәмгыяте вакытсыз дөньядан киткән яшь галим Батыржан Кенжетаевның "XIX гасыр уртасы - XX гасыр башында казах язучыларын формалаштыруда Казан уку йортларының роле" исемле китабын тәкъдир итү кичәсен оештырды. Татарстанның Милли китапханәсендә үткәрелгән бу кичәдә киң җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

"Казахстан" оешмасы Татарстан һәм Казахстан халыклары арасында мәдәни һәм икътисадый хезмәттәшлекне урнаштыруда мөмкин кадәр үз өлешен кертә.

РӘСЕМНӘРДӘ:
"Казахстан" оешмасы рәисе С. Жаксыбаев (сулда) Кыргызстан вәкилләре белән; артиллерия училищесында укучы якташлары янында кунакта.

Нурсөя АЙТУГАН,
әдәбият-сәнгать бүлеге мөхәррире.



70 яшь

Әлеге портретны юбилярга Минтимер Шәймиев бүләк итте. Икенче ягында — Президентның Мәңгелек Указы: "Кем дә кем бу сурәттәге мөлаем, хәйләкәр һәм шаян Әлмәндәрдән җитди Шәүкәт Биктимерне аера ала, шул кешегә теләгән кадәр премия бирелә".

Шәүкәт–Әлмәндәр көлемсери: "Йә, тырышып карагыз..."

Саный китсәң, Шәүкәт ага Биктимеровның мактаулы исемнәре шактый: Татарстанның, Россиянең, Советлар Союзының халык артисты, Тукай премиясе лауреаты һ. б. Әмма хикмәт монда түгел. Чөнки Шәүкәт Биктимеров - дөньяда адәм баласы ирешә алырдай иң югары исем иясе: халык артисты. Ягъни халыкның үз канаты. Халык аңа мөкиббән китеп, горурланып, аны хөрмәт итеп кенә калмый, ул Шәүкәт Биктимеровны ихлас ярата. Искиткеч таланты, камил рольләре өчен генә түгел, серләрен чишәрлек, кайгы-шатлыкларын сөйләрлек газиз кешесе дип үз итә. Сөйкемлелегенә, шуклыгына, ярым хәйләкәр, ярым җитди, очкынлы, шаян күз карашына сокланып елмая. 70 яшьтә дә егетләр солтаны! Шәүкәт ага сәхнәдә эчтән балкый, аның карашыннан тирә-юньгә нур бөркелә. Дөньяда нинди дер тотрыклылык бар икән, ул Шәүкәт ага Биктимеров һәм аның иҗатыдыр, мөгаен. Әлмәндәр карт нәрсә ди әле? "Кеше мине күргәч елмая икән, димәк, мин бу дөньяга кирәк". Шәүкәт Биктимер дә шулай ди. Ул сөйләгәнне тыңлау - үзе бер рәхәт.

Егетләр СОЛТАНЫ

... Яраткан рольләр турында еш кызыксыналар. Мин рольләремнең тамашачылар яратканын, халык теленә кергәннәрен яратам. Әйтик, "Беренче мәхәббәт"тәге - Тәлгать, "Баһадирлар"дагы - Ленин, "Зәңгәр шәл"дәге - ишан, "Әлдермештән Әлмәндәр"дәге - Әлмәндәр...

... Тәлгать образы миңа зур популярлык алып килде. Хәер, ул спектакль Хәй Вахитны да оста драматург итеп, ул вакытта әле студент Наилә Гәрәеваны да талантлы артистка итеп танытты. Миңа 30 яшь иде, 17 яшьлек Тәлгатьне уйныйм. Әй, тудырган бит Ходай: чәчем җирән, ут шикелле янып тора, битем сипкелле. Оялам инде. Тырыша-тырыша грим салам, кара төсле парик киям. Җүләр булганмын, рольне чәч уйныймыни инде? Бик ераттылар ул рольне, урамда да "Тәлгать" дип кенә дәшә башладылар. Гастрольләр вакытында, спектакльләрдән соң яшь кызлар көтеп торалар. Мин инде гаиләле кеше, уңайсыз. Җирән чәч белән чыгам да тиз-тиз узып китәм. Гаҗәпләнеп карап кала кызлар; "Кит әле, син Тәлгать түгел ич", - диләр. Кайбер карчыклар әле хәзер дә, туктатып: "Картайгансың икән, Тәлгатьне уйнаганда мин сиңа гашыйк идем", - дигән булалар. Мондый хәлләр һәр артистның да тормышында очрап тора инде ул.

... *Ленин* ролен кем уйнарга тиешлеген ул заманнарда КПСС Үзәк Комитеты хәл итә иде. Мәскәүгә үк бардык. *Ленинны* уйнарга теләүчеләр бик күп, барыбызны да бер кунакханәгә урнаштырдылар. "Йа, Алла, *Ленин* белән дөнья тулган икән!" - дим. Ул вакытта *Ленин* ролендә йөргән Штраух, Каюров кебек мәшһүр артистларның грим остасы көзге каршына утыртып 2-3 сәгать буе грим салды, фотога төшерделәр. Сайлау катгый төстә бара. Биографияңне, көндәлек тормыштагы тәртибеңне, интеллект дәрәҗәсен генә түгел, костюм, ботинкаларга кадәр тикшерәләр. Тавышны тыңлап карыйлар. Кыскасы, энә күзеннән үткәрәләр. Күп театрларга *Ленинны* уйнарга рөхсәт бирмәделәр. Мине Сатира театры сәхнәсендә уйнатып карадылар. Бу - зур вакыйга иде. Үзәк Комитеттан вәкилләр килеп утырды. Спектакль тәмамланды, тамашачыларга баш идек, пәрдә ябылды. Шуннан мине ЦК вәкиле чакырып алды да: "Сезгә бернинди дә дәгъвабыз юк, ләкин Сез спектакль беткәч башкалар белән бергә баш ияргә тиеш түгелсез. Чөнки бөек *Ленин* беркайчан да, беркем алдында да баш имәгән!" - диде. Соңыннан үзем дә уйладым: гомумән, артистка кат-кат баш ию кирәк микән? Уйнап чыккансың икән, кул чабаларны, чапмыйлармы - елмаеп басып тик тор. Шуннан бирле, менә 30 ел инде, сәхнәгә, халык алдына чыгып, җиңелчә баш кагып куярга гына гадәтләндем. *Ленин* роле минем өчен зур сынау булды ул. ЦК комиссиясе безнең театрга да килде. Н. Погодин әсәре буенча куелган "Баһадирлар" спектакленең премьерасы хәзер дә исемдә. Иң башта әле *Ленин* үзе күренми, тавышы гына ишетелә. Ә халык шул мизгелдән үк дәррәү кубып кул чаба башлады. Мин торам сәхнә артында калтыранып: "Эх, алдан ук

Татарстан Президенты Шәүкәт аганың 70 яшьлек юбилеенда.

кул чабып карап италәр инде", - дим. Халык бит тере Ленинны көтә. Килеп чыгуым булды - алкышлар көчәйде, халык торып басты. Шунда гына җинел сулап куйдым. Халык чын-чынлап кабул иткән булып чыкты. Ул елларны урамда, яныма килеп: "Владимир Ильич, син - әйбәт кеше, пролетариатны яклаучы, тәмәке бир әле", - дип бәйләнүче сукбайлар еш очрап торды. Акча сораучылар да булды - Ленин бит юмарт булган. Хәзер Ленинны тиргәсәләр дә, мин ул ролемнән баш тартырга җыенмыйм...

... Әлмәндәр карт булуыма инде 22 ел. Шул вакыт эчендә 400 ләп тапкыр уйнаганмындыр бу спектакльдә. Ләкин мин аннан үзем дә туймадым, тамашачылардан да андый сүз ишетмәдем. Гаҗәп бит: бишәр, унар тапкыр караучылар бар икән. Әлмәндәрне мин көн саен башка төрле итеп уйныйм. Театр артистының бәхете дә шунда: кәефкә карап, импровизация ясарга, көтелмәгән үзенчәлекләрен китереп чыгарырга мөмкин. Нәрсә уйныйсымны беләм мин, әмма ничек уйныйсымны һич тә алдан әйтмим. Сәхнәгә кергәч - минем биләмә, анда мин патша. Мәтәлчек тә атынам, биим дә, сикерәм дә, биш минутлык күренешне ун минут уйныйм. "Шәүкәт уйнаса, спектакль ярты сәгатькә соң бетә", - дигән даным да таралган инде театрда. Бу махсус сүзу түгел, уйный башлыйсың, үен дәрте шулкадәр алып кереп китә ки, көтелмәгән детальләр берсе артыннан берсе чыгып кына тора. Шулкадәр тәмләп уйныйсың, халык та көлә, үзең дә ләззәтләнәсең. Бу яктан Равил дә оста, фортельләр җибәрергә ярата. Ирек белән Нәҗибә дә кушылып китәләр. Нәтиҗәдә - куелган саен бу спектакль яна төсмерләрен ача. Тамашачы үзе дә бертөрле генә түгел ләбаса. "Әлдермештән Әлмәндәр"не берәүләр монсу комедия, икенчеләр - комедия, өченчеләр - драма итеп карый. Кайберәүләр пәрдә ачылу белән көлә башлый, кул чаба. Кемнәрдер тып-тын гына елап утыра... Гел бертөрле генә уйнасак, әлеге спектакль 22 ел яши алмас иде. Хәзер исемемне дә оныттылар бугай инде, урамда: "Бабай, исәнме!" - дип кенә дәшәләр. Әле күптән түгел генә базарга чыккан идем. Анда әйбер сатучы хатын-кызларның күбесе татар икән ләбаса. "Әлмәндәр бабай, бирегә кил, ни алырга телисең?" - дип төрле яктан чакырып торалар. Базардан чыгып кына китә алмыйм бит, әй. Чаллыдан кайтканда тукталган идек, пәрәмәч сатучы хатын-кызлар, самавырларын, чиләкләрен, сумкаларын күтәреп йөгереп килеп урап алмасыннармы! "Әлмәндәр бабай, бер чынаяк чәемне генә эч әле, пәрәмәчне генә кабып карасана", - диләр. "Акчам юк әле", - дигән булам, котылырга теләп. "Акчага түгел, болай гына, үз итеп кенә", - диләр. "Хөрмәтегезгә рәхмәт, башка вакытта, махсус, иркенләп килермен", - дигәч кенә бераз тынычландылар...

... Заман үзгәрүнең иҗатыма әллә ни тәэсирен сизмәдем. Иҗат кешесе иҗаттан туймый, аңа һәрвакыт эш кирәк. Мин бервакытта да эшсез калмадым, рольләр мәсьәләсендә каршылыклар очрамады. Мин театрыма рәхмәтле: илле ел буена "Уйна гына, рәхим ит", - дип тордылар. Әдәбиятны, сәнгатьне белгән, театр яраткан Президентыбыз булуына да сөенәм. Минтимер Шәрипович театрның иң өлкән артистыннан башлап иң яшенә кадәр исемнәрен белә, спектакльләрне карап барырга вакыт таба. Хөкүмәтебез дә театрга ярдәм итә. Бу яктан бәхетебез бар. Ә менә сәяси климат алышыну, тотрыксызлык нык тәэсир итте. Мәсәлән, 60 яшь тулгач, СССР исән чакта, миңа союз пенсиясе билгеләгәннәр иде. Инде бик күп эшләмичә дә яшәп булыр кебек иде. Заман үзгәрде, СССР таркалды, пенсия дә килми башлады. Яңадан пенсия юлларга туры килде. Халык артисты дигән бернинди исемнәрегез дә кирәкми, бары тик эш стажы һәм эш хакы турында белешмәләр генә китерегез, диделәр. Һәм... 300 сум пенсия билгеләделәр. Илле еллык хезмәтемнең шундый нәтиҗәсен бик авыр кичердем. Театрда әлегәчә ныклап эшләргә тырышуымның рухи ягы да һәм әнә шундый матди ягы да бар. Чираттагы яңа ролем - Король Лир...

... Тамашачы гаҗәп бит ул. Безнең халык табигате буенча театр ярата. Тамашачылар синең белән бергә уйный, шатлана, борчыла - сәхнәдән болар ачык күренә. Заманалар үзгәргән саен, әлбәттә, тамашачы да үзгәрә. Мәсәлән, элек халык кул чабарга да ояла иде, абыстайлар килсә, кул чапмый гына, елмаеп кына карап утырырлар иде. Хәзер соклануын яшерми тамашачы, кул чабып кына калмый, сызгырып җибәрә, "афәрин" кычкыра. Мин моны табигый хәл дип анлыйм. Адәм баласының хисләрен чикләргә кирәкми. Тамашачы актуаль проблемаларга бик сизгер. Әлмәндәр әйтә бит әле: "Дөньясы бик рәтләнде бит, яшисе килә, үләсе килми", - ди. Пьеса бит кайчан язылган! Тамашачы бүген уйлап куя инде: "Кая рәтләнсен ди?" Шуңа күрә, бераз үзгәртеп: "Менә радио-телевизордан көн саен, дөнья рәтләнер, дип әйтәләр, әзрәк яшисе иде әле, күрәсе иде рәтләнгәнен", - дип кечкенә генә монолог сөйләргә туры килә. Безнең тамашачы иманлы, чит йогынтыларга бирешми. Чөнки Алласы бар, мәчете бар, теле бар, театры бар.

Солтан ИСХАКОВ, Михаил КОЗЛОВСКИЙ һәм архив фотолары.

Карпенко–Карий. "Мартын Боруля". Төп рольләрдә - Шәүкәт Биктимеров һәм Вера Минкина. 1954 ел.



Н.Погодин. "Баһадирлар". Шәүкәт Биктимеров В.И.Ленин ролендә. 1970 ел.



Ак яулыгым кебек ак калдым

(Гомер монологы)

Бик күпләр миннән: "Болай яшь булуыгызның сере нәрсәдә соң?" - дип сорыйлар. Ә мин аларга гел: "Сабыр булуда, кеше булуда", - дип җавап бирәм. Шуңа шатланып бетә алмыйм: сабырлык белән, кеше булып кичкәнмен икән бит 80 еллык гомеремне! Шуның 65 елы иҗат белән үткән икән.

Һай, син гомер! Әле яңа гына мин - керәшен авылында туып-үскән бөтерчек бер кызый театр техникумында укып йөри идем бит. "Буең кечкенә, үсеп кил! - диюләренә: "Мин әле үсәчәкмен, зур булып үсәчәкмен!" - дип җаваплаганым хәтеремдә. Аннары инде республика күчмә театрында, зур шәхесләр арасында кайнап яшәүләр. Беренче рольләр, беренче алкышлар. Яшь драматург Риза Ишморатның миңа атап диярлек язган "Гөлзада"сы. Яшь героиня Гөлзада - Верага гашыйк булып төн йокыларын җуйганнарның исәбе-хисабы булмагандыр. Ә мин Әсгатемә, ул вакытта минем буем җитмәс булып күренгән режиссерыбыз Әсгать абый Мәҗитовка гашыйк идем шул. Ләкин, Алла сакласын, аны-моны сиздерү юк, аның кесәмә салган мәхәббәт хатларына җавап язу да юк - очрашмаска тырышып, качып йөргәнем генә истә. Ә ул газап чигеп йөрде-йөрде дә, сабырлыгын җуеп, беркөнне кич туп-туры өебезгә килеп керде. Әниемнең фатихасын алырга... "Кечкенәм, әйдә, җыен, мин сине алып китәргә килдем", - диде. Һәм ул мине гомере буе кадерләп-иркәләп "Кечкенәм" дип йөрде.

Ходай безгә туп-тулы 10 ел бәхет биргән икән... Марселебез, Диләрәбез туды. Туп-туп итеп тәпи басып йөргәннәрен, "әттә" дип дәшүләрен генә ишетергә насыйп булды аңа. Мин авыру әнием, ике сеңелем, берсеннән-берсе кечкенә ике бала белән 28 яшемдә тол калдым.

Һай ул көннәрнең авырлыгы! Сугыш еллары, ачлык, ялангачлык. Әмма театр! Театр һәммәсен дә оныттыра иде. Кышкы бураннарда авылдан-авылга үгез җигеп, ә кайчакта җәяүләп тә дистәләрчә километр юл уза идек. Ягылмаган, салкын клуб сәхнәләренә аяк басуга җылы сүзгә, юатуга мохтаҗ тамашачыны күреп, юл газапларыбыз да онытыла, бары аларга кирәклегебезне тою хисе генә кала иде.

Гомерләр - аккан су кебек... Тыныч елларны, матур көннәрне дә күрергә насыйп булды. Авыр тормышлар үткәреп, балаларымны да аякка бастырдым. Шөкер, тыңлаучан, акыллы булдылар, тырышып укыдылар. Икесе дә югары белем алып, хөрмәтле кешеләр булдылар, әтиләре исеменә тап төшермәделәр.

Кызык икән үз-үзеңә читтән карап тору: 15 яшеннән сәхнәгә аяк баскан кечкенә Вера да үсте, зурайды, даны-

Вера МИНКИНА,
Татарстанның һәм РСФСРның халык артисткасы

шөһрәте артты. Әмма тамашачы мәхәббәтен яулап, зур исемнәр алса да, борынын чөймәде, гади, эчкерсез булып кала белде. Мин аны шуның өчен яратам да бугай. Әйе, күктән йолдыз чүпләмәгәне, югына уфтанмыйча, барына канәгать булганга күрә ошый бугай ул миңа. Кучмә театрдан Камал театрына күчкәч тә ул эреләнмәде, рольне кечкенәсенә, зурына бүлмичә, бөтен ихласы белән уйнады да уйнады. Ул уйнаган рольләрне бер сулышта гына санап та чыга алмассың! Ничәмә-ничә холык, нинди амплуа! Кәрим Тинчуринның "Зәңгәр шәл"ндәге малайдан алып дисталәгән карчык роленә кадәр! Алар арасында кемнәр генә юк: печән өшкертүче карчык ("Зәңгәр шәл"), Галимәбану ("Галиябану"), Гөлнур әби ("Сүнгән йолдызлар"), Шәмси әби ("Казан сөлгесе"), Рәхимә әби ("Бәхетлеме син?"), Чикерткә Гыйльменисасы ("Чаткылар"), Хәмдебану ("Моңлы бер җыр")... Әле болары искә төшкәннәр генә. Ә башка характерлы рольләр? "Хәерле юл"да - Абыз Чичи, "Зифа"да - Кәләмзә, "Баһадирлар"да - Мария Ильинична Ульянова, "Үз кешеләр - килешербез"дә - Устинья Наумовна, "Хуҗа Насретдин"да - Хуҗа хатыны, "Моңлы бер җыр"да - Мусаның энисе, "Гөргери кияүләре"ндә - Палый түтәй... Санап китсәң - шактый җыела икән бер гомергә. "Кечкенә дә - төш кенә шул!" дип мактап та куям үземне!

Юк, сәхнәдә дә, тормышта да кунел кайтарырлык, кеше рәнҗетерлек гамәлләр кылмаганмын икән, Ходаема мең шөкер! Хак Тәгаләм каршында минем бер гаебем дә юктыр, дим. Мин бит бары тик ана гына, аның көченә генә ышанам. 6 ел элек мәчеткә йөреп, мөселман диненә дә күчтем. Күнелем белән, бөтен йөрәгем белән мөселман булып яшәгәнгәдер, Ходай каршысында да бурычлы булып калмыйм, дидем. Мәрҗани мәчетенә бардым: "Мине мөселман диненә кабул кылыгыз", - дидем. "Сез хәзер безнең җирдәге йолдызыбыз - Венера булырсыз, Вера ханым", - диде миңа хәзрәт, кулымны кысып. Үзем шушы гамәлне кылып мәчет ишек алдына чыктым, үзем очам, канатланам, кая басканымны белмим. Җаным, кальбем чеп-чиста! Керәшеннәрем, кичерегез мине, дим, 12 яшеннән авылдан чыгып киткән "Чибәр Егор" кызы беркайчан керәшен генә булалмады, аның җаны һәрчак мөселманлыкка тартылды, дим. Хәер, Ходаем кичерер, ул бит безнең барыбызга да берәү генә, дим.

80 ел гомер... Аз да сыман, бик күп тә сыман. Уйлап карасаң, әле яшәлмәгән дә кебек... Күнел аша вакыт ага, чор ага... Һәр чорның үзенә күрә ачышы, яңалыгы, матурлыгы бар. Гел матурлыкны күреп, шул матурлыкка омтылып яшәгәнгәме - замана авырлыклары, аның тискәре, кара яклары калмаган да кебек күңелдә, бары яктылык, чисталык кына калган. Бәлкем, шулар йөземдә чагылганга картаймыймдыр, яшәрә генә барамдыр. Юкса, зарланган кешегә зарланырлык икән лабаса! Татарстанның, РСФСРның халык артисткасы 440 сум пенсия ала. Шул сумманы фатирга, телефонга, газга, утка түләргә кирәк. Кеше арасында йөргәч, адәм рәтле киенәсе дә килә. Без дә адәм баласы, фәрештә түгел - теш пастасы да, порошогы, сабыны да кирәк. Ашарга калмый да диган сүз бу. Ярый балалар бар, алар булыша. Алар да пенсионер бит инде! Шөкер, "Инсаният"ебез бар. Кайсыбызга 80, кайсыбызга 70, ин яшебезгә 60 булган артистлар авылларга чыгабыз, Казан тамашачысын сөендерәбез. Үзебез дә рухи көч алып, яшәреп китәбез. Бер спектаклебезгә 50-60 сум акча түлиләр, иш янына куш - ярап куя. Пенсиягә генә яшәп булмый хәзерге заманда. Аллаһы Тәгаләм рәхмәтле, ул мине ташламый: тирә-юнемдә гел яхшы кешеләр генә минем. Дусларым да бик күп. Театрымда да яраталар. "Безнең Вера апабыз", дип кенә торалар. Безнең кебек дус коллектив кайда бар икән ул? Рәхмәт миһербанлы, игелекле директорыбыз Шамил Закировка. Ул барысын бергә туплап, бер гаилә итеп яшәтә белә.

Артист ул - барометр кебек бит. Илдәге үзгәрешләр дә, халыкның кәефе дә беренче чиратта аның җанына кагыла. Әмма ул һәрвакыт ачлыгына-ялангачлыгына, сугышына карамастан, халкының рухын күтәрерлек көчләр тапкан, өмет дигән учагын беркайчан да сүндермәгән. Камаллар заманыннан алып бүгенгәчә шулай булган ул. Мин үзем беркайчан да өметсезлеккә бирелмәдем. Алдагы көнемә куркып карамадым, кем белә бит - алдагысы, бәлки, без көткәннән дә яхшырак булыр!

"Гомерләр уза икән ул..." Авыз эченнән шулай дип көйлим дә, "Тфу-тфу, әстәгъфирулла!" дип, "Колһуалла"ларымны укырга тотынам. Фани дөнья фани килеш калыр, ахирәтне дә онытмыйк, дим. "Әлдермештән Әлмәндәр"дәге Хәмдебануым кебек матур яшәдем, шөкер, ак яулыгым кебек ак калдым, дим.

Һәммәбезгә дә шулай ак калырга язсын иде, дип намаз сәен ак теләкләр телим мин сезгә...

Солтан ИСХАКОВ һәм архив фотолары.

Яшь рухлы АКСАКАЛ

Миңа моннан ике ел элек шагыйрьнең зур чәчмә әсәрен - “Минем беренче гомерем” исемле, үзе атаганча - “хистәлек”ләрен редакцияләргә туры килгән иде. Инде бу әсәр китап булып та чыкты, укучыга киң таралды, дия алам. Аерым өлешләре могътәбәр “Татарстан” журналында да дөнья күргән иде (тулысы белән ул “Казан утлары”нда басылды). Менә шушы әсәре белән шагыйрь Шәүкәт Гали әдәбият сөючеләр алдында янә бер кат “ачылды”. Әйе, әйе, шигырьләрендә, поэмаларында инде без очраткан Бакырчы авылы, Кайбыч урманнары, Апас, Тау ягы һ. б. атамалары күңелләргә күптән үз иде, якын иде. Инде шагыйрьнең нәсел-нәсәбен, шәҗәрәсен дә күздән кичердек, үй белән татар халкының күпне кичергән бер төбәгенә барып кайттык. Шулай, шигырь өчен, иң әүвәл, нигез кирәк, ныклы зәмин, изге туфрак булу кирәк! Үз төбәгенең җаны күчү кирәк шагыйрьгә. Менә шуңа күрә дә, әсәрне укыгач, Шәүкәт Гали холкы, акылы, сабырлыгы һәм үзенә генә хас тапкырлыгы, шаянлыгы һәм, әлбәттә инде, хәйләкәрлеге, һичкайчан да югалырга ирек бирмәс крестьян тәҗрибәсе, үҗәтлеге - болар бар да янача, шигъри булып ачыла кебек.

Татарстанның халык шагыйре, республиканың Г. Тукай премиясе лауреаты, Г.-Х. Андерсен исемендәге халыкара Почетлы диплом иясе, шуңа өстәп әле Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге бүләгенә дә лаек булган Шәүкәт Гали - бүгенге әдәбиятыбызның күренекле вәкиле. Дәреслекләр аша бар татар дөньясына таныш балалар шагыйре. Менә дигән лирик. Кырык елга якын инде мин аның “Сиңа әйтер сүзем бар” исемле китабына кергән шигырьләрен яттан сөйлим... Шигырьләрнең күбесе җырга да әверелгән инде: “Сөенечкә, дисәм”, “Утыр әле яннарыма”, “Тамчылар тамар чаклар”, “Раушаниям, бәгырем” һ. б. Кайсыбыз гына белми аларны!.. Юморһөҗүдәге шиксез, зур уңышлары. Янә хикмәтле сүзләр, шигъри афоризмнар...

Исәннәрнең кадерен бел,
Үлгәннәрнең каберен бел!

Шуның өстенә бик күп еллар яшьләр белән эшләү, секция җитәкчесе булу, Язучылар берлегенә кабул итү коллегиясе рәисе вазыйфасы һ. б. Остазлык, балалар әдәбияты, шигърият, милли дөньябыз өчен янып яшәү. Шәкертләреннән Роберт Миңнуллинны гына атау да җитәдер. Быел июль аенда шагыйрьнең туган ягына бардык. Шунда Яркәйдә һәм Шәммәт авылында узган зур тантанада остазның янып, дулкынланып, сөенеп йөрүенә бу бәйрәмнәрдә бергә булган бер журналист та игътибар иткән иде. Әдәбият, сәнгать кешеләренә аеруча игътибарлы бу журналист Шәүкәт аганың хәрәкәтчән, житез, яшьләрчә төз гәүдәсенә карап та һәм акыллы, олпат сүзләрен тыңлап та шуны кабатлаган иде:

- Нинди яшь күренә бу аксакал! Нинди егәр, көч, дәрт әле анда... Милләт, халык көче турында сөйли ләбаса бу!

Шәүкәт Галигә 70 яшь тулган көннәрдә мин моны һаман-һаман искә төшерәм. Бик хаклы сүзләр бу!

Без дә шулай - Шигырьнең, Моңның, Рухның үзе кебек, мәңге яшь була алсак иде!

Рәдиф ГАТАШ.

Шәүкәт ГАЛИЕВ

КҮҢЕЛ ТҮРЕ

Өй түренә куйган шәмаилнең
Сүзләре ак-көмеш хәрефле,
Гел иминлек кенә теләгән ул,
Бусагадан куган хәвефне.

Җанга тынычлыклар биреп торган
Гасырлардан килгән инану.
Язулары безгә бикле иде,
Соң төшендем бугай мин аны...

Диварларга иңгән язуларын
Үзгәртүчән булды шул гасыр...
...Очраттым бер авыл өендә мин
Гомер бакый төшмәс догасын:

“Туган тел”е иде ул Тукайның -
Яшәү таныклыгы халкымның,
Чәй көмеше белән бизәлсә дә,
Һәрбер сүзе тере алтынлы.

Яңа чорлар килә, берәм-берәм
Кыйбласына кайта киткәннәр.
Кан тартканнар, әнә җан тартканнар
Тукай җырын Гимн иткәннәр.

Шәмаилдә - телем-иманым ул,
Бабайлардан килгән әманәт,
Ул иминдә нәслем-халкым исән,
Ул сау чакта рухым сәламәт.

Ил-йортка ул бәхет теләп тора.
Атын җуйган дага булмасын -
Канатлы ир-йөрәкләре белән
Дөлделләре җирне урасын.

...Күңел түрендәге атам-бабам,
Борчулы рух инде шат сыман.
Тыныч булырмынмы - шәмаилне
Мин дә варисларга тапшырам...

ГОМЕР КОЯШЫ

I.

Таңнан торып, кырга чыгып,
Без дә җир сөргән идек,
Көн бигрәк әкрен үтә, дип,
Зарыгып йөргән идек.

Сәгатебез - кояш иде,
Түзмибез, гел карыйбыз,
Ач күләгә озынлыгын
Чабаталап саныйбыз.

Ишәккә атланган кояш -
Хәрәкәте шул чама.
Төштән соң куянга күчә -
Куян ул яхшы чаба!

II.

Әкрен генә еллар үтте,
Тырышып гомер иттек,
Ишәктәй җигелеп без дә
Төшлеккә кояш илттек.

Уф, дидек, җиңел булмады
Йөкләре замананың,
Хәвеф арты хәвефләре
Табыла һаман аның.

Безнең хәрәкәтләр инде
Салмаграк шул, бер чама,
Ә менә гомер куяшы
Куянны узып чаба.
Чаба - шәфәкъка таба...



ТУГАННАРЫМНЫ БАРЛЫЙМ ЯҢА ЕЛДА

Урманнарда чыршы мәңге яшел,
Ылысларын кайчан коядыр?
Югалтуның сары сагышларын
Сызланганнар гына тоядыр.

Туганнарны барлыйм Яңа елда,
Күңелемдә газиз исемнәр:
Аларның да шушы чыршылардай
Яшәүләре яшьли киселгән.

Чыршыларда шәмнәр генә янмый,
Үткән гомеркәйләр яна ул:
Йөзләренә карап сөенергә
Якыннарым юк бит, Яңа ел...

Түребездә балкып торган чыршы
Үткән шатлыкларын коясы,
Яңа елны каршылаган саен
Аерылуны күбрәк тоясын.

...Ә бит еллар - гасыр оныклары,
Ерак офыкларны күрәчәк -
Нәсел чыршысының тирәсендә
Әйлән-бәйлән уйнар киләчәк.

ИСКЕ РӘСЕМ

Мәсгуткә

Петербурда төшкән иске рәсем...
Алтмыш биш ел узган ул көннән;
Гасыр азагына килеп җиттен,
Дәвам булып шушы төркемнән.

Казанны да алдык бергәләшеп -
Үрчемле ул Гали нәселе.
Киләчәккә карап торсын әле
Безнең туганнарның рәсеме.

Үлемсезлек гади нәрсә бит ул:
Буын арты буын яралып,
Яшәреп тә, һаман матурланып
Мәңге яшәрбез без янарып!

КАРТЛЫК - ШАТЛЫКМЫ?

Җәмилгә

Картлык - шатлык түгел, диләр,
Өзеп куйган шарт юктыр -
Гомернең һәр фасылында
Үзенчәрәк шатлыктыр.

Арта бара нәсел-нәсәп,
Тармаклана-кинәя,
Шатлыкларың да өстәлә,
Юк монда һич киная.

Һәр тумыш көндә - туган көн,
Берсен дә онытмыйсың -
Бәллүр касәләр чыңлатып,
Күккә чөеп котлыйсың.

Шөкер, зарыкмый-тарыкмый
Җитмешкә җиткән мәлем,
Яшьләр белән рәттән заман
Безне дә җиккән әле!

Картлык шатлыгым - эшем бар,
Җан асрарлык төшем бар,
Кишер кимерерлек әле,
Күз тимәсен - тешем бар.

Улым белән икәү бергә
Проспекттан узганда,
Әллә аңа, әллә миңа
Елмаялар кызлар да.

Картлык - шатлык, рәхәтләнеп
Чибәрләрне күзлимен:
Кайсы оныгыма кайсы
Ошар, диеп эзлимен.

Уянып-уйланып ятам,
Йокым качкан таңнарда -
Өлкәнлекнең яшьлеген дә
Кирәк икән аңларга.

Болай булса, ярап тора,
Аерма картлыгымнан -
Исәнлекне, исәрлекне
Искәргән шатлыгымнан!

УРМАН МАНАРАЛАРЫ

Безнең якларның юллары,
Ул - урман аралары,
Болытка тигән имәннәр -
Урман манаралары!

Җилләр искән, җилләр кискән,
Исеп бетермәгәннәр,
Тере манаралар үскән -
Кисеп бетермәгәннәр...

Имәннәрне колачлыйк дип,
Яланаяк әйләндек,
Мәгърур имәннәрдән, ахры,
Горурлыкка өйрәндек.

Мәңгегә калган имәннәр
Без үскән Тау ягында.
Имәннәр офыкка карый -
Карыйлар таң ягына!

Солтан ИСХАКОВ һәм Андрей ТИТОВ фотолары.

мәдәни манзара

7-10 нчы сентябрь көннәрендә Татарстан Фәннәр академиясендә "Галәм һәм мәктәп" дип аталган беренче халыкара конгресс үтте. Конгресста Мәскәү, Минск, Саратов, Екатеринбург, Уфа һәм Татарстан шәһәрләреннән галимнәр, педагоглар, табиблар катнашты. Биредә халкыбыз тарихына, мәдәниятенә, милләт генофонды, гаилә һәм авылның зыялылык дәрәҗәсен арттыруга кагылышлы әһәмиятле мәсьәләләр каралды.

К. Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры бинасында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе шагыйрә Гөлшат Зәйнашеваның 70 яшьлек юбилее уңаеннан зур иҗат кичәсе уздырылды. Сәхнәгә шагыйрәнең иҗат дуслары Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Рафаэль Ильясов һ.б. күренекле җырчылар күтәрелде.

Сентябрь ахырында башкалабыз Казанда Әфганстанда һәлак булганнар истәлегенә һәйкәл ачу тантанасы булды.

Һәйкәл - туган илләренә әйләнеп кайта алмаганнар турында, аларның тормышка ашмаган өметләре, үйниятләре, төзелмәгән йортлары, тумаган балалары турында истәлек ул. "Әлбәттә, һәйкәл яшь егетләребезне кире кайтармас, ләкин ул мондый сугышлар бүтән булмасын иде дигән өмет белән эшләнде", - диде аның авторы Асия Миннуллина әлеге тантанада чыгыш ясап.

Казанның Апанай мәчетендә танылган татар мәгърифәтчесе,ислам белгече Әхмәтһади Максудига багышлап хәтер кичәсе уздырылды.

Күптән түгел башкалабызда аксакаллар һәм төбәк оешмалары вәкаләтле вәкилләренең оештыру корылтае булып узды. Нәтиҗәдә татар халкының Аксакаллар шурасын оештыру турында карар кабул ителде.

Корылтайда Россия армиясе генералитеты вәкилләре, ерак һәм якын чит илләрнең руханилары, эре предприятие җитәкчеләре, танылган мәдәният, фән эшлеклеләре, язучылар катнашты. Татар халкының Аксакаллар шурасы рәисе итеп Рәфигулла Хәмидуллин сайланды.



Стокгольмда 33 нче халыкара архив конференциясе булып узды. Анда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы архив идарәсе җитәкчесе Дамир Шәрәфетдинов та катнашты. Әлеге форум барышында ул Азия, Африка илләре архивчыларына, Идел буенда ислам динен кабул итү тарихы белән бәйләнешле рәсми кәгазьләрне эзләү һәм кайтарып бирүне үтенеп, гарәпчә язылган мөрәҗәгатьләр таратты. Моннан тыш, Швеция Милли архивының "Татарика" фондында сакланган 200 дән артык документлар күчермәсе Татарстанга кайтарылды.

РӘСЕМДӘ: тарихи хәзинәне Д. Шәрәфетдиновка (сулдан беренче) тапшыру вакыты.

Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышында язучыларның булачак корылтаена әзерлек турында фикер алышынды. Шул уңайдан "Био-библиографик белешмәләр һәм Татарстан язучылары" дигән яңа китап чыгару кирәклеге дә әйтелде. Корылтай киләсе елның маенда узарга тиеш. Утырышта аерым әдипләрнең юбилейларын билгеләп узу мәсьәләсе дә каралды. Идарә утырышында балалар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш керткән шагыйрь Хәкимҗан Халиковка Абдулла Алиш исемендәге әдәби бүләк бирү турында карар кабул ителде.

"Казан" милли мәдәният үзәгендә "Тарихи география, Урта Идел буенда IX-XII гасырдагы сәүдә юллары һәм шәһәрләре" дигән темага симпозиум булып узды.

Аңа дөньяның күп кенә илләреннән Шәрекъне өйрәнүчеләр килде. Биредә "Урта гасырлар Казаны: барлыкка килүе һәм үсеше" дигән темага да фикер алышулар булды. Симпозиумны үткәрүдә Россия, Татарстан Фәннәр академияләре, Казан дәүләт университеты галимнәре катнашты.

Казанның Гали мәчетендә Россия Ислам университетының шәригать факультетын рәсми төстә ачу тантанасы булды. Анда шәһәр хакимиятеннән, иҗтимагый үзәклардән һәм Диния нәзарәтеннән вәкилләр катнашты.

А. М. Бутлеровның тууына 170 ел тулуга һәм Казан химия мәктәбенең 160 еллыгына багышлап КДУның Бутлеров исемендәге фәнни-тикшеренү институтында фәнни сессия уздырылды.

Анда Мәскәү, Екатеринбург, Түбән Новгород, Уфа һәм Россиянең башка шәһәрләреннән галимнәр катнашты.

Татарстан Дәүләт симфоник оркестры үзенең 32 нче концерт сезонын башлап җибәрде.

Иҗат коллективы, республиканың Зур концерт залында чыгыш ясап, А. Луппов, Л. Хәйретдинова һәм чит ил композиторлары Г. Малер, Э. Григ әсәрләрен башкарды.



Татарстан Җөмһүриятенең Дәүләт музеенда танылган рәссам, шәмаилләр остасы, быелгы җәйдә 50 яшен тутырган Нәҗип Нәккашның шәхси күргәзмәсе үткәрелде.

Бу күргәзмәдә гарәби каллиграфиянең бер жанры (төре) — тугралар күрсәтелде, ул "Һәр шәхеснең үз билгесе" дип аталган иде. Исеменнән үк күренгәнчә, борынгыдан килгән төрки сүз "тугра" – тамга, шәхси билге дигәнне белдерә. Гарәп язулы туграның традициясе бик күптәннән - XIII-XIV гасырлардан үк, төрек солтаннары, Алтын Урда ханнары заманнарыннан ук килә. Гарәп язулы чорда безнең татар укымышлыларының, сәүдәгәр-эшкуарларның тугралы шәхси мөһерләре булган. Соңгы 80 еллар эчендә югалган, онытылган бу традицияне әдәбият галиме һәм каллиграф Н. Нәккаш яңартып, тергезеп җибәрде дисәк, шаять, ялгышмабыз. Шушы күргәзмәдә аның 60 ка якын иҗат эше куелган иде. Гади балта остасыннан башлап илбашына кадәрге, танылган вә танылмаган бу шәхесләрнең исем шәрифләре, билгеләре һәрберсе үзенчәлекле булып, реаль шәхеснең теге яки бу сыйфатын, холкын йә гамәлен, һөнәрен чагылдыра, шуңа күрә туграны хәрефләр белән язылган портрет дип тә атарга мөмкиндер. Әлеге рәсемдә сез Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев туграсын күрәсез.

Мәркәзебезнең Авиатөзелеш районында урнашкан "Старт" клубы "Әйдәгез, танышыйк!" дип аталган ачык ишекләр көне үткәрде.

Нәни артистлар үзләре теккән киемнәр белән дусларына театрлаштырылган тамаша күрсәттеләр. Клуб директоры Зоя Борисова әкият геройларын сайлап алуны балалар хөкеменә тапшырган иде.

Сентябрь урталарында "Гринлайн" исемле яңа газета-дайджестның беренче саны дөнья күрде. Әлеге матбаганы нәшер итүчеләр, әлбәттә, Америка ачып маташмаган, Россия һәм Татарстан матбугатыннан үзләре өчен иң кызык, актуаль дип тапкан язмаларны күчереп кенә бастырганнар.

Казан дәүләт университеты музеенда "Күңдәге хыяллар" күргәзмәсе ачылды. Анда чын күңнән рәсемнәр ясаучы Ольга Черкасованың 180 эше куелган иде.

Остакул Ольганың тәүге күргәзмәсе 1996 елда Казанда уза. Аның шактый эшләре Германия, АКШ, Франция, Канада, Япония һәм башка илләрдә шәхси тупланмаларда саклана.

КЕШЕ ГОМЕРЕ - гасыр ярым

Социаль проблемаларның бүген иң мөһиме - сәламәтлеккә турыдан-туры бәйле булганы - тукланудыр, мөгаен. Белеп туклану гаять четерекле мәсьәлә, үзе бер зур фән. Ашау өчен яшәмик, яшәү өчен ашыйк, дигәннәре хакыйкать.

Фәридә ШИҺАПОВА,

Татарстан Республикасы санитария-эпидемиология күзәтүе дәүләт комитетының туклану бүлеге мөдире.

Бүген, ипи-су белән генә яшәгән гаиләләр дә байтак булган заманда, файдалы, витаминлы азыкка гына өстенлек бирегез, дип әйтү, бәлки, уңайсыздыр да. Ләкин медальнең икенче ягы бар - табигать безгә витаминны көлтәләп биргән. Эшкәртелгән, пешерелгән, кыздырылган ризыкны цивилизация тудырды. Табигать үзе биргән байлык белән туклану зарур. Авыртуларга китергән, үлемне коточкыч тизлек белән якынайткан нәрсә безнең әнә шул табигый азыкны кире кагуыбызда, кадерсезләүдә.

Бөтендөнья сәламәтлек саклау экспертлары чаң суга - кешелек бүген бик җитди куркыныч алдында тора, артык күп ашау, симерү, аз хәрәкәтләнүдән миллионлаган халык атеросклероз, йөрәк-кан тамырлары, сөяк һәм мускул авырулары корбаны булачак. Авыру тәлинкә төбендә, дип тә, кашык белән үзеңә кабер казыйсың, дип тә бик белеп әйткән борынгылар.

Симерү эпидемиясеннән котылырга була. Иң мөһиме - һәртөрле майлар куллануны чикләү, баллы һәм кондитер азыклар кулланудан бөтенләй баш тарту. Шикәрне сахарин төймәләренә алыштырырга мөмкин, бүген алар һәр даруханәдә тулып ята. Баллы ризыктан баш тарта алмаучыларга атнасына ике тапкыр мармелад ашарга мөмкин. Ит азыкларыннан - тавык, күркә, куян итләренә өстенлек биреп, бәрән, дуңгыз, каз, үрдәк ите, төрле сосиска, салями, котлетлардан бөтенләй читләшергә кирәк. Ашау - гадәт бит ул, ә саулыгы кадерле кеше нәфесен тыярга тиеш. Ә менә балыкның теләсә кайсын ашау файдалы.

Тән саулыгын тәэмин итүче төп азыклар ул, әлбәттә, яшелчә, җиләк-җимеш. Җәй-көз айларында организм өчен кирәк кадәр табигать байлыгы булган укроп, петрушка, яшел суган, шалкан, кычыткан, кузгалак ашап, төрле үлән-яфраклардан төнәтмәләр эчеп калырга кирәк.

Соңгы елларда, бигрәк тә хатын-кызны аямый торган "тыныч авыру"лар исемлегендә йөрүче остеопороз авыруы киң таралды. Травматология бүлегенә аяк-кул сындырып яшьләр, ирләр, балалар күп мөрәҗәгать итә. Әлеге "сөяк сыну" авыруына организмда кальций җитешмәү сәбәпче була.

Сөт, катык, каты сыр, бодай икмәге, эремчек, кәбестә, соя һәм чикләвекләр кальцийга бай. Минераль су эчү дә организмны кальцийга баета.

Ләкин сөякне 30 яшькә кадәр ныгытырга кирәк. 35 яшькә җиткәндә сөяк нык булса, ул кальцийны аз югалта. Ләкин ятып торган сөяккә кальций үзе агып керми дигәндәй, аның тәндә яхшы үзләштерелүе өчен Д витамины, кояш яктысы кирәк.

Сөт тирәсендә бүген күп төрле бәхәсләр бара. Берсе - файдалы, икенчеләр исә аны зыянлы дип расларга тырыша. Ләкин көненә ярты литр сөт, ике телем сыр ашау кешенең кальцийга булган көндәлек ихтыяҗын канәгатьләндерә. 1 литр сөттә 1200 мг кальций бар. Әгәр шулкадәр кальцийны башка ризыклардан алам дисәгез, 3 кг кишер, 10 кг сыер ите яки 17 кг алма ашарга кирәк. Кесәгез калынлыгына карап рацион сайлау һәркемнең үз ихтыярында.

Белеп туклансагыз, сәламәт булырсыз һәм симезлек авыруына юлыкмассыз да.

Ит азыгы куллану соңгы елларда 20 килограммга кимеде. Америкалыларга караганда сыйфатлы, кирәкле "кара" итне россиялеләр ике тапкыр кимрәк ашый. Безнең халык бүген "ак ит" - тавык ите корбаны. Америкалылар үзләре тавыкның май аз булган түш итен генә яраталар.

Бүген базар, кибетләргә чит ил ризыклары тулды. Аларның сыйфаты шик тудыра. Консервантлар микроб күзәнәкләрен генә түгел, кеше күзәнәкләрен дә үтерә. Ә кайбер "Е" хәрефе белән бирелгән консервантларның хәтта

ашказаны-эчәк җәрәхәтенә китерүе билгеле.

Күп очракта ысланган колбаса, торт, пирожный ашаганчы, бер көн бөтенләй ач тору хәерлерәк. Кеше, гомумән, атнаның бер генә көнен булса да чистарыну - ач торуга багышласа, сәламәтлеге нык, кәефе шәбрәк булыр иде.

2000 ел элек үк Гиппократ: "Симезлек гомерне кыскарта", - дип язган. Табиблар гомер-гомергә: "Сәламәтлек өчен аз ашауның файдасы күбрәк", - дип әйтә килделәр.

Һималай тауларында бик озын гомер кичерүче бер кабилә яши. Алар кышка кергәндә бернинди азык әзерләмиләр һәм язга кадәр ярым ач яшиләр. Ул кабилә кешеләре 120-140 яшькә кадәр яшәп, сәламәтлекләрен җуймый, бары картаюдан гына үләләр.

167 яшенә кадәр яшәгән (галимнәр соңрак анын 15 яше арттырып язылган дип исбатладылар) Әзәрбайҗан аксакалы Ширали Мөслимов журналистларга туган көне мәҗлесендә болай дигән: "Мин бервакытта да каударланмый, ашыкмый яшәдем, тормышым гел бер тәртиптә барды, ашау белән мавыкмадым. Кирәк өчен түгел, ашказаны сораганда гына ашадым". 150 яшенә кадәр эшләгән аксакал ул!

Статистика күрсәткәнчә, бүгенге көндә дөньяда 100 яшьтән өлкәнрәк кешеләр саны 61 мең исәпләнә. Шуның 49 меңе хатын-кызлар, 12 меңе ирләр. Россиядә йөз яшьлек чикне узучылар 6900, шунын 255 е Мәскәүдә яши. Ә Татарстан Республикасы Дәүләт статистика комитеты мине шундый саннар белән таныштырды. Татарстанда 1997 ел башына (быелгысы әлегә билгеле түгел) 100 яшьтән өлкәнрәкләр саны 159 кеше икән. Шуларның 122 се хатын-кызлар, 37 се ирләр.

Россиядә картаю проблемаларын өйрәнүче бердәнбер геронтология институты директоры, академик Владимир Шабалин: "Кеше гомере гасыр ярым булырга тиеш, анын генетик программасы 140-150 елга исәпләнгән", - ди. Башка галимнәрнең фәнни яктан дәлилләп күрсәтелгән хезмәтләрендә кеше гомере 100-110 яшь белән чикләнгән диелгән.

"Озак яшәү өчен оптималь шартлар булуы кирәк, - ди В. Шабалин. - Нәрсә соң ул оптималь шартлар? Күпләр стресссларсыз, тыныч яшәү, диләр. Ләкин беренче шарт ул түгел. Организм бөтенләй стресссларсыз да яши алмый. Аңа физик нагрузка кебек, рухи-психик нагрузка да кирәк. Иң мөһим шарт - дөрес туклану! Витаминлы, сыйфатлы ризык, сулар һава һәм эчәр суның арулыгы".

Ә нигә хатын-кызлар озаграк яши соң? В. Шабалин фикеренчә, ир-атлар берүк эшкә хатын-кызларга караганда энергияне 40% ка артык сарыф итә. Табигать ир-атны экстремаль ситуацияләр өчен яраткан.

Кайбер галимнәр, ир-атны тәмәке, алкоголь иртә үтерә, дип исбатлыйлар. В. Шабалинның фикере үзгәрәк. Нәрсә эчү белән бәйле ул... Шәраб саулыгы яхшы кешегә файдага гына, 100 яшьлек картка да көн дә 1 бокал шәраб эчеп кую зыян китерми. Ничек кенә булмасын, озын гомерлеләрнең иң күбесе Кавказда яшәве билгеле. Ә алар шәрабсыз яши алмыйлар.

Әйе, шәрабы нинди дер шул. Үзләре ясаган, югары сортлы йөзем шәрабы эчә бит алар. Кара виноград согы эчәләр. Ә кара виноград согын даими куллану кан оешу (тромб) куркынычын киметә. Аспирин да шул үзлеккә ия.

Яшәү бер хәл, ләкин ничек яшәү икенче мәсьәлә. Бүген кеше миенең эшкә сәләтлелеген озайту да мөһим. Кешенең интеллекты 50 яшькә иң югары ноктасына житә. "Нәкъ 50 яшькә житкәндә кеше фән докторы, академик дәрәҗәсенә күтәрелә ала. Ә 50 яшькә житкән кешене безнең җәмгыять "утилгә чыгара", - ди В. Шабалин.

Әлеге дә баягы безнең тормыш дәрәҗәсе түбән булу дөрес тукланмауга, дөрес тукланмау авыруларга китерә. Гомернең күп өлеше азык әзерләп, азык юнәтеп үтә бит. Тәмлене яратабыз. Ә менә ул сәгатьләр буе плитә каршында бии-бии пешергән нигъмәтебез организм өчен файдалымы, шунысын уйласак икән. Яшәү өчен генә яшәсәк иде.



Әхәт САФИУЛЛИН

ЯҢА ЫСУЛ БУЕНЧА

(Шаян хикәя)

Сәламәтлекнең кадерен исән-сау вакытта, җир җимертеп йөргән чакта гына белмибез икән. Авыру якадан бөтереп алгач кына исебезгә төшә.

Уйламаганда гына үзем дә аяктан егылдым. Чалгы белән чабып аткан үлән шикелле, бер көн эчендә шәлперәйдем дә төштем. Нидер ярамады бугай, эчне шундый итеп борып-борып ала, мин сиңа әйтим, һич түзәр әмәл юк! Тәмам хәлдән тайдым, баш әйләнә. Ятам күзләрне түшәмгә текәп. Ычкынуым шушы, ахрысы, мин әйтәм, хатын, балалар, бәхил булыгыз! Очрашсак, тегендә генә очрашабыз инде...

Юк, алай тиз генә җибәрәселәре килмәде, "ашыгыч ярдәм" машинасын чакырдылар. Карыйм, мин җан тәслим кылганчы килеп тә җитте болар! Эчемә төрткәләп-баскалап карадылар да - бәхетемәдер инде, табиблары бик кеше җанлы булып чыкты - үзләре белән алып та киттеләр мине. Эчкә бераз җан кергәндәй булды. Шәт, инде кулларына эләккәч, күрә торып үтермәсләр дигән өмет чатнап куйды. Ни әйтсәң дә, хәзерге медицинаны мең дә тугыз йөз унөченче елгы медицина белән чагыштырырлык түгелдер инде! Дөрес, уколлар кадап азапларлар инде азаплавын... Бер генә дә җаным сөйгән нәрсәм түгел, гомер буе куркып яшәдем шул энә, пычак ише нәрсәләрдән. Ләкин нишләмәк кирәк, якты дөньяда яшисең килсә, энә кадау түгел, тунасалар да сүз әйтмисең.

Алып килделәр дә, палатага салдылар. Кан белән башка нәрсәләрне анализга алдылар, шакы-шокы китереп, күкрәк белән җилкәгә суккалап чыктылар. Хәтта температураны да тикшерделәр. Мондагы табиблар би-ик тәҗрибәле булса кирәк, аны термометр белән түгел, кул белән генә үлчәделәр. Берсе маңгаема бармакларын тидереп алды да: "Утыз сигез дә алты", - диде.

Аннары берсе җеп саплаган энә һәм агач линейка тотып килеп утырды. "Менә инде кадамакчы да булалар, - мин әйтәм эчтән генә, - башланды..." Табиб - хәер, миңа ак халат кигәннәрнең барысы да табиб инде! Кем белә, бәлки, ул шәфкать туташы булгандыр - җиңемне сызгандырды да, шул сапланган энәсен җебеннән тотып, кан тамыры буйлап йөртә башлады, аннары кулындагы линейка белән нәрсәдер үлчәп маташты. Кыскасы, мин бу юлы энәдән юкка гына курыкканмын: аның кан басымын үлчәве генә булган икән. Дөрес, аны ниндидер махсус прибор белән үлчи торганнар иде шикелле... Монда икенче төрлерәк икән.

Аннан соң бик ныклап эчкә тотындылар. Капшыйлар, басалар, изәләр, сыпыралар. Һәм баскан-капшаган саен: "Йә, ничек, авыртамы? Ә болай? Ә монда?" - дип сораштыра-сораштыра аптыратып бетерделәр. Сәгать ярым чамасы маташтылар болар минем эч белән. Шулай баса-изә-капшый торгач, хәтта авырту да кими төште сыман...

Ә баш (тегермән ташы дип белерсең!) әйләнепме әйләнә, күз алларым караңгыланып-караңгыланып китә. Эчтән генә, хәл кертә торган берәр дару да бирмиләр, ичмаса, дип уйлап ятам. Инде актыгында уколына да түзәр идем, тик күз алдымда түшәм белән идән генә сикерешмәсен...

Табибның үз эше: эчне капшап туйгач, бер-бер артлы сорау яудыра башлады. "Үзегезнең, туганнарыгызның тиф белән авырганыгыз булмадымы?" - ди бу миңа. Юк, дим, андый нәрсәнең гомердә дә нәселебездә булганы юк! "Әби-бабагыз революциягә кадәр туганнармы, әллә октябрь вакыйгаларыннан соңмы?" - дип сорый табиб. Әлбәттә, революциядән соң, мин әйтәм. "Әби-бабагызның, эти-әниегезнең һәм үзегезнең чит илләрдә булганыгыз бармы, юкмы?" - дип тә төпченә бу. Юк, юк, беркемебезнең дә чит-ят илләрдә булганыбыз юк, дип кул селтәдем. Үзем шулай дим, үзем шикләнә төштем: нуҗәли СПИД дигән явыз нәрсә таптылар?! Аннары кылт итеп, моннан ун-унике еллар чамасы элек хатыным белән Ригага барып кайтуыбыз искә төште. Бик очсызга гына менә дигән костюм-чалбар алып кайткан идек. "Әйтергә микән, әйтмәскә микән?" - дип, тәмам аптырашта калдым. Аптырарсың да, чөнки Рига хәзер чит дәүләтнең башкаласы бит! Уйлап-уйлап тордым да, бу турыда әйтмәскә булдым. Ник дигәндә, ул чакта бер ил идек ләбаса...

- Сальмонеллез түгел микән сездә... - дигән нәтиҗә ясады табиб. - Ярар, борчылмагыз, дәваларбыз... Тик менә нәрсә: сез безгә бик каты ышанырга тиеш! Никадәр нык ышансагыз, шулкадәр тизрәк терелерсез. Без монда традицион булмаган ысул белән дәвалыйбыз...

- Ышанам, доктор, бик ышанам мин сезгә, - дидем мин, урынымнан күтәрелә төшеп. - Дәвалагыз гына!

"Нинди традицион булмаган ысул икән бу? - дип уйлап алдым мин. - Әллә гипноз белән микән? Хәер, хәзер медицинаның башы җитмәгән нәрсә юктыр... Көненә генә дә күпме ачыш ясала торгандыр! Яңа дарулар уйлап табалардыр..."

Икенче көнне дәвалый да башладылар: иртәнге аш алдыннан бик яхшы итеп массаж ясадылар. Аяк табаныннан алып башка хәтле! Тән ут яна башлаганчы, бер сәгатькә якын ышкыды мине бер чибәр генә кыз. Үзе ышкый, үзе: "Йә, ничек? Кәефегез яхшырамы? Бераз җиңеләймиме?" - дип сораштыра. Җиңеләйгән шикелле, мин әйтәм, тик баш бик әйләнә әле, хәл юк, температура да югары бугай... "Хәзер үлчибез", - ди ул миңа һәм кулын маңгаема куеп алды да: "Утыз сигез дә ике", - дип, шундук әйтеп тә бирде.

"Ай-яй, нинди тәҗрибәле кешеләр эшли икән

монда! Хәтта термометрсыз да нинди төгәллеккә ирешкәннәр!" - дип шаккаттым.

Көндезгә аш алдыннан да берәр сәгать чамасы массаж ясадылар. Кичкә таба да шул ук нәрсә кабатланды. Һәм икенче көнне дә, өченче көнне дә. Миңа бу массаж дигәннәре шулкадәр ошап китте, берсеннән-берсе чибәр туташларның кулы тәнемә кагылуы була, шундук эрим дә китәм! Йокы менә дигән дәва чарасы, дип юкка гына әйтмиләр икән шул. Эшләр җайга китте: бернинди укол кадаучы да юк, дару эчертүче дә юк, массаж да йокы, йокы да массаж. Чыннан да, шулай берничә көн яткач, тернәкләнеп үк киттем бит, әй! Баш әйләнүе дә бетте диярлек, температура да төште.

"И-и, мин әйтәм, яшибез икән, болай булгач! Табиблар кулы - табиблар кулы шул. Болар барысы да Чумак белән Кашпировский һәм безнең Галләмов шикелле экстрасенслар, психотерапевтлар, ахрысы".

Өч атна дигәндә җир җимертеп йөри идем инде. Өйгә кайтыр алдыннан мине дәвалаган табибларның барысына да зур рәхмәтемне әйтеп, мондагы традицион булмаган ысулларның әйбәтлегенә сокланып:

- Менә дигән ысул икән бу! - дидем. - Моны киләчәктә дә кин кулланырга кирәк...

- Нишлисең, дарулар түгел, температура үлчәргә термометрлар да юк заманда, кулыбыздан килгән берләнбер чарабыз шул инде... - диде моңа каршы табибларның берсе. - Традицион медицинабыз үлде, традицион булмаганы гына калды...

Ә мин уколдан куркып яттым тагын, җүләр! Эңәләре дә, шприцлары да, дарулары да юк икән ич аларның! Үнөченче елларда гына булган, ди, алар...

Фәнзаман БАТТАЛ

Мал

(Хи-хикәя)



- Әлү!.. Привет!

- Сәлам, сәлам! Бик иртә кузгалгансың бит әле. Гастрольгә җыенмыйсыңдыр бит? Йокы кадерен беләә иден кебек болай?..

- Йокы юньле булмады бүген, малай. Төн буе баш ватып чыктым. Берәр юньле мал кирәк иде. Шуңа күрә син чыгып киткәнче дип шалтыратуым.

- Кәҗәме, сарыкмы?..

- Шаяртма әле. Унсигез-егерме яшьләрдәге кыз кирәк. Синең техникумыңда адашып йөрмиме шундый бер мал?

- Әллә хатыныңны курортка җибәрдеңме?

- Туктале, малай, һич тә шаяртасым килми...

- Нинди кирәк кыз кирәк соң сиңа?

- Тыңлап тор: иң мөһиме - аяклары! Төз булсыннар, озын булсыннар!

- Андый бер кыз бар. Аяклары да челәннеке сыман. Нечкәлеге дә, озынлыгы да чаңгы таякларыннан әллә ни аерылмый.

- Юк-юк, батмый. Анысы укысын, зоотехник булсын, ит, май ашап тазарсын... Миңа юан ботлы, матур балтырлы кыз кирәк.

- Тәк-тәк...

- Тиресе дә ак булсын! Каралардан туеп беттем. Гел шундыйлар килә... Күкрәк мәсьәләсе дә бик мөһим: калкып, ташып торганы кирәк. Хәзер бит, үзең беләсең, андыйлар дефицит...

- Андыйлар күренгәли бездә, күренгәли. Башлары булмаса да, ул шәрифләре муллдан!

- Акылы минем өчен неважно. Аннан соң, игътибар белән тыңла, биле шәп булсын! Өзелеп китәрдәй нечкәсе кирәк.

- Һай, таләпләр зур синең! Андыйлар бөтен техникумны сафка тезсәң дә икәүдән-өчәүдән артмас.

- Таләпләрнең зурысы алдарак әле, малай. Муены аккошныкыдай нәфис булсын. Чәчнең инде йомшагы, куесы, сикергән чакта байтал ялыдай үйнап торганы кирәк.

- Нигә, сикерергә тиешмени ул?

- Тыңлап тор әле син башта... Йөзе, күзләре фәрештәнеке кебек нур сибеп торсын, ә керфекләре озын, күбәләк канатларыдай ачылып-ябылып тора торган булсын.

- Сокланам мин сиңа! Илледән үтсәң дә, нәфесең егерме яшьлек егетләрнеке кебек!

- Туктале, причум монда нәфес? Тыңлап бетер әле син. Шушы мин санаган сыйфатларыннан тыш, сәламәт һәм җитез хәрәкәтле булсын. Утлы табадагы борчактай сикереп торырлык мал кирәк! Рәттән ярты сәгать биеп торса да ару-талуның нәрсә икәнен белмәсен! Шундый кыз тапсаң, үзенә кистереп әйт: кадерең булачак, диген, сәхнә йолдызы ясыйбыз дип әйтәләр диген. Әйбәтләп сөйләш. Бездә бит акча ягы шәп хәзер.

- Ә-ә, аңладым! Сиңа биюче кыз кирәк! Башта ук шулай диләр аны...

- Юк, ялгыштың. Миңа җырчы кыз кирәк.

- Туктале, тукта! Җырчы кирәк булса, син бит сүзне тавыш мәгълүматларыннан башлар иден?

- Причум монда тавыш?! Хәзерге заман җырчысына тавыш, моң нәрсәгә? Иң мөһиме мин санаган сыйфатлар! Барабан суккан, быргы кычкырткан көйгә, ике-өч сүзне кабатлый-кабатлый, тәпие пешкән тавык шикелле сикереп йөри алса, шул бик җиткән....

Ринат АБЗАЛОВ һәм Александр АЛЕШИН рәсемнәре.

РЕЗЮМЕ

Очередной, десятый номер журнала открывает статья зам. председателя Госкомимущества И. Хайруллова, посвященная проблемам приватизации госсобственности в республике.

"Госслужащий" - статья публициста А. Файзрахманова поднимает очень актуальную проблему - о положении госчиновников в нашей республике.

Известный драматург, народный депутат РТ Т. Миннуллин делится своими воспоминаниями о Раисе Беляеве - выдающейся и трагической личности, стоявшей у истоков строительства "белого города" - Н. Челны и немало сделавшей для культуры, будучи ректором академии искусств.

В Муслюмово нашли золото! - не сенсация ли! Предполагается, что здесь можно добыть столько же золота, сколько сейчас добывает Зимбабве и Боливия. Р. Фаттахов и Г. Гумер освещают эту тему в статье "Муслюмовская земля - золотая".

Проблеме подростковой преступности посвящена статья начальника управления внутренних дел г. Казани, полковника милиции Н. Акберова. Почему в последние годы такой разгул подростковой преступности, что надо сделать для ее искоренения, размышляет автор.

"Я не выходила замуж за мэра города" - так озаглавлена беседа с супругой К. Исхакова Фанией-ханум.

По традиции журнал продолжает публикации статей, посвященных претворению в жизнь Закона о государственных языках. Это беседа с главным референтом КМ К. Миннуллиным. Р. Мухаметдинов высказывает свою точку зрения о происхождении татар.

RESUME

The tenth issue of the magazine opens with the article of the Deputy Chairman of the State Property Committee I. Khairullov, devoted to the problems of privatization of State property in the Republic of Tatarstan.

"State officials" - under this title A. Faizrakhmanov presents an article concerning tne actual problems of the standing of State officials in our Republic.

The article of T. Minnullin, a prominent playwrite and People's Deputy of the Republic of Tatarstan, is devoted to the memory of Rais Belyaev, an outstanding, though tragic, personality whose life was closely connected with the construction of the so called "White City" Naberezhny Chelny and who, later in the capacity of Rector of the Kazan Academy of Arts, did much for the cultural development of that City.

"Gold was discovered in Muslumovo! Isn't it sensational!" It is supposed that this region may give as much gold as Zimbabwe or Bolivia R. Fattakhov and G. Gumer speak on this theme in the article "The Land of Muslumove is Golden".

The article by the Chief of Local Internals of Kazan, Militia Colonel N. Akberov, discusses the problems of juvenile delinguency. The author is concerned about the state of affairs and he deliberates and offers possible solutions.

"I didn't Marry the Mayor of the City" - that's the title of the interview with the wife of K. Iskhakov - Mayor of Kazan.

A series of articles traditionally tells about the realization of the Law of the State Languages of the Republic of Tatarstan. One of the authors is the head referent of the Cabinet of Ministers K. Minnullin.

A historian R. Mukhametdinov shares his view points on the origin of the Tatars.

Татарстан дигән
Ватаным бар,
"Татарстан" дигән
журналым!
Мин аларга
үткәннәрдән түгел,
Киләчәктән
урын барлыймын!

ХӨРМӘТЛЕ ДУСЛАР!

Яңа, бай эчтәлекле, зиннәтле кәгазьле, югары полиграфик бизәлешле - республикабызның иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисадый һәм мәдәни проблемаларын киң яктыртучы "Татарстан" журналына 1999 елның беренче ярты еллыгына язылу дәвам итә.

Безнең индекс - **73377.**
Ярты елга язылу бәясе - **36 сум.**

КОТОЧКЫЧ АФӘТТӘН СОҢ

Сезнең ишеткәнегез булдымы икән: Бөек Ватан сугышы кебек коточкыч афәттән соң да коммунист һәм комсомол балаларының җенси органнарын тикшереп йөргәннәр. Ата-аналары аларны сөннәткә утыртмаганнармы, янәсе. Әйе, әйе, сугышта җиңеп чыккан халык тормышында ээәрлекләүләр һаман дәвам иткән. Шул ук вакытта демократиянең аерым элементлары үзләренә юл яра килгәннәр.

Бу катлаулы процесслар ничек барган? Алар аерым шәхесләрнең язмышында ни рәвешле чагылган? Әйтик, Муса Җәлил ничек реабилитацияләнгән? Гомумән, ул чорда Татарстандагы социаль-сәяси хәл-халәт нинди булган?

Архив мәгълүматларына таянып язылган хезмәтендә күренекле тарихчы, академик Индус Таһиров әнә шундый сорауларга җавап бирә.

Яңа мәгълүматларга бай булган бу кызыклы хезмәт журналыбызның киләсе санында тәкъдим ителә.

Безнең индекс - 73377.